Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 9 (1374) 11 март 2022 ел

1995 елның июленнән башлап чыга

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:
madani_zhomga
madanizhomga
madanizhomga
madanizhomga

Казанда бер дә кадере булмаган тарихчы, җәмәгать эшлеклесе, чын милләтпәрвәр Һади Атласины Бөгелмәдә зурлыйлар.

12

Бик кыска гына гомер кичергән артист Камил Камалов табигый таланты, экчерсезлеге белән тамашачы күңелен яулап өлгергән иде.

14

“Казан” бию ансамбле үзенең 25 еллык бәйрәме уңаеннан “Америка рухындагы” кызыклы тамаша тәкъдим итте.

24

И тынычлык кошым, син дә безгә Имин көннәр генә телисеңдер...

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Мәскәүгә эш сәфәре кысаларында Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов Россиянең Тышкы эшләр министры Сергей Лавровка «ТАССР төзелүгә 100 ел» медален тапшырды.

- Пенза өлкәсенең татар милли-мәдәни автономиясендә «Тарихи һәм мәдәни мирасны өйрәнү: мәкаләләр һәм проектлар язуга җәлеп итү аша яшь буынны тәрбияләү» темасына остаханә үткәрелде.

- Самара өлкәсенең Камышлы районы Иске Ярмәк авылында язучы, татар әдәбияты классигы Зыя Ярмәки исемендәге сквер барлыкка киләчәк.

- «Татарларда кунакта» күргәзмә проекты Мәскәүдәге Хәзерге заман тарихы дәүләт музеенда эшли башлады.

- Казанда «Нуриев сезоннары» халыкара мәдәни проекты кысаларында балет артисты, хореограф Рудольф Нуриев турында документаль фильмнар күрсәтелә.

- 31 мартка кадәр казанлылар һәм шәһәр кунаклары Казан Кремле территориясендә урнашкан Татарстан Дәүләт сынлы сәнгать музееның «Хәзинә» милли сәнгать галереясын бушлай тамаша кыла ала.

- Ульяновск шәһәрендә Татарстанның атказанган артисты Барый Тарханов исемендәге татар халык театрларының төбәкара фестивале башланды.

- КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты директоры, филология фәннәре докторы Рәдиф Җамалетдинов Россия мәгариф академиясенә мөхбир-әгъза итеп сайланды.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ, әдәбият галиме:

«Әсәргә бәя биргәндә аның кызыклы булуы, тема, мотивы һәм сайлап алынган тормыш материалы белән мине җәлеп итүе һәм тотып торуы мөһим. Әсәрнең 20 битен укыганнан соң да кереп китә алмыйча азапланасың икән, андый әсәр алга таба кызыксыну уятмый».

СЫНАМЫШЛАР

Искечә 1 мартта (хәзер 14 мартта) аяз булса, бөтен яз аяз була ● Әгәр 14 мартта тәрәзәләргә боз катса, бу елны кыяр уңа ● 14 мартта көн җилле булса, бөтен җәй җилле була; урамда су күренсә, язгы ташуда су күп килә; җылы булып, тамчы тамса, кар тиз китә, җәй буе җылы була.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **6 сәгать 09 минутта** чыкты, һәм ул **17 сәгать 38 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **11 сәгать 29 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **32 минутка озынаячак** һәм киләсе җомгада, ягъни **18 мартта 12 сәгать 01 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

11 март – язучы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Индус Фатих улы Сирматовка 85 яшь (1937).

12 март – язучы, әдәбият һәм тел галиме, публицист, җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Гыйрфан улы Ибраһимовның тууына 135 ел (1887–1938);

– язучы, журналист, нәшир Фәхрелислам Нигъмәтулла улы Агиевнең тууына 135 ел (1887-1938);

– язучы Әбрар Гыйләҗетдин улы Шаминнең тууына 110 ел (1912–1979);

– тарихчы, академик һәм язучы Равил Габдрахман улы Фәхретдиновның тууына 85 ел (1937-2014).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Мартның магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көннәрне исегезгә төшерәбез: 11, 12 март.**

* * *

Гадәттә, айның беренче чирегеннән тулы айга кадәр **(10-18 март)** организм киңәюгә бара. Мондый көннәрдә организмны, бигрәк тә бавырны чистартуга бәйле процедуралар үткәрү файдалы.

Шунысын да онытмагыз: **18 февральдән 29 апрельгә кадәр** бавыр һәм үт куыгы актив булучан. Шушы вакыт аралыгында аларны чистарту һәм дәвалау уңай нәтиҗәләргә китерә.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1443 ЕЛ

Бүген шәгъбән аеның 8 нче көне

ИСЛАМ ДИНЕ КАБУЛ ИТЕЛҮГӘ 1100 ЕЛ



Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ,
филология фәннәре докторы

Ислам дине һәм татар әдәбияты

Кешелек тарихында мәҗүсилек, буддизм, зәрдәшт (зороастризм), яһүди, манихей, христиан, тәңречелек һ.б. диннәрнең яшәве мәгълүм. Аларның туу, кулланылу вакытлары, таралу урыннары да төрле. Бер өлеше билгеле бер чорда, аерым төбәкләрдә гамәлдә йөргәннән соң тарих сәхнәсеннән төшеп кала, икенчеләре гаять киң таралыш табып, меңәр еллар буе яшәвен, кулланылуын дәвам итә. Әнә шундый диннәрнең берсе – ислам. Мәгълүм ки, ул VII гасыр башларында Гарәп ярымутравында оешып, тиз арада күп кенә җирләргә (илләрдә, халыкларда, кыйтгаларда) таралып, хәзерге вакытта ике миллиардка якын кешене үз эченә ала, бернигә дистә мәмләкәттә рәсми дәүләт дине булып хисаплана.

Ислам – кайбер башка диннәр кебек, яшәешнең, рухи һәм иҗтимагый тормышның төрле күренешләрен теге яки бу дәрәҗәдә үз эченә алган, җәмгыять белән тыгыз бәйләнешле идеологик система, тәгълимат. Аның төп асылын Аллаһының барлыгын һәм берлеген тану, Мөхәммәд пәйгамбәрнең «расүл»легенә иман-ышаныч тәшкил итә. «Коръән» рухи яшәешнең нигезе итеп хисаплана.

Яңа эрага кадәр үк тарих мәйданына чыгып, дөньяга үз сүзен ишеттергән, үзенең барлыгын таныткан татар кавеме – әби-бабаларыбыз соңгы ике меңьеллыкта гаять катлаулы, каршылыклы, данлы да, фаҗигале дә юллар үтеп, дистәләгән дәүләтләр төзеп, бер-бер артлы аларны югалтып гомер кичергән. Тормышның төрле сәбәпләре аркасында аларның шактый өлеше күченгән, яшәү урыннарын алыштырган. Шуның нәтиҗәсе буларак, Ерак Шәрыктан Дунай-Балкангача сузылган гаять зур мәйданнарда һәм гомумән Евразия тарихында татар тирән эз калдырган. Гасырлар агышында әкренләп Идел-Урал, Идел-йөрт аның төп яшәү урынына әверелгән. Шунысы мөһим: безнең әби-бабаларыбыз катлаулы язмыш кичереп, төрле этник үзгәрешләргә дучар ителсә дә, аның табигатенә – татар-төркилегенә тугры калган.

Халкыбыз, аның составына кергән этник төркемнәр үзләренең күпгасырлык яшәү дәверендә, чорына һәм җирлегенә карап, иман-ышанычның төрле формаларын үз иткән. Борынгырак чорда аеруча мәҗүсилек, бераздан тәңречелек чагыштырмача киң тарала. Будда, яһүди, зәрдәшт, христиан, башка диннәрне тотучылар да була. Әмма халкыбызның мең елдан артык тарихы, тереклеге мөселман дине белән аерылгысыз бәйләнгән. Ул татарның даими юлдашына, ышанычлы, тотрыклы таянычына әйләнеп, аның бөтен күзәнәкләренә сеңгән, бар вөҗүден сугарган.

Еш кына Идел-йортта исламның кабул ителешен, тарала башлавын 922 елдагы мәгълүм вакыйга-хәлләр белән бәйләп кенә карыйлар. Билгеле ки, шушы елда Багдад хәлифе Идел-йортка составында Ибне Фадлан да булган зур делегация җибәрә. Болгар ханы Алмуш гарәп илчеләре катнашында тантаналы рәвештә мөселман динен кабул итә. Бу – тарихи яктан дөрес, реаль факт. Әмма ул шактый гына ачыклык кертүне сорый.

Тарихи чыганаклар, аерым фәнни хезмәтләр Коръән тәгълиматының Мөхәммәд пәйгамбәрдән (570-632) соңгы тәүге хәлифәләр чорында, ягъни VII гасырның урталарында һәм икенче яртысында ук Идел-йортка керә башлавын күрсәтә. Мәгълүм ки, безнең әби-бабаларыбыз элек-электән үк гарәпләр һәм мөселман дине орбитасына кергән Иран, Урта һәм Үзәк Азия, Кавказ халыклары, шулай ук башка кавем-төбәкләр белән сәүдә, мәгърифәти, иҗтимагый-сәяси мөнәсәбәтләрдә торган. Бер-берсенә килеп-китүчеләрнең дә шактый булуы билгеле.

Хәзәрләр, болгар, кыпчак, татар, кимәк һ.б. кавемнәр кебек, татарлар составындагы бик тә мөһим бер этник компонент. Якынча 632- 970 елларда яшәгән Хәзәр каганлыгы – татар дәүләтчелегенең бик тә әһәмиятле бер баскычы, буыны. Болгар, хәзәр, кыпчак кавемнәренең кардәшлеге, бер-берсе белән керешеп, кушылып китүе бәхәссез хакыйкать. Бу хакта Ш.Мәрҗани, В.Бартольд, башка гыйлем әһелләренең дә кыйммәтле фикерләре бар. Хәзәр каганлыгында ислам киң таралыш таба. Илнең җитәкчелеге 737 елда мөселман динен рәсми рәвештә кабул итә. Идел-йортта бу чорда ук шактый гына мәчет-мәдрәсәләрнең булуы билгеле. Ибне Хәүкял (X йөз) язуынча, хәзәр мәмләкәте башкаласы Итилдә генә дә 30 мәчет эшли (Греков Д., Якубовский А.Золотая Орда и ее падение. – М.-Л., 1951. - 27 с.).

Азов буйларында VII гасырның икенче чирегендә һәм урталарында яшәп алган «Бөек Болгар» дәүләтендә дә инде мөселман динен тотучылар була. Урта Иделгә күченгән болгарларда 922 елга кадәр үк ислам дине шактый киң таралыш таба. Гарәп авторы Ибне Рустә X гасыр башларында ук болай язып калдырган: «Большая часть (болгар) исповедует ислам, и есть в их селениях мечети, начальные училища с мудзэнами и имамами» (История Татарии в материалах и документах. – М., 1937. – 26 с.).

Кыскасы, халкыбызда мөселман диненең кабул ителешен 922 ел белән генә бәйләү чагыштырмача шартлы. Ул моңа кадәр үк Идел-йортта исламның берничә гасыр буена таралу, кулланылу процессының бер мөһим рәсми акты, баскычы гына. Чынлыкта безнең әби-бабаларыбызның мөселман дине орбитасына керә башлаулары якынча 1400 ел! Шунысын да искә төшереп үтик: ислам динен безнең халкыбыз мәҗбүри төстә, көчләү-кысулар нәтиҗәсендә түгел, үз ихтыярлары белән, ирекле рәвештә кабул иткән.Моңа, бер яктан, күпчелек әби-бабаларыбызның, нигездә, бераллалыкка өстенлек биргән тәңречелек тарафдарлары булуы ярдәм итсә, икенче яктан, ислам диненең гаҗәеп бай Шәрык әдәбияты, фәлсәфәсе, фәне, мәгарифе белән табигый керешүе, күп кенә гарәп-фарсы рухи кыйммәтләренең синкретик характерда булуы да уңай шартлар тудырган. Хәзәр, Болгар, Дәшти-кыпчак, Алтын Урда мәмләкәтләрендә, татар ханлыкларында динара мөнәсәбәтләрдә толерантлык, вөҗдан ирегә булуы да күп нәрсә хакында сөйли.

* * *

Дин һәм әдәбиятның үзләренә генә хас хосусиятләре, максат-бурычлары булса да, алар гомумән шактый якын, еш кына үзара керешеп, кушылып та китә. Боларның һәр икесенең дә үзегендә – кеше, аны рухи яктан тәрбияләү, үстерү. Юкка гына мөселман диненең төп китабы «Коръән» бер үк вакытта дөнья классик әдәбиятының да бөек бер ядкяре итеп хисапланмый. Чөнки анда исламның төп канун-мәсьәләләре, асылы, яшәеш, тормыш турындагы күзаллаулар үтемле тел-стиль, образ-сурәтләр ярдәмендә гәүдәләнеш таба. Шунысын да искә төшерик: бу Изге китапны безнең күп кенә әби-бабаларыбыз оригиналда – гарәп телендә укыган. Аның шактый гына тәфсир-тәрҗемәләре дә бар. Казан ханлыгы чорында ук бу ядкярнең саллы гына татарча нөсхәсе дә барлыкка килә. «Коръән»нең Ногмани, Морад Рәмзи (1855-1934), Муса Бигиев (1875-1949), Батулла һ.б. милләттәшләребез тарафыннан эшләнгән тәфсир-тәрҗемәләре дә укучыларга билгеле. Бу Изге китап инде мең елдан артык безнең әдәбиятыбызны сугарып, азыкландырып, аның асылын, төп үсеш-юнәлешләрен билгеләүдә хәлиткеч факторларның берсе булып тора.

(Дәвамы 5 нче биттә).

БАЗА ХОКУКЛАРЫН КЕМ БОЗА?

Сүзебез бу юлы халыкларның милләт буларак яшәү шартларын билгели торган хокуклары хакында булыр. Кешенең Хак Тәгаләдән бирелгән төп (база) хокуклары (яшәү, ирекле үсү һ.б.) булган кебек, милләтләрнең дә андый хокуклары бар. Чөнки кешеләрнең кавемнәр итеп яралтылуы да - Аның ихтыяры. Яшәештә алар һәркайсы үз рухи вә милли хасиятенә туры килә торган динен кабул итә, башкалар белән үз ихтыяҗларына яраклы мөнәсәбәтләр урнаштыра, шул рәвешле, рухи, милли-мәдәни, матди һ.б. мәнфәгатьләрен дә канәгатьләндерә торган мөстәкыйль дәүләтләр барлыкка килә. Яшәеш туктап тормый, ә инсаният инде бүген глобаль үзгәрешләр чорына керә. «Континенталь дәүләтләр» кору процессы башлануы сәбәпле, бәгъзеләр инде күптәннән яңа дөньяви тәртип урнаштыру теләге белән дә яна. Безләрне исә Россиядәге мөнәсәбәтләр күбрәк кызыксындыра.

Хактыр ки, милләт өчен мөһим база хокукларының берсе – туган телдә белем алу. Чөнки ул, телнең куллану һәм үсеш шартларын гына түгел, милләтнең рухи вә мәдәни үсешен һәм яшь буын аша яшәеш перспективаларын билдерүне да үз эченә ала. Шуңа ул илнең Төп Законында беркетелгән дә. Ә бүген бу яктан эшләр ничек тора соң? Конкрет фактларга күчик. 309 нчы федераль закон (2007) мәгариф буенча дәүләт стандартларыннан милли компонентны (туган тел, әдәбият, тарих һәм мәдәният) төшереп калдырды. Милли республикаларда алар буенча хәтта дәреслекләр әзерләп чыгару да отыры туктатылды. РФ мәгариф вә фән министрының 362 нче приказы (28.11.2008) милли мәктәпләрдә БДИне рус телендә генә тапшыру тәртибе кертте. Аларда рус теленнән БДИ нормалары рус мәктәпләрендәге дәрәҗәдә куелды, шул рәвешле, укуларын дәвам итү өчен, рус булмаган укучылар һәм аларның ата-аналары туган телдән баш тартырга мәҗбүр ителде.

Бүген инде илдә милли сәясәт 2012 елдан 2025 елга кадәр чор өчен кертелгән дәүләт стратегиясе нигезендә үткәрелә. Бу чор «казанышлары»ның да кайберләренә тукталыйк. Рус булмаган халыклар өчен туган телдә белем алу 9 нчы сыйныф белән генә (әле анысы да «мөмкинлек булса») чикләнде. Туган телне өйрәнү үзе дә факультатив дәрәҗәсенә (атнага 2-3 сәгать) төште һәм 9 нчы сыйныф белән чикләнде. Кыскасы, төп халыкларның Конституциядә беркетелгән хокуклары бүген дәүләт дәрәҗәсендә бозыла. Бу чорда Төп Законга күп кенә төзәтмәләр кертелде һәм алар арасында илдәге халыкларны сортларга бүлә торганы да бар. Шул ук вакытта төп халыклар бүген үз хокукларын хәтта парламентта яклау мөмкинлегеннән дә мәхрүм ителгән. Чөнки илдәге сайлау системасы халык ихтыярын чагылдырмый. Болардан тыш, Россия тарихында зур роль уйнаган халык буларак, хәтәр кавем татарларны аерым исәптә тота, үзенең мәкер укларын аның югары милли аң вә үзенчәлекле хиссият чыганагы өлкәләренә (тел, моң, рух, тарих, милли театр һ.б.) ата. Әйтик, татар хисабыннан зур чыгымнар белән үткәрелә торган «Үзгәреш җиле» фестивале (музыкаль җитәкчесе – В.Эйленкриг), асылда, татар моңын халык җырларын бозу аша эчтән җимерүне максат итә. Әле җитмәсә, анда имгәтелгән җырлар татарлар өчен радио һәм ТВ аша тапшырыла торган концерт программаларына да кертелә.

Янә бер мисал. В.Мединский үзенең мәдәният министры булып эшләгәндә язган «Мифы о русской демократии, грязи и «тюрьме народов»» дигән китабында татарлар турында: «...никакой другой народ не воспринимался в народном сознании русских страшнее и хуже, чем татары. ... нет в народной памяти ни поляка, ни немца, ни шведа – такого же беспощадного «сосальщика» дани, насильника и убийцы», - дип язып чыкты. Моның өчен бу бәндә әлегә беркем алдында һәм бернинди дә җавап тотмады кебек. Игътибарны исә Казанда Камал театрының яңа бинасына чит-ят проектны сайлап алу һәм урынын үзәктән читтә билгеләү факты да җәлеп итә. Моның ялгыш адым булуы хакында архитектор А.Саттаров, халык язучысы М.Галиев һәм әдәбият белгече М.Хәбетдинованың дәлилле фикерләре белән килешергә кирәктер. Сәяси яктан бу адым Казан үзәген татар рухыннан арындыру булып та күренә. Бүген хәтта Казан Кремлендә килештерелгән кайбер проектлар да, әгәр ул татар рухын көчәйтүгә эшли икән, урынын алыштыра ала (Сөембикә һәйкәле, «Түбәтәй Tower» проекты һ.б.). Әйе, монда уйланырлык нәрсәләр бар.

Фоат УРАЗАЙ.

Театрлар дөньясында

Татарстан Хөкүмәтенең ковидка каршы чараларны җиңеләйтү турында карары үз көченә керде. Хәзер театрларда залны 100% тутырырга рөхсәт ителә. Тамашачыларга театрга керү өчен QR-кодлар да кирәк түгел.

Г. Камал театрының «Санаулы кичләр» спектакле башка күрсәтелмәскә мөмкин. Драматург Александр Володин текстларының хокук иясе аларны Россиядә кую рөхсәтен кире ала. Спектакль Камал театры сәхнәсендә 25 март һәм 16 апрель көннәрендә булырга тиеш.

Г.Камал театры «Татмедиа» акционерлык җәмгыяте һәм Татарстан Президенты карамагындагы Татар телен саклау һәм үстерү комиссиясе оештырган «Тамга» бәйгесенең «Татар телендә Ютуб-канал» номинациясендә бүләкләнде.

Республикада «Кино+театр» акциясе старт алды. Март аенда «Мир» кинотеатрында һәм республика кинотеатрларында ел дәвамында Камал театрының иң яхшы спектакльләре трансляцияләнәчәк. «Татаркино» оешмасы әлеге акция кысаларында «Мир» кинотеатрында күрсәтү өчен дүрт спектакльне сайлап алган.

К.Тинчурин театрының сәхнә ветераны, Татарстанның халык артисткасы Земфира Исхак кызы Досаева 85 нче яшендә вафат булды.

К.Тинчурин театры оркестры «Татар классик музыкасы җәүһәрләре» концертлар циклының чираттагысын тәкъдим итте. 1 март Таҗи Гыйззәт белән Җәүдәт Фәйзинең легендар спектакле – «Башмагым» музыкаль комедиясенең беренче куелышына 80 ел булды! Шул уңайдан театр артистлары, оркестры һәм Казан дәүләт консерваториясенең опера студиясе махсус концерт программасын әзерләде. Әлеге концертта «Башмагым» музыкаль комедиясенең төрле елларда куелган һәм яңгыраган, төрле редакцияләрдә булган спектакльләрдән өзекләр башкарылды.

Әтнә театрының кече залында Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан чыгарылган «Габдулла Тукай: тормышы һәм иҗаты» өчтомлыгы тәкъдим ителде.

Минзәлә театры Ярославльдә «РОЗОВФЕСТ» Бөтенроссия театр фестивалендә «Җинаять һәм җәза» спектаклен уйнады.

Әлмәт драма театры сәхнәсендә 28 мартта шәһәр һәм районның барлык театр актерлары (урам театры, курчак театры, буффонада театры, Әлмәт музыка көллияте театрлары) чыгыш ясаячак.

Санкт-Петербургның Сиринә Зиннурова җитәкчелегендәге «Былбыл» татар халык театры Флорид Бүләковның «Эх, күгәрченкәйләрем» спектаклен күрсәтте.

Быел «Тантана» республика театр премиясе 27 мартта Чаллы татар дәүләт драма театры сәхнәсеннән тапшырылачак.

Каһарманны Казахстан искә алды

Казахстанның Актүбә өлкәсендә Советлар Союзы Герое Гайнан Кормашны искә алдылар.

Гайнан Кормаш 1919 елда Казахстанның Актүбә өлкәсе Кобда районында туган. Мари АССРның Бәрәңге педагогика техникумын тәмамлаган. Сугышка кадәр Бәрәңге районы Куян авылында мөгаллим булып эшләгән. 1937 елда аны, кулак булуда гаепләп, комсомолдан куалар, бернича туганын кулга алалар. Шуңа күрә Гайнан Кормаш Куян авылыннан Актүбәгә китә, анда янә мәктәпкә урнаша. 1939 елда, хәрби хезмәткә чакырганда, ул инде мәктәп директоры була.

Актүбә өлкәсенең «Шатлык» татар-башкорт этномәдәни берләшмәсе ел саен Геройның туган көнендә искә алу чаралары үткәрә һәм үз якташларын хөрмәт белән искә ала. «Шатлык» этномәдәни берләшмәсе каршындагы якшәмбе мәктәбе аның исемен йөртә, Казахстанның Актүбә шәһәрендәге бер урамга Гайнан Кормаш исеме бирелгән.

Татарлар оста куллы

Бөтендөнья татар конгрессы оештырган «Оста куллы гүзәл затлар» конкурсы тәмамланды. Конкурсның максаты – халкыбызның сәләтле кешеләрен ачыклау, аларның кул эшләнмәләрен, пешергән милли ризыкларын, иҗатын таныту, милли үзаңны, милли рухны үстерү, кул эшләнмәләре арасында халкыбызның милли гореф-гадәтләренә туры килгән хезмәтләрне барлау иде.

Бәйге инстаграмда ике номинация буенча уздырылды: «Кул эшләнмәләре», «Тәмле булсын ашыгыз!». Конкурста 12 яшьтән өлкәнрәк булган хатын-кызлар, үсмер кызлар катнаша алды. Барлыгы 545 эш килде.

Конкурста Татарстан район-калаларынннан кала, Башкортстан Республикасы, Свердловск, Ульяновск, Омск, Пенза, Оренбург, Самара, Иркутск, Новосибирск, Төмән өлкәләре, Пермь крае, Санкт-Петербург шәһәре, Казахстан, Кыргызстан республикалары актив булды.

● **Бәйгедә җинүче Илизә Абдуллаева.**

Әлмәт музыкантларны җыя

14-19 мартта Әлмәт шәһәрендә Almet Music Lab музыкаль лабораториясе узачак. Бер атна эчендә 10 музыкант һәм шагыйрь белгечләр ярдәмендә татар телендә яңа музыкаль әсәрләр иҗат итәчәк.

«Композицияләр уен кораллары экспозициясендәге төрки коралларының тере тавышы белән яздырылачак. Лабораториядә татар телен белүче шагыйрьләр һәм төрле уен коралларында уйный белгән музыкантлар катнаша ала», — диде оештыручыларның берсе, музыкант Рәдиф Кашапов.

Аның сүзләренчә, лаборатория барышында барлык катнашучылар белән Татарстан һәм Башкортстаннан чакырылган этник музыка коралы белгечләре һәм кураторлар – этнограф һәм Казан консерваториясе доценты Геннадий Макаров, музыкаль продюсер Марат Фәйзуллин, төрки музыка коралы белгече Алмаз Әсхәдуллин һәм перкуссионист Эрик Марковский һ.б. эшләячәк. Төп этап алдыннан Милли китапханәдә барлык теләүчеләр өчен төрки музыка турындагы лекцияләр оештырыла.

Лаборатория кураторларының берсе Зөлфия Камалова Австралиядән онлайн-элемтәгә чыгып, катнашучыларга «world music» жанрындагы җырлар язу турында сөйләр дип көтелә.

Зилә МӨБӘРӘКШИНА.

«Мәдәни җомга» газетасына март аенда 2022 елның II яртысы еллыгы өчен ташламалы бәядән язылып куя аласыз. Татарстанда газетага язылу индексы – П2355. Язгы ыгы-зыгылы вакытка калдырмыйча, бүген үк язылып кую уңайлы да, отышлы да. Безнең белән бергә булыгыз!

1 нче биттә – Күп халыкларда муллык һәм тынычлык символы саналган күгәрчен. Фото: pixabay.com

«Тамга»лы булдылар

Интернетта татар телендә алып барыла торган иң яхшы проектлар өчен «Татмедиа» акционерлык җәмгыятенең «Тамга» премиясе тапшырылды.

«Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев сәламләү чыгышында рәхмәт сүзләрен әйтеп, «Киләчәктә дә татар мохитен, татар телен үстерик», – дип изге теләкләрен җиткерде.

● «Тамга» бүләген алган блогер Василий Ивановның сәхифәсен М.Әхмәтов та күзәтеп бара.

«Без, Интернетта татар телендә контент ясаучыларны җыеп, тамгалап чыгарга булдык. Безнең фестиваль оештыру хыялы да бар. Дәресләр, мастер-класслар да булыр дип уйлыйбыз. Социаль челтәрләр үзгәреп тора, тәҗрибә белән уртаклашу, аралашу, үсү өчен яңа мәйдан кирәк. Яшьләр тулысы белән Интернетта, татар телен популяр итәргә телибез икән, Интернетта булырга кирәк. Безне күреп башкалар да актив эшли башлады», – диде «Татмедиа» акционерлык җәмгыятенең генераль директоры Шамил Садыйков тантанада.

Татарстан Президенты карамагындагы Татар телен саклау һәм үстерү комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов фестиваль үткәрү фикерен хуплады. «Зур, матур, саллы, әҗере дә була торган форматта эшләргә кирәк. Блогерларның һәрберсе язылучыларның күңеленә керү юлын тапкан. Шулкадәр милли җанлы кешеләр бар икән, милләтнең, телнең киләчәге бар», – диде ул.

«Тамга» сыннарын тапшыру тантанасы Милли китапханәнең «Моң» театраль мәйданында узды. Җиңүчеләрне өч номинация – «Татарча Ютуб канал», «Инстаграмда милли аккаунт», "Татарлар ТикТокта» номинацияләрендә бүләкләделәр.

Җиңүчеләрне «Караш» төркеме, яшь җырчылар Илгиз Мөхетдинов, Әдилә Әхмәтова котлады.

Гөлүзә **ИБРАҺИМОВА.**

Туфан ага феномены

Халыкара язучылар көнендә Казан кооператив институтының Татар мәдәнияте үзәгендә «Туфан Миңнуллин феномены» дигән бәйгегә нәтиҗә ясалды.

Тантанага Нәҗибә Ихсанованың сеңлесе Роза Байбикова, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, Бөтендөнья татар конгрессының татар эшкуарлары белән эшләү бүлеге җитәкчесе Фәрит Уразаев, шагыйрьләр, укытучылар, китапханәчеләр, тәрбиячеләр, институт студентлары, укучылар, ата-аналар килгән иде. Төркия, Швеция, Лондон, Таллинда яшәүче татарлар онлайн катнашты.

Беренче урынны – Әлки районы Карга авылыннан татар теле һәм әдәбияты укытучысы Айгөл Сергеева, Казанның 402нче балалар бакчасы тәрбиячесе Рәйхана Юсупова алды. Икенче урын – Әлки районы үзәк китапханәсенең Туган якны өйрәнү һәм милли әдәбият бүлеге җитәкчесе Алсу Низамова, Казанның 208 нче балалар бакчасыннан Лилия Сәгъдиевага бирелде. Бәйгенең жюри рәисе – драматургның кызы, журналист Әлфия Миңнуллина-Юнысова барлык катнашучыларга, оештыручыларга рәхмәтләрен җиткерде. Конкурс җиңүчеләренә Евразия рәссамнар берлеге әгъзасы Гөлсем Хаҗиева иҗат иткән Туфан Миңнуллин портретлары бүләк ителде. Аларны рәссамның оныгы Диләрә Камалова тапшырды.

Казан кооператив институтының Татар мәдәнияте үзәге Т.Миңнуллинга багышланган чараларны икенче ел рәттән оештыра. Былтыр драматург хөрмәтенә искә алу кичәсе уздырылды. Быел үзенчәлекле конкурс игълан ителде.

«Чараларның формалары аерылса да, асылы үзгәрми. Алар, Туфан ага Миңнуллин язып калдырганча, татар телебезне, гореф-гадәтләребезне саклап калудан гыйбарәт. Т. Миңнуллин һәрвакыт татар теле, мәдәнияте, аның язмышы турында чыгышлар ясады, татар халкын дәүләт дәрәҗәсендә яклаган шәхес иде», – диде Татар мәдәнияте үзәге җитәкчесе Флюра Абдуллина.

Төркиядә яшәүче журналист Айзирәк Гәрәева Төркия театрларында да Т. Миңнуллин әсәрләрен куярга кирәклеген әйтте, Лондоннан Рамиль Миңнуллин, Швециядән Исмәгыйль Шаһгәрәев мондый чараларның татар телен, гореф-гадәтләрне саклаудагы әһәмиятенә тукталды. Таллиннан табибә Флюзә Хәйруллина Т. Миңнуллинның Эстониядәге сәфәре вакытындагы очрашуларын мавыктыргыч итеп сөйләде.

Чара Габдулла Тукайның «И туган тел» җырын берләктә башкару белән тәмамланды.

Театр эше күп юнәлешле булырга тиеш

Буа шәһәрендә профессиональ театр сәнгатен торгызуга 20 ел тулу уңаеннан, Татарстан мәдәният министры Ирада Әюпова республиканың әйдәп баручы сәхнә әһелләре белән театр өлкәсендә актуаль мәсьәләләр турында фикер алышу өчен Буа шәһәрендә түгәрәк өстәл уздырды.

«Татарстан театрларының тактик һәм стратегик үсеше» дип аталган түгәрәк өстәлнең төп темалары: драматургиядә яңа исемнәр ачу һәм репертуар сәясәте; гастроль һәм фестиваль эшчәнлеген үстерү; финанс системаны камилләштерү; театр өлкәсендә «Пушкин картасы»н куллануның нәтиҗәлелеген арттыру.

И. Әюпова чыгышыннан берничә өземтә:

«Театр – ул күп санлы иҗади кешеләргә талантларын ачарга мөмкинлек бирүче корал. Яшьләрне, актив сәнгать әһелләрен иҗади процессларга җәлеп итү юлы белән шул исәптән милли сәнгать кысаларында да без диалог төзи алабыз. Коллаборациянең ачык мисалы: А.Гыйләҗев исемендәге Яр Чаллы шәһәре театры. Бу яшьләр театры гына түгел, театр бинасында урнашкан Татарстан Язучылар берлеге бүлеге дә, ул хәзерге заман рәссамнарының хезмәтләрен күрсәтү урыны да, яшьләр бергәлекләре өчен мәйданчык та».

«Без Татарстан Республикасы театр әһелләре берлеге базасында учреждениеләрнең гастроль һәм фестиваль эшчәнлеге буенча хезмәттәшлек итү өчен мәйданчык ясарга тәкъдим итәбез. Бу күпчелек мәдәният учреждениеләре өчен оптималь карар булачак».

«Системалы исәпләү, бухгалтерлык эшчәнлеге аутсорсингы моңарчы булган хаталарны кабатламаска ярдәм итәчәк. Бүгенге көндә хокук бозуларның 80% – бухгалтерлык исәбен бозу. Система тулысынча ачык, бернине дә яшереп булмый. Бу учреждениеләрдә аларның эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен шартлар үзгәрәчәк дигән сүз түгел, бу барыннан да элек хаталарны минимальләштерү».

«Без мондый тегие яки бу чараны «Пушкин картасы» программасына кертү буенча программа таләпләре нигезендә зур эш алып барабыз. Әмма монда ике проблема бар: реаль тәкъдимгә кытлык һәм мәдәни куллану культурасының түбән булуы. Хәзерге буын үзенең көн тәртибендә театрга бару өчен 3 сәгать вакыт таба алмый. Шуңа күрә балаларны театраль, музей мәдәниятенә өйрәтергә кирәк. Шуннан соң гына балаларыбыз мәгънәле һәм образлар телен укырга өйрәнәчәк».

Уставка үзгәреш – заман таләбе

Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла берлекнең чираттан тыш съездында уставка кертеләчәк үзгәрешләр турында аңлатма бирде. Съезд 8 апрельгә билгеләнгән.

«Язучылар берлегенең уставы туксанынчы елларда кабул ителгән иде. Ул инде юридик яктан да искергән. Яңартылган устав проектын хәзер юристлар карый, бәлки, тагын нинидер үзгәртүләр кирәктер, хәзер анык кына әйтеп тә булмый», – диде рәис.

Уставта берлекнең Әлмәт һәм Чаллы бүлекләре беркетелмәгән, юридик хокуклары да булмаган. «Аларның хокукларын һәм бурычларын уставка кертергә телибез», – дип аңлатты ул.

Кворум булсын өчен, съездда Язучылар берлеге әгъзаларының 2/3 өлеше катнашырга тиеш. Язучыларның күбесе өлкән яшьтә булу сәбәпле бу съезд өчен кыенлыклар тудыра. Шуңа яңа вариантта кворум булсын өчен әгъзаларның 50 проценты +1 кеше булуы тәкъдим ителә.

«Онлайн катнашу мөмкинлеген дә уставка теркәдек, андый мөмкинлек тә каралмаган иде. Устав язылганда, ул пандемияләрне күз алдына да китермәгәннәр. Без үзгәрттек, әле бит әгъзаларның хуплавы кирәк», – диде Ркаил Зәйдулла.

Язучылар берлеге җитәкчелеге әдәбиятны популярлаштыруга зур өлеш керткән кешеләрне шәрәфле әгъза итеп алу тәкъдимен кертә. Ркаил Зәйдулла уставта взнос түләү пункты һәрвакыт булуын, ләкин беркайчан да түләнмәвен искәртте. Ул уставта мәсьәләнең каралуын һәм съездда күтәреләчәген әйтте.

Ул устав үзгәртүнең Россия берлекләре составына керү яки рәиснең эшләү срогын озайту өчен эшләнмәвен ассызыклады. «Рәис элеккечә ике срок кына эшли ала – моңа үзгәрешләр кертелми», – диде Р.Зәйдулла.

Рузилә **МӨХӘММӘТОВА.**

●Дөньяда нибары 252 генә ил булса да, барлыгы 7 меңләп тел һәм 40 мең чамасы диалект исәпләнә. Шул телләрнең 800 дән артыгы Папуа-Яңа Гвинеядә яшәүчеләрнеке.

●Үзара аралашу өчен 1887 елда уйлап чыгарылган халыкара ясалма телнең авторы – Варшава окулисты Лазарь Заменгоф, аның псевдонимы Эсперанто («Өметләнүче») булган, тел дә шулай атала.

●Һәркемгә мәгълүм @ билгесен руслар «собачка» дип атый, ивритта исә ул «штрудель», чех һәм словак телләрендә «маринадланган сельдь» дип атала, күпчелек исә әлеге символны «маймыл» дип йөртә.

●Бугенвиль утравындагы (Тын океанда) ротокас телендә 12 генә хәреф бар, бу – дөньяда иң кыска әлифба. Иң озын алфавит исә – Камбоджадагы кхмер телендә, ул 74 хәрефтән тора.

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

Ислам дине һәм татар әдәбияты

Әдәбиятның төп элементы – сүз, тел. Шуңа да аны еш кына сүз сәнгате дип йөртәләр. Моңа кадәр туран (һун), рун, уйгур һ.б. графикаларны кулланган халкыбыз ислам дине белән бергә гарәп язуын да кабул итә һәм аны соңгы дәверләргә кадәр куллана. Шунысы да гыйбрәтле: әчтәлекләре нинди булуына да карамастан, гарәп графикасындагы язмалар гомумән бездә шактый дәрәҗәдә изгеләштерелә дә. Аларны кадерсезләү гөнаһ та хисаплана. Мөселман тәгълиматының таралуы Идел-йортта, әби-бабаларыбыз арасында гарәп телен өйрәнү, үзләштерү белән бергә бара. Октябрь инкыйлабына кадәр бездә гарәп-фарсыча белү зыялылык, укымышлылыкның төп билгесе итеп тә каралган. Ислам дине, Коръән теле, бераздан фарсы, төрки телләре безгә Шәрык, Мөселман цивилизацияләрен кабул итәргә, үзләштерергә юл ача. Шуның тәэсирендә татар теленә күпләгән гарәп-фарсы сүзләре, шәкел-формалары керә һәм алар гасырлар дәвамында тәмам үзебезнең тел хәзинәсенә әверелә. Бу уңай белән бер хакыйкатьне дә искә төшерү урынлы. Кайвакыт соңгы дәвер укучыларыннан «элеккеге әсәрләрнең теле тиешенчә аңлашылып җитми» дигән сүзләр ишетергә туры килә. Болай әйтү өчен билгеле бер нигез бар. Элеккеге авторлар гарәп-фарсы сүзләрен шактый мул куллана, хәтта аерым юлларын, әсәрләрен шул телләрдә дә язып китә (Мәхмүд Болгари, Габдерәхим Утыз Имәни, Шәмседдин Зәки...). Әмма шуны хәтергә төшерү зарури: ул каләм әһелләре үз әсәрләрен шул чор аудиториясен күздә тотып иҗат иткән. Ә ул дәвер укучыларының күпчелеге исә иске татар телен, гарәп-фарсыны, «төрки»не яхшы белгән. Кызганыч ки, соңгы гасыр укучыларының төп өлеше ул сыйфатлардан мәхрүм. Хәтта үзенең туган телен – газиз татар телен белмәүчеләр дә артканнан-арта бара.

Ислам диненең әдәбиятка тәэсире Йосыф Баласагунлының «Котадгу белек» (1069), Әхмәд Йүгнәкинең «Һибәтел-хәкаик» (XII) кебек гомумтөрки ядкярләрдә үк күзәтелә. Мәшһүр Әхмәд Ясәви (вафаты 1166 елда), Сөләйман Бакырганый (үлеме 1186 сәнәдә) иҗатлары инде тулысы белән мөселман дине рухында. Авторлар Аллаһыны берлеген, бөеклеген данлый, үз укучыларын «Коръән» тәгълиматы, Мөхәммәд пәйгамбәр өйрәтмәләре нигезендә тәрбияләргә омтыла.

Мәгълүм ки, ислам кешеләрнең, күп кенә халыкларның рухи кыйммәтләренә, инсаннарның тормыш тәҗрибәсенә таянып туган һәм формалашкан. Каләм әһелләре өчен бу кыйммәтләр таяныч, төп терәк булып хезмәт иткән. Диннең бу төр гуманистик табигатенә мөнәсәбәттә әдипләр үз кавемнәренең, төбәкләрнең дә инсани, әхлакый тәҗрибәсен, идеалларын үз әсәрләренең тукымасына табигый, мантыйкый рәвештә кертеп җибәргән.

Шәрык сүз сәнгатендәге кебек, бездәге күләмлерәк әсәрләр еш кына Аллаһыга, пәйгамбәргә багышлаулар, аларга мактау («хәмдү-сәналәр») уку белән башланып китә. Бу Йосыф Баласагунлы, Кол Гали, Котб, Мөхәммәдъяр... кебек авторларның поэмаларында ачык күзәтелә.

«Кыйссаи Йосыф»тагы төп сюжетның, образларның «Коръән»нән алынып, автор тарафыннан эшкәртелүе гавамга яхшы таныш. Шушындый ук күренеш кайбер башка әсәрләр өчен дә хас. Мәсәлән, Алтын Урда чоры әдибе Рабгузыйның «Кыйссасел-әнбия» исемле күләмле китабы (1310) тулысы белән диярлек «Коръән»дәге сюжет-кыйссаларга корылган; андагы төп образ персонажларда да дини чыганаклар аркылы укучыларга билгеле.

Урта гасыр һәм XIX йөздәге күпчелек каләм ияләренең эшчәнлеге өчен күпкырлылык, күпвазифалылык хас. Алар, әдип-шагыйрь генә түгел, бер үк вакытта дин әһеле, галим, мәгърифәтче һәм җәмәгать эшлеклесе дә. Мәхмүд Болгари (1297-1360), Кол Шәриф (?-1552), Г.Утыз Имәни (1754-1834), Таҗеддин Ялчыгол (1768-1838) һ.б. бик күпләр - моның күркәм мисалы. Шунысы мөһим: алар язган әсәрләр еш кына төрле вазифаларны үти. Мәсәлән, ислам динендәге күп кенә гыйбрәтле факт-мәгълүматларны, сюжет-мотивларны, шул исәптән аять-хәдисләрне үз эчләренә алган «Нәһҗел-фәрадис» (1358), «Рисаләи Газизә» (1806) китаплары бер үк вакытта киң катлам укучыларның һәм әдәби-эстетик, һәм дини-әхлакый ихтыяҗларын да канәгатьләндерә. Т.Ялчыгол әсәренең Октябрь инкыйлабына кадәр күп тиражлар белән 40 мәртәбә басылуы, мәктәп-мәдрәсәләрдә уку-укыту әсбабы буларак өйрәнелүе үзе генә дә күп нәрсә хакында сөйли.

Мөселман галәмендә элек-электән Аллаһыны мәдехләгән, «Коръән»не зурлаган, Мөхәммәд пәйгамбәрнең тормышын һәм эшчәнлеген тасвирлаган күп әсәрләр иҗат ителә. Алар шактый дәрәҗәдә татар укучыларына да таныш була. Мәсәлән, Мөхәммәд Чәләбинең госманлы телендә язылган гаять күләмле «Мөхәммәдия» китабы (1449) безнең әби-бабаларыбыз тарафыннан яратып укыла. Ул Казанда күп мәртәбәләр басылып чыга. Бу төр язмалар татар дөньясында да шактый иҗат ителә. XIV-XV гасырларга нисбәт ителүче «Кыйссаи авык» дастанының үзәгендә Мөхәммәд пәйгамбәр образы. Аның игелек-шәфкатьлелеге аркасында хәтта тоткынлыкка эләккән аукыкыр кәҗәсе дә иреккә чыгарыла, балалары белән кавыша.

Әдәбиятта ислам проблемасы хакында сүз барганда, суфыйчылык мәсьәләсе дә үзенә игътибар сорый. Урта гасыр мөселман дөньясында киң таралган ислам диненең бик тә мөһим бер тармагын, өлкәсен тәшкил иткән бу идеологик күренеш төрки-татарларның иҗтимагый-социаль, аеруча рухи-мәдәни тормышында тирән эз калдырган. Авыр елларда, бигрәк тә милли-колониаль, чукындыру сәясәте котырынган чорларда ул халкыбыз өчен бер рухи терәк, туплану факторы да булып тора. Суфыйчылык белән сугарылган әсәрләрдә адәм баласының эчке дөньясына, уй-кичерешләренә, психологик халәтенә, иман-ышанычына аеруча игътибар ителә, дөнья мөнәсәбәтләре, яшәү мәгънәсе, үз-үзеңне әхлакый һәм инсани яктан камилләштерү, байлыкка, хакимияткә кызыкмау кебек мәсьәләләр үзәккә куела. Әхмәд Ясәви һәм Сөләйман Бакырганый, Хисам Кятиб һәм Өмми Кәмал, Кол Шәриф һәм Мәүла Колыйларның тирән эчтәлекле, уй-кичерешләргә бай, сәнгати яктан камил әсәрләре – төрки-татар дини-суфыйчылык әдәбиятының гүзәл сәхифәләре. Алардагы тел-стиль чаралары, образ-сурәтләр, фикри байлык соңгы дәвер әдипләре тарафыннан да иҗади рәвештә файдаланылды, дәвам итте. Бу аеруча Дәрдемәнд, Мәҗит Гафури, Габдулла Тукай һ.б. каләм әһелләренең әсәрләрендә ачык күренә.

Мөселман дине безнең әби-бабаларыбызны киң дөньяга чыгарга, үзләрен бай Шәрык галәменең тулы хокуклы әгъзалары итеп тоярга, гаҗәеп бай гарәп-фарсы рухи казанышлары, алар аркылы антик Грециянең, Һиндстанның рухи байлыклары белән танышырга мөмкинлек бирә. Ислам халкыбызның аерым милләт буларак оешуында, үсешендә, саклануында да гаять мөһим роль уйнаган. Юкка гына аны татарның бер канаты дип әйтмиләрдер.

Тарих шуны күрсәтә: безнең татарга беркайчан да җиңел булмаган. Дәүләтчелеген җуйганнан соңгы аның берничә гасырлык яшәеше – аеруча газаплы, афәтле чор. Әмма шуңа да карамастан, гаять зур югалтулар бәрабәренә булса да, ул үзенең барлыгын, милли асылын саклап кала. Монда да без, иң беренче чиратта, мөселман диненә, ислам рухлы хәзинәләребезгә, әдәбиятыбызга бурычлы.

Кызганыч ки, совет чорында дингә, милли асылга һөҗүм гаять көчәйде. Атеизм байрагы астында күп кенә рухи байлыкларыбыз юкка чыгарылды, йөзәрләгән иҗат әһелләребез шәхес культы корбаны булды, иҗтимагый-мәдәни тормыштан читләштерелде. Мең ел буе кулланылган гарәп графикасы әүвәл латин, аннан кирилл язуына алыштырылды. Бу исә бай рухи мирас, буыннар арасындагы бәйләнеш күперләрен утка ягу кебек булды. Совет җирлегендәге рәсми сәясәт нәтиҗәсендә халкыбызда милли нигилизм көчәйде, туган телгә, милли мәгарифкә игътибар бик нык кимеде, имансызлык, башка милләт сафларына күчү киң колач алды.

Әмма нинди генә кыенлыкларга да карамастан, халкыбызның шактый гына асыл уллары һәм кызлары үз милләтенә тугры калды, бу юнәлештә фидакярләрчә көрәште. Элекеге дини-милли яшәеш кануннарын һәм традицияләрен саклауда, буыннар арасындагы элемтәләрне дәвам иттерүдә аеруча мөһаҗирлектәге милләттәшләребез зур тырышлык күрсәтте. Финляндиядә, Кытайда, Төркиядә, Алманиядә һ.б. мәмләкәтләрдә нәшер ителгән китаплар, газета-журналлар - моның ачык дәлиле. Бу юнәлештә бигрәк тә Гаяз Исхакый, Хәсән Хәмидулла, Әхмәд Ләбиб Каран, Хөсәен Габдуш, Сания Гыйффәт һ.б. мәшһүр затлар күп хезмәт куйды.

* * *

Узган гасырның азаклары – XXI йөзнең башлары милләтебез тарихында күтәрелеш, яңарыш чоры булды. Халкыбыз үзенең аяныч хәлдә икәнлеген аңлый башлады. Үзгәртеп кору хәрәкәтенең көчле дулкыны нәтиҗәсендә милли мәгариф, рухи мирас мәсьәләләре үзәккә куелды һәм бу юнәлештә мөһим генә кайбер адымнар да ясалды. Шунысы аеруча әһәмиятле: халкыбыз үзенең мөселманлыгын нык тоя башлады. Мәчет-мәдрәсәләр ачылды, күптөрле дини, милли-мәдәни чаралар уздырылып тора.

Болгар дәүләтендә ислам диненең рәсми рәвештә кабул ителүенә быел, ягъни 2022 елда 1100 ел тула. Аңа хәзерлек шактый киң планда алып барыла. Ул халкыбызны туплауда, кавемара бәйләнешләрне ныгытуда, милли үзаңны үстерүдә бик тә мөһим чара булсын иде!

Бу уңай белән янә бер хакыйкатьне искә төшерү зарури. Болгар дәүләтенең 922 елда исламны кабул итүе – мөселман диненең Идел-йорттагы берничә гасыр буена таралу процессын тарихи-сәяси-иҗтимагый яктан ныгытуның әһәмиятле бер баскычы. Янә шунысы да бар: әйткәнебезчә, халкыбыз хәзәр, кыпчак, татар һ.б. этник элементлар кушылуыннан барлыкка килә. Болгарлар исә алар арасында мөһим бер компонент. Кызганыч ки, безнең кайбер «болгарчы»ларыбыз шул тарихи хакыйкатьне күрергә теләми. Халкыбызның татар буларак оешкан, аны бөтен дөньяга танытканн дәверен – Алтын Урда чорын күләгәдә калдырырга омтыла. Ә бит бу кодрәтле татар дәүләте Евразиянең зур мәйданнарын биләгән. Идел-йорт, Урал-Җаек буйлары, Көнбатыш Себер киңлекләре – бу мәмләкәтнең тарихи җирләре. Болгар дәвере, XIII гасырның урталарына кадәрге чорлар – халкыбызның татар булып оешуына хәзерлек процессының мөһим бер этабы. Элеккеге Болгар, Казан ханлыклары, хәзерге Татарстан җирләре күп гасырлар буе безнең әби-бабаларыбыз яшәгән гаять зур мәйданнарның аерым төбәкләре генә.

Соңгы елларда яшь парларның туйларын танылган артистлар катнашында шаулап-гөрләп үткәрү гадәткә керде. Әлбәттә, күп акчалар түгелә, яшьләргә фатир, машина кебек зур бүләкләр дә бирелә. Әмма ни гаҗәп, еш кына зур, хезмәт куеп тапкан акчалар хисабына уздырган туйлар яшьләргә бәхет китерми. Әллә ни озак та үтми, кияү белән киленнең аерылышулары турында күңелсез хәбәр килеп ирешә. Бу инде тормыш итү өчен затлы туйлар, кыйммәтле бүләкләрнең генә җитмәве турында сөйли. Загслардан килгән мәгълүматлар да куандырырлык түгел. Әле дистә ел элек кенә ике гаиләнең берсе аерылышуы турында әйтсәләр, хәзер бу саннарның елдан-ел арта баруын искәртәләр. Хәзер инде кайбер чыганакларга караганда аерылышучылар исәбе 80 процентка җитә.

Өйләнү – түгел сөйләнү

Шушы урында милли гореф-гадәтләребез нигезендә оешкан гаиләләребез искә төшә. Яшәү өчен иң авыр елларында да алар аерылышмаган, гаилә учагын сүндермичә, иңне-иңгә куеп тормыш иткән, балаларын үстергән. Аларның көнне төнгә ялгап эшләве, тырышлыгы бәрабәренә яшәешебез дә яхшыра барган.

Бөтендөнья татар конгрессы каршында эшләп килгән «Ак калфак» татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасы да ныклы гаиләләр булдыру мәсьәләсен алга куя. Азнакай шәһәрендә «Татарстанның көньяк-көнчыгыш районнарында яшәүче татар халкының гаилә-көнкүреш йолалары, фольклоры һәм халык сәнгатенең бүгенге торышы» дигән темага узган җыены да гаилә кору йолаларына багышланган иде. Анда «Ак калфак» оешмасының тугыз район бүлеге җитәкчеләре һәм ЗАГС бүлеге хезмәткәрләре катнашты. Кунакларны район башлыгы Марсель Шәйдуллин һәм төбәккә чираттагы эшлекле сәфәр белән килгән Россия Дәүләт Думасы депутаты Азат Ягъфәров сәламләде.

Татар халкы кызларын һәм улларын гаилә тормышына бик иртә – кече яшьтән үк әзерли башлаган. Ир бала 4-5 яшеннән чүкеч тотып әтисе янында кайнашкан, аңа тегесен-монысын китереп биргән, нәрсәнедер каккан, «төзәткән». Кызларны да 5-6 яшьтән аш-су пешерергә, чигәргә, тегәргә, бәйләргә өйрәтә башлаганнар. Кыз бала уклау белән әнисе янында кайнашкан, аңа токмач та кистергәннәр, кош телен дә, бәлешен дә пешерткәннәр. Кызның кулы шомарган. Чөнки, гадәттә, татар халкында туйның икенче көнендә үк «Килен токмачы» үткәрү йоласы бар. Азнакай районының мәдәният идарәсе җитәкчесе Гөлсинә Хафизова ул елларда кызларның инде 14-15 яшьләрендә чигүле кашагалар, сөлге, кулъяулык, мендәр тышлары тутырылган сандыгы әзер булуын да искә төшерде. Әмма соңгы елларда кызларыбызны килен, улларыбызны гаилә башлыгы итеп тәрбияләүдәге, кыз бирү, егет өйләндерүдәге гореф-гадәтләр дә югала бара. Алай гына да түгел, баланы артык иркәләү, аны гаиләдә туган авырлыклардан саклау башланды. Бүген татар халкының буыннан-буынга тапшырылып килгән өлкәннәргә изге мөнәсәбәт, «ата-ана хакы» дигән төшенчәләр кимеп, югалып баруы борчуга сала. Хәзер егет-кызларның күбесе хәтта җәмәгать транспортында басып барган өлкән яшьтәге кешегә яки балага урын бирә белми. Ә инде берәр тәнкыйть сүзе әйтелсә, бише белән җавап кайтарыла.

Соңгы елларда Бөтендөнья татар конгрессы каршында эшли торган «Ак калфак» татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасы бу вәзгыятьтә хәлне үзгәртергә тырыша. Ул әлеге мәсьәләгә ата-аналарның игътибарын җәлеп итү ниятеннән «Татар кызчыгы», «Татар малае» конкурсларын үткәрә башлады. Анда баланы кече яшьтән эшкә өйрәтүгә игътибар юнәлтелә. Быел Россиякүләм конкурста 27 мең бала, башкача әйтсәк, гаилә катнашкан. Казанда 200 баладан 16сын сайлап алганнар. Районнардагы оешмалардан да шулай эшләү таләп ителә. Бәйге башта балалар бакчаларында башланып, бу эшкә ата-аналар җәлеп ителүе мәслихәт. Кызлар-малайларның әби-бабаларын да белүен, әти-әниләре белән ясаган шәҗәрәләрен дә аңлата алуы сорала. Шул ук вакытта балаларның йорттагы кайбер эшләрне үти белүе әһәмиятле. Аннары Бөтендөнья татар хатын-кызлары оешмасы 9-11 сыйныфларда һәм көллиятләрнең 1-2 курсларында белем алучы кызлар арасында «Татар кызы» конкурсын уздыра. Бу инде кызларга, ягъни булачак киленнәргә карата таләпләрне барлык укытучылар, ата-аналарның белүенә дә китерә.

Бу урында Кадрия Идрисова хәзерге ата-аналарның, җитеп килгән кызларын да, балага санап, алар белән кечкенәдән эшләмәүләрен дә искәртте. Әгәр бала үз туган ягындагы язучы яки берәр галимнән һ.б. танылган кешеләрдән бихәбәр икән, монда иң әүвәл ата-ана гаепле. Чынлыкта да яшьләрнең шактые районнарның үзендә яшәп иҗат итүче әдәбият һәм сәнгать әһелләрен белми.

Кызларыбызның - милләтебезнең булачак аналарының фикерләве дә бик гаҗәп. Кадрия Идрисова бу уңайдан былтыр уздырылган һәм 28 яшькә кадәрге кызлар катнашкан «Татар кызы» конкурсына бәйле кичерешләре белән дә уртаклашты. Бәйгегә әзерлек барышында «Ак калфак» җитәкчесенә кызлар белән әңгәмә корырга туры килгән. Ул алардан «Егетегез сезне очрашуга чакыргач, ярты сәгать соңга калырга туры килә икән, телефоннан шалтыратып, бу хакта хәбәр итәсезме?» – дип сораган. Ул шунда «Юк, без – алиһәләр, ни өчен акланырга тиеш? Көтсен!» – дигән сүзләр ишетә. «Егетегез сезгә төп йортта, кайнана-кайната янында яшәячәгегезне әйтсә?..» дигән сорауга да булачак киленнәр «Нинди кайнана белән тору ул?» —дип җаваплый.

Кадрия Рәис кызы аларга һәрнәрсәнең ике ягы бар икәнен, кайнана белән яшәүнең ямь-сәгадәтен, эшкә тыныч күңел белән чыгып китү, кайтуларына ашарга әзер, өйләренең җыештырулы, балаларының караулы булуы кебек уңайлыкларын аңлата.

Гадәттә, гаилә кору мәшәкате элекке чорда йортка кәләш йортына сул аягындагы баласын чыгарып, икенчесен читек эченә кертеп кигән яучы килүдән башланган. Ул капкадан килеп керү белән, аңа, бер алдына, бер артына төшеп, хөрмәт күрсәтелгән. Аңа сөлге тоттырып җибәрү кызның ризалыгын алу булып исәпләнгән. Хәзер бу гореф-гадәт сакланмаган, кызны сорарга егетнең әти-әнисе, башкода килә. Гаиләләрне ныгытуда яучыларның әһәмияте дә ассызыкланды. Сарман районы «Ак калфак» оешмасы җитәкчесе Эльмира Салихова аларның, кызларны димләргә барганчы, яшьләрнең нәсел-нәсәбен, холык-фигылен әйбәтләп өйрәнүен әйтте. Яучылар, егет белән кыз һәръяклап бер-берсенә туры килгәндә генә, димче булып барган. Хәзер яшьләрнең күбесе ике якның нәселләрен белмичә кавыша, гаиләдәге күп кенә каршылыклар шуның нәтиҗәсендә дә килеп чыга, еш кына аерылышуларга китерә. Шуңа күрә җыенда яучылык эшен кайтару мәсьәләсе дә күтәрелде. Туй алып баручылар да яшьләргә юнәлеш бирүдә әһәмиятле роль башкара. Алар белән дә алдан барысы да килешенгән булуы кирәк.

Форумда катнашкан тугыз район вәкилләре үз җирлекләрендә сакланып калган йолалар һәм гореф-гадәтләр белән таныштырды. Әйтик, Баулы районында сакланып калган «Кода-кодагыйлар мунчасы» турындагы йола бик кызыксынып кабул ителде. Бу якта мунчага кунакларны, кода-кодагыйларны җырлап-биеп арба яисә чанада алып бару, аннары каршы алуларны бик күңелле итеп оештыралар.

Форумга килгән кунаклар Азнакай районы унганнарының кул эшләре күргәзмәсе белән дә танышты. Соңыннан Әсәй авылының халык исемен йөртүче «Өммегөлсем», Таллыбүләк авылы халык фольклор ансамбльләре, катнашында кыз бирү, бәби чәе уздыру кебек йолалар күренешен, Россиянең атказанган халык коллективы «Җанашым» чыгышын карады.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотолары.

БЕРӘГӘЙЛЕ БЕРГӘЛЕК

Гел бергә без: бергәлектән беркем туймас,
Туйганда да туйганлыкны беркем тоймас.

Эштә – бергә, тышта – бергә, бергәләшеп,
Ара-тирә аралашып, тиргәләшеп;
Менә-менә чыгабыз, дип, такыр юлга,
Кичелгәндер җиде диңгез, кырык елга.

Бер өстәлдә ашыйбыз без качып-посып,
Һушлангач та язылмый кул кашык кысып...
Тел кычытса, үткәрәбез колак кашып,
Аерым-аерым яшибез без кочаклашып...

Ике тәкә башы, имеш, бер Казанда –
Без сыябыз, үч калмый ул үксез канда...

НИ БЕРЕНЧЕЛ?

Иң башта булган, диләр, берни булмаган бер заман, –
Аптырыйм да, шул заманга әйләнеп кайтам һаман.

Файдасы нидә бу мәхлук черкинең?
Дисәләр, ошбу сорауга, чур, тимим, –
Бер шигырь яздым менә хет, ичмасам,
Йокысыз үткәрдем төнне чөнки мин...

БУ!

Бу – безнең йорт, бусы – безнең бакча,
Тегеләре – хатын, балалар!
Хатын хаклы, нәрсә эшләсә дә...
Ә балалар инде – бал алар.

Бу – күршеләр Тәнре хакын хаклар,
Читләр дә бар, бераз читтәрәк!
Күршеләрнең күршесеннән кайчак
Якынрак кебек чит гарәп...

Бу – зур урам, карап торсаң болай,
Зур түгел дә кебек күренә!
Бушап калган урамнарны күргәч,
Төшенәсең зурлык серенә.

СӘЯСӘТ

Уңнар белән уңга барыйм, дисәң,
Сулагайлар болгый сулларын;
Әллә кемнәр тагын, әллә кайдан
Күрсәтмәкче туры юл барын.

Уңнар кайчак сулга килеп чыга,
Ә суллары уңга каера:
Анархия – тәртип анасы, дип,
Тотыналар тагын баерга...

Карап торам,
каргап торам, дисәм,
Каргамыйм да, торам аптырап:
Һәммәсе дә илне илиләр бит,
Һәр яшәлгән көнгә хак сорап.

Сәясиләр сырып алды җирне –
Яше, карты, яңа туганы:
Капкалары шул ук – безнең капка,
Уеннар шул ук – туп аның...

Данис ХӘЙРУЛЛИН

Нигә синҗа җәйгорларның җиде төре, Үз юлыңнан тәпилә син эре-эре...

Ә чынында, ул заманның булмаган, ди, үзе дә, –
Ул, имеш, кемдер, берәүнең күренгән тик күзенә.

И эзлим, эзгә салмактан, шул башлангычның башын, –
Кубармак булам мәңге кубарылмас вакыт ташын.

Нәрсә булган ул беренчел – төшме, өнме, вакытмы, –
Күккә кем сипкән ул учлап хисапсыз вак-вак утны?

Чәчрәгән бер чаткысыннан җиргә төшкән яктылык,
Шул көннән калган, имеш, җир безнең туган як булып.

Тукта! ни, нәрсә беренчел? – белү иде бит сүз башым,
Инде тәмамлыйм, җитмәгәч сүз башына үз башым!

СУРӘТ

Һич иман юк имансызда,бер бөртек иман заты:
Юләрлеккә ни җитә, дип, яшәү, ди, иң ансаты.

Юк аерма: көн ни, төн ни – аңа бар да бербөтен;
Бер битендә төн биесә, пәри ялый бер битен.

Имансызлар – иман, диеп, сүз башласа – түз, гареш;
Көт тә тор күкләр күтәрә алмаслык бер үзгәреш!

Күпме ул иман сатканнар – сансыздыр, китсәң санап.
Очсалар да кош түгел алар, зәгыйфь бер ярканат!

БУШАНУ

Юк бу җирдә беркемем, бер җан кешем, –
Бар да юрый өнендә күргән төшен;
Ник хәят, чыгар урында бер аять,
Бу көндә батты җанга азау тешең?

Аһ, туйдым мин, бер кабым җир калмады,
Җан азыгым кайсы азгын ялмады?
Сүнде рухым, кипте дәртем чишмәсе,
Булса да фани бакчам шыр алмалы.

Кем – бу җирдә, нигә мин, ник торам мин?
Ни чәчтем, кыямәт көн ни урам мин?
Аһ, күңлем кошы талпына тар чатта,
Шат чакта, юкса, үзем бер урам мин.

Әйтте Кем: – Елак, һәмишә, гөл дә син,
Фанилыкта догалан вә көл дә син,
Ашыгып какма ахирәт ишеген –
Туйсаң да йөрүдән киеп хөллә, син! –

Күр! әнә, вирус үрчи көлә-көлә...
Җил исә, җиләк-җимеш җитеп килә:
Бар да шат, берсе зарланмый берсенә-
Шайтанга җитми җирдә, кеше илә!

Бакчы син: китте уйлар, кипте уйлар,
Турайды кабат уйдан сынган буйлар:
Тор! димен, тартам үземне якадан, –
Юк, бүген түгел әле соңгы туйлар...

ХӘЕРСЕЗ КИҢӘШЛӘР

Нигә синҗа җәйгорларның җиде төре,
Үз юлыңнан тәпилә син эре-эре:
Күз күтәреп караса да кайсыбере,
Күрмәмешкә салышкан бул салкын гына!

Миннән башка миндәй кеше юк, дип йөр син:
Акыллы баш акыл сорап сиңа керсен!
Көмешләре, бакырлары читтә торсын –
Тиңдәш булсын сиңа бары алтын гына!

Кем ул сиңа шәфәгатьсез Шәвәлиләр,
Тәнарәтсез шәп Галиләр, шәп Вәлиләр? –
Исемеңне тел астында әвәлиләр,
Үзләреннән берәр чирек калкын гына.

Үз юлыңны сайлагансың – бар да бар син:
Нишләсәң дә, юкка – юк син, баргa – бар син!
Очалармы? – очканга да шул ук ясин...
Ә син очма, канат җилпеп талпын гына!

Ара-тирә үзең дә ал дулаштырып,
Ач бүредәй усалланып, улаштырып.
Инде тәмам тынычланып калыйм, дисәң,
Бутейкоча* өзек-өзек сулаштырып...

Нигә синҗа җәйгорларның җиде төре,
Үз юлыңнан тәпилә син эре-эре!
Киңәш капчыгын кем ачты, дисә кемдер:
Юк – мин, димә – ачты, диген, бер ач бүре...

**Бутейко К. П. – тирән сулыш алу методикасын эшләгән галим.*

ЧЕРКИЛЕ ТӨН

Зур түгел ул кечкенә, кеп-кечкенә,
Булса да булыр өйдә бер өч кенә:
Юк йокы, качты йокы, очты йокы –
Бирсәнә черки куарга көч кенә.

Без куабыз, ул качадыр, качышлы
Уйнау ымлап үзара чышлы-пышлы:
Әнә ул, менә оча, кунды – үтер!
Юктыр гөнаһ бәргәнгә дәһри кошны...

Тын гына килсә бер хәл, килә безләп,
Башта ук дошманлашып, үлем эзләп,
Өнеңне алмак, төнеңне кыскартып, –
Берәү дә җитә, кирәк түгел йөзләп.

Бу – ак дөнья!
Карасы да бардыр,
Барасы да бардыр ул якка…
Бәлки әле гел кара да булмас –
Кереп торса азан колакка.

Бу – халыклар! –
алфавитлары бар.
Балыкларга ник юк?
Сәер бу!
Әйтте Күкләр: – Авызыңны үлчәп
Ачар өчен биргән хәер бу!

ПАРЛЫЛЫК

Төн белән көн алышынып тора,
Иң беренче төнме, көнме туган?
Иң беренче, дигән төшенчәгә
Иң беренче булып төшкән томан.

Чебеш булмас йомыркасыз, мәгълүм,
Йомыркасы булмас тавыкларсыз.
Беренчесе икенчегә пар ул,
Бернәрсә юк бу дөньяда парсыз.

Парсыз – Берәү!
Берәү генә парсыз –
Парлы-парлы хәят яратучы.
Һәр гамәле тылсым – ач Коръәнне,
Рәхмәт укы Аңа парлап учың!

КИСӘТҮ

Өйрәнегез!
Өйрәнегез Мине!!
Мин – галактикалар, галәмнәр!!!
Ә сез бары уйлар тулгагыннан
Уйлап чыгарылган Галләмнәр...

Янар тауга яулык ыргыттым да,
Чак суыттым сезгә ут шарын.
Шул кабыкны бүлешәсез һаман,
Кешеләрем – кыргый мутларым!

Кырык мирне кырмыскадай сиптем –
Кавем саен тиеш бер өем:
Күршенекен нигә талап алу,
Үзең төзеп, үзең кер идең!

Фәрештәләр гел кабатлап тора:
Бик азынды, диеп, затыгыз.
Яулык читен бераз тарткаласам,
Юешләнер әле артыгыз...

БҮЛЕНГӘННЕ БҮРЕ АШАР

"Жырлыйм" белән "җырлаемны"
Сүзен сүзгә аерып,
Кем ул безнең бергәлекне
Үз ягына каерып,

Кайры тунның эчен тышка
Әйләндереп масая?
Без барыбыз бер ятьмәдә:
Уен, муен, баш, аяк...

Кем аера сыерыннан
"Бодау" белән "бозауны"?
Сөтнең тәме китеп бара –
Басу тулып боз яуды...

Әнкәй типтәр сөйләшеннән,
Әткәем Казан ягы:
Чып-чын татар булмыйча мин,
Йә кем булыйм соң тагын?

Башкорт та безгә бик якын,
Туган тиеш, ди, әни.
Бу арада башкаем да
Әйләнгәли әллә ни.

Җырлыйм белән җырлаемны
Сүзен сүзгә аерып,
Кем ул анда куш тамырны
Аермакчы каерып?

МӘЧЕ

Үземнеке үлде! Күршенеке
Йөри хәзер капка башыннан.
Калган малга хуҗа табыла ул –
Авыз итә "кит-кат" ашыннан.

Тамак туйгач кит – кит инде! дисәм,
Анда-монда тамга сала да,
"Калхузник" дип, күзгә карый, малай,
Китеп барган кебек калага...

– Тычкан туе кубарылса, абзый,
Ялынырсың әле, янәсе.
Яшәп яту әле менә шулай
Ата мәче белән ярәшеп.

Сездә – белмим, бездә һәр көн шулай,
Мәче белән бергә ата таң.
Үзеңнекен жуйсаң гел шулай ул –
Күрше йөнтәсләрен ашатам!

Чаллы.

ГЕНШТАБТА –

● 10 нчы кавалерия дивизия штабы башлыгы Ш. Гыйниятуллин (сулда) һәм дивизия командиры А.Д. Кулешов. Пятигорск. 1932 ел.

(Дәвамы. Башы 8 нче санда).

Туры сүзле кызыл командирга бәйле маҗаралы хәлләр моның белән генә тәмамланмый әле. 1924 елның 14 гыйнварында Бохара республикасының Хәрби-революцион трибуналы каршындагы хәрби секция Бохара уку кавалерия полкы командиры Шакир Гыйниятуллинны 8 айга каланың төзәтү йортына ябарга хөкем итә. Сәбәбе – 1923 елның 7 ноябрендә, җитди җинаятьләр кылуда гаепләнгән полкның элемтә башлыгы Ганинны кулга алган вакытта командирның гамьсезлек күрсәтүе нәтиҗәсендә, аның качып китүе. Әмма «җинаять» риясыз рәвештә кылынган дип табыла, хәрби өлкәдәге уңышлары да исәпкә алына һәм аны шартлы рәвештә хөкемгә тартып, Бохара армиясе штабына озаталар. Анда исә бар да уңай хәл ителә: ике Кызыл Байрак (№208, 12.10.1922 һәм №147, 4.10.1923), Бохара республикасының II һәм III дәрәҗә Кызыл Йолдыз орденнары белән бүләкләнгән кыю командирны Новочеркасский каласындагы Кызыл Байраклы команда составын камилләштерү кавалерия курсларына укырга җибәрәләр.

1926 елның сентябрендә курсларны уңышлы тәмамлаган Шакир Гыйниятуллин Урта Азия хәрби округына юллама ала һәм 7 нче Төркестан кавалерия бригадасы составындагы 80 нче кавалерия полкы командиры итеп билгеләнә. Аннары Яков Мелькумов командалык иткән 8 нче Төркестан кавалерия бригадасының 84 нче кавалерия полкының штаб башлыгы вазифасын башкара һәм шул ук бригаданың чик буендагы Кушка кирмәнендә тупланган 83 нче кавалерия полкы белән командалык итә. Зур хәрби тәҗрибә туплаган Шакир Гыйниятуллин 1928 елның октябреннән 1931 елның апреленә чаклы М.В.Фрунзе исемендәге Хәрби академиянең төп факультетында укый. Татарларга карата һәрвакыт хәерхаһлы булган Михаил Фрунзе исемендәге академияне иң яхшы билгеләргә генә тәмамлаган Шакир Гыйниятуллинның чираттагы хезмәт иткән урыны – Төньяк-Кавказ хәрби округы. Биредә ул, 6 кавалерия полкын, атлы-артиллерия дивизионын, саперлар һәм элемтә эскадроннары берләштергән 10 нчы Төньяк-Кавказ кавалерия дивизиясенең штаб башлыгы вазифасына билгеләнә.

РККАда кертелгән тәртип буенча, академиядә алган белемнәрен 2 ел дәвамында практикада чарлаган Шакир Гыйниятуллин хезмәтен хәрби разведкада дәвам иттерә. Кызыл Армиянең Разведка идарәсе карамагына җибәрелгән кыю командир әүвәл Монголиядә хәрби киңәшче вазифасына керешә, куелган бурыч – бер яктан Япония милитаризмы, икенче яктан Кытай дәүләте басымы тынгы бирмәгән илнең армиясен оештыруда ярдәм итү. Монголия армиясен оештыру өчен көчен кызганмаган майор Шакир Гыйниятуллинның 10 нчы Төньяк-Кавказ кавалерия дивизиясендә хезмәт иткән чагында алган тәҗрибәсе бик нык ярап куя. Чөнки 1932 елда дивизиянең аерым автобронеэскадроны базасында механикалаштырылган полк оештыруның һәм аны хәрби әзерлек хәленә җиткерүнең бөтен авырлыклары штаб башлыгы иңнәренә төшә. Гаскәрләрне механикалаштыру ихтыяҗы Монголия армиясе өчен дә ят булмый һәм бу юнәлештә Гыйниятуллин кебек киңәшчеләр керткән өлешне бәһаләп бетергесез. Дүрт елдан Монголиянең Поляр Йолдыз ордены белән бүләкләнгән милләттәшебез туган илгә әйләнеп кайта һәм 1937 елның февраленнән алып 1938 елның сентябренә чаклы Разведка идарәсенең 9 нчы бүлекчәсе (монгол-шиңган) башлыгы вазифасында хезмәтен дәвам иттерә. 1938–1939 елларда полковник Гыйниятуллин Генераль штабның Хәрби академиясендә укый. Милләттәшебез биредә дә кыюлыгы, кискен хәлләрдә куркып калмавы белән курсташларының ихтирамын казана.

Шул җәһәттән, гаделсез кыерсытылган Кырым татарлары мәнфәгатьләрен яклаган диссидент-генерал Петр Григоренко истәлекләреннән өземтә китерү урынлы булыр: «Безнең курста кулга алулар булмады. Бездә аңа үсәргә һәм җәелергә мөмкинлек бирмәделәр. Без моның өчен ике кешегә: безнең курсның партоешма секретаре майор Сафоновка һәм шул ук оешманың секретаре урынбасары полковник Гыйниятуллинга бурычлыбыз. Алар бу шайтан тегермәненең ничек тартканын бик яхшы аңлый иде».

Петр Григоренко шул утырыш турында үз истәлекләрендә шактый зур урын бирә һәм бу, туган – туганны, дус – дусны сатарга мәҗбүр ителгән ул каһәрле заманның сулышын тоярга, нечкәлекләрен сиземләргә ярдәм итә. Вакыйга Гыйниятуллин белән бер курста укыган полковник Михаил Шарохинның партия оешмасына мөрәҗәгатенә бәйле рәвештә төенләнә. Михаил Николаевич үз мөрәҗәгатендә, беркатлылыгы белән, үзенең элегрәк халык дошманнары буларак кулга алынган кешеләр белән бергә хезмәт итүен, аралашуын ирештерә. Партбюро утырышында бу белдерүне көн тәртибенең «төрлеләр» өлешендә карыйлар һәм «исәпкә алырга» дигән карар чыгаралар. Әлбәттә инде, партбюро утырышында катнашкан академиянең үтә сизгер комиссары белән махсус бүлек башлыгы мондый «йомшак» карарга ризасызлык белдерми калмый. Әмма партбюро әгъзалары алардан конкрет фактлар таләп итә. Махсус бүлек башлыгы исә масаеп: «Мин үзем белгәннәрнең барысын да сезгә җиткерергә тиеш түгел», – дип белдерә. Шул чагында полковник Гыйниятуллин, махсус бүлек башлыгының партия оешмасына һәм аның җитәкчеләренә карата, партиягә каршы килә торган тәртибе һәм аның партбюроны мыскыллавы турындагы карар кертә. Моннан соң «особист»ның кикриге бик тиз шиңә һәм ул гафу үтенә башлый. Әмма, шуңа да карамастан, карар кабул ителә. Бу вакыйга эзсез үтми: бераздан махсус бүлек башлыгы партия линиясе буенча шелтә ала һәм академиядән куыла.

1939 елның августында Генштаб академиясен бик яхшы билгеләренә генә тәмамлаган полковник Шакир Гыйниятуллинны яңа вазифа көтә: бу юлы аны кабат Новочеркасск каласына җибәрәләр һәм үзе укыган ККУКСка укыту бүлеге башлыгы итеп куялар. Эш сөючән, тырыш, чырыш, хәрби өлкәдә бай теоретик һәм практик тәҗрибә туплаган полковник Гыйниятуллинга Халык оборона комиссары Советлар Союзы Маршалы К.Е.Ворошиловның яшерен Боерыгы (№01705) белән 1940 елның 25 апрелендә комбриг чины бирелә, тагын 40 көннән ул инде – генерал-майор чинында. 948 хәрби җитәкчегә генераллар чины бирү турында 1940 елның 4 июнендә чыккан Карарны (№945) Халык комиссарлары советы рәисе Вячеслав Молотов һәм Советта эшләр башкаручы Михаил Холомов имзалаган. Күп чыганакларда, шул исәптән, «Хәрби разведка энциклопедиясе» хезмәтендә генерал-майор Шакир Гыйниятуллинның 1941 елның ноябрендә 58 нче армиянең штаб башлыгы итеп билгеләнүе күрсәтелә.

58 нче армияне оештыруда катнашкан генерал Гыйниятуллинны, сугышның беренче елы тәмамланып килгәндә, Генштабка күчерәләр һәм, 1939 елның октябрендә 1 нче бүлек (оператив) базасында оешкан Оператив идарәнең Ерак Көнчыгыш бүлеге башлыгы вазифасына билгелиләр.Күп яуларда сыналган һәм ике хәрби академия тәмамлаган Ш.Гыйниятуллинны Ставка өчен Генштабның оператив сводкаларын әзерләүгә җәлеп ителүе дә тарихи чыганакларда теркәлеп калган. Мисал өчен, 1942 елның 12 май көне иртәсенә әзерләнгән 132 нче санлы сводканы (ЦАМО. Ф. 28(16). Оп. 1072сс. Д. 481г. Л. 90 – 96) беренче булып Генштабның Оператив идарәсе башлыгы урынбасары вазифасын башкаручы генерал-майор Шакир Гыйниятуллин имзалаган. Икенче имза – идарәнең бригада комиссары чинындагы хәрби комиссары Иван Рыжковныкы. 24 июнь көнендәге 175 нче санлы сводкага да (ЦАМО. Ф. 28 (16). Оп. 1072. Д. 481д. Л. 203-209) Гыйниятуллин белән Рыжков имзалары тарих өчен ташка басылып калган. 1942 елның 30 июненнән алып 4 июлгә чаклы һәм 6–13 июль көннәрендә Ставка белән Сталин өчен әзерләнгән сводкаларга (№181–185, №187–194) кул куючылар да – Шакир Нигъмәтулла улы белән Иван Николаевич.

Тарихи чыганакларда расланганча, генерал Гыйниятуллин шактый вакыт Оператив идарә башлыгы вазифасын да башкарган һәм Ставкага барып, Сталин алдында докладлар ясаган. Бу исә гаҗәеп дәрәҗәдә авыр һәм җаваплы шөгыль. 1941 ел тәмамланып килгәндә, гаскәрләр белән даими элемтә урнаштыру максатларыннан чыгып, Генштаб үзенең Оператив идарәсе хезмәткәрләреннән торучы махсус штаб офицерлары төркеме оештыра. Шунысы хак: генерал-майор Ш.Гыйниятуллинның Генштабта алып барган алдагы эшчәнлеге әлеге төркем белән турыдан-туры бәйле. Ягъни Якын Көнчыгыш юнәлеше башлыгы, Оператив идарә башлыгы урынбасары һәм вакытлыча шул идарәнең башлыгы вазифаларын башкарган милләттәшебезнең Генштабта ирешкән үрләре болар белән генә чикләнми. Тарихи чыганакларда, аның офицерлар корпусының җитәкчесе итеп үрләтелүе дә ташка басылган. Бу турыда үз истәлекләрендә генерал Штеменко яза: «Генераль штабның офицерлар төркеме... турында да искә алмый калалмыйм. Ул төркем 1941 елда ук оешты һәм баштагы мәлне шактый күп санлы иде...

Операторларның әзерлекле кадрлары арасында югалтулар чамасыз күп булу сәбәпле, Генштаб җитәкчелеге гаскәрләр белән элемтә тоту өчен махсус командирлар төркеме оештырырга мәҗбүр булды. Әүвәл алар Оператив идарә карамагында иде, ә соңрак Б.М.Шапошников тәкъдиме белән аларны бездән алдылар һәм мөстәкыйль төркем итеп үзгәрттеләр. Ставка ул төркемне Генераль штабның офицерлар корпусы дип атады. Шунысы әһәмияткә ия: Кызыл Армия тарихында беренче мәртәбә «офицер» сүзе кулланылды... Генштабның офицерлар корпусына җитәкче итеп гаять дәрәҗәдә намуслы һәм эш сөючән генерал-майор Н.И.Дубинин билгеләнде. Алга таба аны Оператив идарәнең икенче бер ветераны генерал-майор Ш.Н.Гыйниятуллин алыштырды. Аларның икесенең дә сәясәт буенча урынбасарлары вазифасын генерал-майор Ф.Т.Перегудов башкарды» (Штеменко С.М. Генеральный штаб в годы войны. Кн. 1... Курс. хезм.).

Сүз уңаеннан, Офицерлар корпусында тагын бер татар командиры хезмәт итүен ассызыклап үтү артык гамәл булмас. Ул – Башкортстанның Илеш районына керүче Төкәйтамак авылында туган, исеме татар колагына бераз ятрак тоелган Шәрхаб Шәйхразиев. Орден һәм медальләр белән бүләкләнгән документларда аның армиягә 1933 елның 4 ноябрендә Туймазы каласындагы хәрби комиссариаттан чакырылуы күрсәтелә. Бөек Ватан сугышында Кызыл Байрак, I дәрәҗә Ватан

ТАТАР ГЕНЕРАЛЫ

● Хатыны һәм кызы белән Мәскәүдә.

сугышы, ике Кызыл Йолдыз орденнары һәм медальләр белән бүләкләнгән майор Шәйхразиев 1957 елның 23 августында полковник чинында отставкага чыга. 1949 елда – Кызыл Йолдыз, 1954 елда Кызыл Байрак орденнары белән бүләкләнүе мәгълүм. 1943 елның 19 октябрендә Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләү документында майор Шәйхразиевның Төньяк-Көнбатыш юнәлештә Генштаб офицеры вазифасында булуы раслана. Аннары шул ук вазифада 4 нче Украина фронтында хәрби бурыч үти. 1945 елның 17 мартында 4 нче Украина фронтының Кадрлар бүлеге башлыгы полковник Федор Григорьевич Коломбет 5 хәрбигә «Мәскәүне саклаган өчен» медале тапшыру турындагы Актны имзалый. Аларның берсе – ул чакта М.В.Фрунзе исемендәге Хәрби академия тыңлаучысы майор Шәрхаб Шәйхразиев.

Алда китерелгән архив чыганакларында, 1942 елның яз һәм җәй айларында генерал Гыйниятуллинның Оператив идарә башлыгы урынбасары вазифасын башкаруы ачыкланган иде. Шул елның 13-25 август көннәрендә аның Брянск һәм Воронеж фронтларында командировкада булуы мәгълүм. Күренә ки, ул Офицерлар төркеме башлыгы урынбасары булып билгеләнгәч тә бик еш фронтларга чыга. 1943 елның 4 февраленнән 1 апреленә кадәр аның Ерак Көнчыгышта булуы турында Генштабтагы Офицерлар төркеменең тагын бер әгъзасы полковник А.В.Крайнов тарих өчен үз истәлекләрендә теркәп калдырган. Нәкъ менә Алексей Васильевич генерал-майор Гыйниятуллинның бик нык чирли башлавын – паралич сугуын һәм бу авыр чирнең соңыннан аның үлеменә китерүен язып калдырган. Крайновтан аермалы буларак, бер генә тарихи чыганакта да Шакир Гыйниятуллинның шул яман чирдән интегүе турында мәгълүмат юк. Тәгаен бу, сугыш алдыннан ике югары хәрби академия тәмамлаган генералның карьера үсешенә дә тискәре йогынты ясамый калмагандыр. Генерал-майор Николай Дубинин Офицерлар корпусы башлыгы вазифасын 1943 елның ноябрь аена чаклы башкарган, ә аннары ул вазифада – генерал-майор Шакир Гыйниятуллин. Шунысы бар: авыруы сәбәпле, милләттәшебезгә ул вазифаны озаклап башкарырга туры килмәгәндер. Чөнки күп чыганакларның авторлары аның 1943 ел ахырыннан Кызыл Армиянең Баш кадрлар идарәсе карамагында булуы турында бәян итә һәм аннан соңгы язмышы мәгълүм булмавы турында искәртә.

1943 ел ахырында генерал Гыйниятуллин чынлап та Баш кадрлар идарәсе карамагында булганмы? Бәлки ул мизгел әллә ни озакка сузылмагандыр, яисә андый хәл бөтенләй булмагандыр? Һәрхәлдә:«Аннан соңгы язмышы билгеле түгел», – дип белдерүче авторлар белән ризалашмаска туры килә. Чөнки Ш.Гыйниятуллинның 1944 елда Генштабта хезмәтен дәвам итүе кире каккысыз һәм моңарчы башка авторлар тарафыннан файдаланылмаган хәрби-тарихи чыганакларда дәлилләнә. Беренче документ. Оборона министрлыгының Үзәк архивындагы хәрби-медицина документлары саклanучы филиалында гаять дәрәҗәдә кызыклы һәм фәһемле шәһадәтнамә (№537) бар. Шул мөһим документта1944 елның 1 мартында Шакир Нигъмәтулла улы Гыйниятуллинның дәвалануын дәвам итү өчен сугыш кырыннан тылга, Мәскәүдәге Хәрби коммунистик госпитальгә (хәзерге Н.Бурденко исемендәге Баш хәрби госпиталь) озатылуы күрсәтелгән. Туган елы – 1895, хезмәт иткән урыны – Генштаб, ә чины – майор дип бирелгән шәһадәтнамәдә, авыруның (бәлки яралануыдыр) аннан соң Архангельское исемен йөртүче санаторийда сәламәтлеген ныгытырга тиешлеге дә искәртелгән (Филиал ЦАМО (военно-медицинских документов), опись: свидетельство о болезни, ящик эг 393-300197). Әлбәттә, чинының майор дип күрсәтелүеннән чыгып фикер йөрткән очракта да, сүзнең нәкъ менә генерал Шакир Гыйниятуллин турында баруы тамчы да шик уятмый. Бу фәкать Генштаб генералын фронтның алгы сызыгыннан тылга озату вакытында күрелергә тиешле конспирация шартларының катгый рәвештә үтәлүен генә дәлилли.

Икенче документ шулай ук тарихи яктан гаять әһәмиятле. 1944 елда Генштаб башлыгы урынбасары армия генералы Алексей Антонов, СССР Югары Советы Президиумы Указы нигезендә «Мәскәүне саклаган өчен» медале белән бүләкләнгән генерал-майор Ш.Гыйниятуллинга шул хөкүмәт бүләген тапшыруы турындагы, бердәнбер фамилиядән торган Актка (ЦАМО. Ф. 33. Оп. 44677сс. Д.222.) кул куя. Алексей Иннокентьевичның имзасы төшкән көн – 1944 елның 17 ноябре. Актта Шакир Нигъмәтулла улының вазифасы буенча Кызыл Армия Генштабының Офицерлар төркеме башлыгы урынбасары булуы теркәлеп калган. Тапшырылган медальнең номеры – А 00178. Шунысы мөһим: әлеге медаль 1944 елның 1 маенда гамәлгә куела. Аның беренче санда йөргәнен 20 июльдә Иосиф Сталинга тапшыралар. Димәк, милләттәшебез – әлеге олы бүләккә лаек булучы 178 нче кеше.

Шушы ике документ генерал Гыйниятуллинның 1944 елда да Офицерлар корпусы башлыгы урынбасары вазифасында Генштабта хезмәтен дәвам иттерүен тулысынча раслый. Фәкать аның кайсы чорда Офицерлар корпусы башлыгы булып торуы гына ачыкланып бетми. Гәрчә, мантыйк буенча фикер йөрткәндә, Шакир Нигъмәтулла улының 1944 елның 1 мартына кадәр шул вазифада булуы бик ихтимал. Әмма, ни аяныч, генералның Бөек Ватан сугышында бүләкләнгән орденнары белән бәйле буталчыклар да җитәрлек.

«Хәрби разведка энциклопедиясе» авторлары, гомумән, Гыйниятуллинның сугышка кадәр алган орденнарын бәян итү белән генә чикләнгән. Чынлыкта, ул Бөек Ватан сугышы елларында Ленин (21.02.1945), Кызыл Байрак (03.11.1944), Кызыл Йолдыз (21.05.1942) орденнары һәм «Мәскәүне саклаган өчен» (01.05.1944), «Бөек Ватан сугышында Алманияне җиңгән өчен» (09.05.1945) медальләре белән бүләкләнгән. Генерал Гыйниятуллинның сугышта алган беренче ордены – Кызыл Йолдыз (№39 500), шул турыда СССР Югары Советы Президиумы Указы (№605 231) чыккан көн – 1942 елның 21 мае. Кызыл Армиянең югары җитәкчелек составын бүләкләү турындагы ил старостасы М.Калинин имзалаган әлеге Указда, аларның оператив һәм оештыру өлкәсендә Хөкүмәт тарафыннан куелган бурычларны үрнәк башкарулары ассызыклана. Шунысы да бар: орденнар белән бүләкләнүче 52 хәрбинең барысы да – Генштаб хезмәткәрләре. Аларның өчесе: генерал-полковник А.М.Василевский, генерал-лейтенантлар А.Г.Карпоносов һәм А.И.Шимонаев – Ленин, тагын утызы – Кызыл Байрак һәм унтугызы Кызыл Йолдыз орденнары белән бүләкләнә. 26 майда Генштабның югары постлар биләүче хәрбиләренә орденнарны Калинин үзе тапшыра һәм шул тантаналы мизгелләрне тарих өчен теркәп калдырган фото да сакланган. Калининның уң ягында – генерал-полковник Александр Василевский, сул ягында исә Генштабның хәрби комиссары генерал-майор Федор Боков, милләттәшебез генерал-майор Ш.Гыйниятуллин һәм Генштабның Оператив тыл төзелеше идарәсе башлыгы, 5 көн генә элгәре генерал-лейтенант чины алган Алексей Шимонаев утырганнар. Фотодагыларның Гыйниятуллиннан кала барысы да – славян һәм яһүди милләтеннән, ә инде нәкъ шул көнне фронтларда командировкаларда булулары сәбәпле тагын 10 хәрби шул тарихи мизгелне чагылдыручы кадерле фотодокументка әләкми калган.

Тик менә генерал Гыйниятуллин турында язучы кайбер авторлар шул көнне Калининның аңа Ленин ордены тапшыруын раслап, хата җибәрә. Чынлыкта, Ш.Гыйниятуллин Ленин ордены (№30 149) белән Җиңү елында бүләкләнә. Шул турыда илнең Югары Советы Президиумы Указы (№220/272) чыккан көн – 1945 елның 21 феврале (ЦАМО. Ф. 33. Оп. 717 028. Д.139. 153.) һәм бу милләттәшебезнең Җиңү елында да Генштабта хезмәтен дәвам итүен дәлилләүче тагын бер факт. Ни аяныч, соңгы елларда аны җәфалаган мәкерле чир чигенми: татар халкының каһарман улы 1946 елның 3 апрелендә вафат була. Аны соңгы юлга маршал А.М.Василевский, армия генералы А.И.Антонов, генераллар С.М.Штеменко, М.В.Захаров һ.б. дуслары, көрәштәшләре озата. Әлбәттә, озатучылар арасында Генштаб башлыгы һәм Оборона министры урынбасары Советлар Союзы Маршалы Александр Василевский, Генштабның Югары хәрби академиясе башлыгы армия генералы Матвей Захаров, Генштаб башлыгының беренче урынбасары Алексей Антонов, Оператив идарә башлыгы генерал-полковник Сергей Штеменко кебек шәхесләрнең булуы хезмәттәшләре арасында абруе зур милләттәшебезгә карата олы ихтирам хисләрен аңлата һәм аның гомеренең соңгы көннәренә кадәр Генераль штаб белән арасы өзелмәвен күрсәтә.

Кызганыч, генерал вафатыннан соң, хакимият тарафыннан аңа карата кылынган кайбер ямьсез һәм тупас гамәлләр аптырашта калдыра. Шакир Гыйниятуллин вафат булганнан соң, аның фатирына көч структураларының вәкаләтле хезмәткәрләре килә һәм музейга кую өчен дигән сылтау белән, барлык орден-медальләрен җыеп ала, хәтта ике кылычын да калдырмый. Ул кылычларның берсен, кыйммәтле ташлар белән бизәлгәнен – Бохара Халык Совет республикасы хөкүмәте, икенчесен шәхсән Климент Ворошилов бүләк иткән була. Алынган барлык бүләкләрнең кайсы музейга куелуы турында туганнарына әлегәчә – нәмәгълүм. Вакытлар үтү белән милләттәшебезнең кабере дә юкка чыга. Әүвәл аны Мәскәүнең Новодевичье зиратында җирлиләр, берничә елдан тол калган хатыны Хәмдениса җәсәдне татар зиратына күчереп күмдерә. Әмма узган гасырның 50–60 нчы елларында яңа төзелешләр татар зиратын изеп-күмеп үтә. Теләк шул: бөтен аңлы гомерен хәрби хезмәткә багышлаган, Ленин, өч Кызыл Байрак, Кызыл Йолдыз, Бохара республикасының II һәм III дәрәҗә Кызыл Йолдыз, Монголиянең Поляр Йолдыз орденнары һәм медальләр белән бүләкләнгән күренекле милләттәшебез генерал-майор Шакир Гыйниятуллинның якты истәлеге югалмасын, исемен ваемсызлык пәрәвезе күмеп китмәсен иде.

Рәис ЗАРИПОВ.

Мәдәни җомга
11 март
№9, 2022

Ягъсуф ШӘФЫЙКОВ

ХУШ, АГЫЙДЕЛ

Фатих бабай ярда, нәкъ су кырыена утырды. Үзенең үткән тормышын Агыйделнең шушы болганчык агымы, силнең бер-берләренең өсләренә менүче ак-соры карлы боз кисәкләре белән чагыштырды. Шушы үлемнәр белән тулы һәм серле егерменче гасырда аның тормышы да болганчык агым булып үтте. Силнең аклары күбрәк бугай, ә аның тормышында сорысы күбрәк урын алып тора.

Сугыш алды елларында энкэвэдэшникларның Актаныш авылларында «халык дошманнарын» эзләп, хуҗалыктан хуҗалыкка йөрүләре аның әле дә хәтерендә. Кырык беренче елның соңгы бер кояшлы көне гомерендә онытылмаслык булып хәтерендә уелып калды. Ул көнне әтекәен – Салих абзыйны, Өшәр авылының бөтен сәламәт ир-атларын сугышка озаттылар. Булачак фронтовикларның җыелу урыны Актаныш янында, Агыйделнең Әҗәкүл пристанендә иде. Аннан инде аларны башта Агыйдел, аннары Чулман, Идел буйлап Казанга алып киттеләр. Салих абзый үзенең туган авылы белән ике мәртәбә саубуллашты дияргә була. Русча белмәүче кичәге колхозчыларны беренче тапкыр җәяүләп күрше Чиялек авылына озаттылар. Бу хәл ерактан караган кешегә бөтен авыл яшәгән урыныннан купкан да каядыр күчеп китәргә җыена сыман күренгәндер. Чиялекне чыккач, Салих абзый ягымлы гына итеп кырынмаган ияге белән Фатихның битләреннән сыдыргалап алды, үзенең тормышында соңгы тапкыр хатыны Фәрхикамалны кысып кочаклады. Аннары туп-туры Актаныш ягына авылдашларын куып китте.

Икенче тапкыр ул туган авылы белән бер тәүлектән соң саубуллашты. Ул иске генә бер пароходта Агыйдел буйлап үзе өчен иң кадерле булган, әле кайчан гына печән чапкан, биш баласы белән шомырт, гөлҗимеш, салкыннарда балан җыеп йөргән болыннар яныннан үтте. Алар утырган пароходның һәм үтүче башка судноларның сузып-сузып кычкыртуы йөрәкләрне өзә. Бу, күңеленнән үзеңне ялгыз сизеп, Агыйдел белән бик авыр саубуллашу иде. Югыйсә, палубада янәшәдә генә бөтен авылдашлар тын гына басып тора. Гәрчә аларның да йөрәкләрен шундый ук уйлар яндырадыр. Алар да бит төп су юлыннан өч кенә чакрым ераклыктагы Өшәр авылы ягына карап бакканнар.

Өшәр ике-өч көн эчендә бушап калды. Хезмәткә яраклы барлык ир-ат фронтка китте. Биш бала белән калган фронтовик хатыны Фәрхикамал апа кинәттән ниндидер авыру белән урынга ятты. Өйдәге бөтен мәшәкать, хуҗалык эшләре унбиш яшьлек өлкән улы Фатих җилкәсенә төште. Көндезен ул колхозда эшләде, кичен өйдәге мал-туарны карады, кышка утын әзерләде.

Өч айдан Фәрхикамал апа беркадәр рәтләнде, әкрен генә өйдә йөри ала башлады. Һәр көнне әтиләреннән хат көттеләр. Киткәннән бирле анардан әле бер мәртәбә дә хәбәр килгәне юк иде.

Көннәрнең берендә терелеп килүче Фәрхикамалга, бөтен гаиләгә язмыш үзенең бөтен ачысын күрсәтте. Хат ташучы алар йортына кара хәбәр китерде. Ул тапшырган кәгазьдә дөньядагы иң кайгылы сүзләр язылган иде: «Кызылармеец Кәримов Салих Ватан өчен барган сугышларда хәбәрсез югалды». Ул көннәрдә мондый кара кәгазьләрне бик күпләр алды. Фәрхикамал, бу кайгыга чыдый алмыйча, тагын урынга егылды.

Фатих болай тыштан караганда нык торды. Ләкин эченнән бик кайгырды. Үзенең, дүрт энекәшенең һәм сеңлесенең әтисез калуына ышанасы килмәде. Ул битендә гел әтисенең сакалын тоеп торды. Авыл капкасын чыккач, ул беразга атын туктатта да, арбага менеп, озак кына Чулман-Кама, Дербешка пристане затон ягына карап тора, карашы белән Кама арьягындагы Удмуртия колхозы кырларын әйләнеп чыга. Әйтерсең лә фронт шуннан, горизонттан үтә. Ниндидер могҗиза белән ул анда барып чыгар да әтисен очратыр, үзенең йомшак битләре белән аның кыл сакалын сыйпар кебек иде аңа. Кама ягыннан ишетелгән пароход гудоклары күңелне елатып, кайгыга салып торалар. Зур гаиләгә тормыш биргән кешенең менә шулай кинәттән генә юкка чыгуына ышанмый иде ул.

Кырык дүртенче елның көзендә Актаныш аша шул ук маршрут белән үзен Казанга, аннан фронтка озатканда да әтисен башка һичкайчан булмаячагына ул ышана алмады. Үзенең өлкәнен фронт юлларына әзерләгәндә Фәрхикамал кара янып йөрде. Шулай да ул Фатихы анда бәлки әтисен очратыр әле дигән өмет белән яшәде. Ул да барлык фронтовик хатыннары кебек иренең үлгәнә яки хәбәрсез юкка чыгуына ышанмады. «Тере кеше ничек инде хәбәрсез югалсын?» дигән кайгылы уйлары белән Фәрхикамал һаман улының күзләренә карарга тырышты.

– Улыкаем, хет син исән-сау кайт инде, – дип кабатлады.

Фатихны нык гаҗәпләндергәне шул булды: аларны Казаннан көнбатыш фронтка түгел, ә пассажир поезды белән көнчыгыш юнәлешенә, Ерак Көнчыгышка җибәрделәр.

Ул Кытай чигендә хезмәт итте. Көнбатыш фронтка эләкмәве нигәдер һәрвакыт аның күңелен тырнап торды. Ахыр чиктә әтисенең эзенә төшә алмаса да, Россия җиренә кайгы-хәсрәт, җимерүләр, үлем алып килгән гитлер илбасарларыннан үч алыр иде. Хезмәт үз көенә үтә торды. Шунысы гына - бик начар ашаталар. Әйтүләренчә, бөтен булган әйбәтләрен көнбатыш фронтка җибәрәләр икән.

Менә шулай хезмәт итә торгач, кырык бишенченең мае да килеп җитте. Шуның белән бергә – Бөек Җиңү. Фатихка инде сугышлар беткәч, әтисе өйгә кайткандыр кебек тоелды. Ә ул монда Маньчжурия сопкалары арасында эшсез ята.

Ай ярымнан Ерак Көнчыгыш крайларына товар эшелоны-эшелоны белән хәрби техникаларын да алып, сугыш утыннан чыккан фронтовиклар килә башлады. Ил чираттагы яңа сугышка, Япония белән сугышка әзерләнә иде.

Кыска вакытлы бу сугышны Фатих бик җиңел үткәрде. Аңа Сугышчан Кызыл Байрак ордены тапшырдылар. Вакытына карата бу бик зур бүләк иде. Аның әле тагын җиде ел хезмәт итәсе калды. 1926 -1927 елларда туган егетләр сигезәр ел хезмәт иттеләр.

Туган Өшәр авылына ул илле икенче елны өлкәнәеп, матураеп кайтты. Ике энесе армиядә хезмәт итә иде. Ә бер сеңлесе кияүгә чыккан. Әнкәе иң кече кызы-төпчеге Земфира белән яши иде. Сугыш чорындагы һәм сугыштан соңгы колхоз тормышын күргән әнкәйләре өлкән улының исән-сау авылга әйләнеп кайтуына ышана алмый торды. Баштан никах укып, тыйнак кына туй ясап алдылар. Мулла булмаганлыктан, никах ритуалын Фәрхикамал апа үзе башкарды. Ул күп кенә аятьләрне яттан белә иде. Дин мәсьәләләрендә бик гыйлем булган әнисе Бибиәсма кызын да өйрәткән. Фәрхикамал Коръәнне гарәпчә бик иркен укый иде. Фатих шомырт кара күзле Фәридә исемле чибәргә өйләнде. Ул иреннән дүрт яшькә кечерәк. Армиягә киткәнче Фатих аны күргәне дә булмады, белми дә иде. Ул Ерак Көнчыгыш чикләрен япон самурайларыннан саклаган арада Фәридә менә дигән чибәр кыз булып үсеп җиткән. Шуның өстенә әле ул бик яхшы хуҗабикә, ә балаларына менә дигән әни булды.

Фатих үзенең булачак хатынын беренче күрүдә үк яратты. Ә бу ярату көннән-көн ныгыды. Фатих саклады бу мәхәббәтне. Фәридә чибәре дә аңа шулай ук җавап бирде. Берсе артыннан берсе балалар туа башлады. Башта Рәзилә туды, аннары – уллары Зөфәр белән Рәшит.

Фатих үзе колхоз мастерскоенда механик булып эшләде. Бу еллар аның өчен иң бәхетле еллар иде. Ни өчендер андый еллар сиздермичә тиз үтәләр шул.

* * *

Уйланып утыра торгач, Фатих арьяктагы механизаторларның әбәт ашарга кереп китүләрен күрми дә калды. Ни өчендер Спутнигы да үз янында тыныч кына ята бирә. Фатих кирза итек белән аякларының туңа башлавын сизде. Ул утырган җиреннән торды. Хуҗа белән аның дүрт аяклы дусты да землянкага таба китте. Агыйдел өстендә бозлы карларның шыбырдавы һаман ишетелеп тора иде әле. Фатих бабай балыкчылар әзерләп куйган утыннарны землянкага ташыды. Буржуйкага охшаган мичне ягып җибәрде. Аның өстендә су белән тулы колаксыз алюмин кәстрүл тора иде. Балыкчылар, сунарчылар кебек үк, язылмаган законны саклыйлар: үзләре киткәндә яшәү өчен кирәк-яракларны калдыралар. Мичтәге утыннар әйбәт кенә янып китте. Мичнең ачык ишегеннән чыккан ялкын телләре караңгы җир асты патшалыгын тонык кына булса да яктыртып торды. Кәстрүлдәге су бик тиз кайнап чыкты. Фатих бабай капчыгыннан чәен, эмальле кружкасын, Сарапулда алган шикәрен чыгарды. Дустына тагын ипи белән колбаса кисәге бирде. Алар икәүләшеп мич җылысында ашап алдылар. Карт, землянкадан чыгып, тагын яр буена төшеп китте. Агыйделдә кар катнаш бозлар шаулый иде. Тирә-юньдә беркем дә юк.

Тракторчылар төшке аштан соң картны борчымаска булдылар. Шуңа күрә Агыйдел буена да бармадылар, иске елга ярына таба киттеләр. Бу ерганакта сил бөтенләй юк диярлек иде. Ә булганнары су өстендә тыныч кына әйләнеп тора. Тегеләр ярда халыкларның зур күченүе көннәрендә ташланган ике иске өй тора. Аннан арырак Габдулла Хәйбуллинның яңа йорты күренә. Ә янәшәсендә иске өенең каралып беткән түбәсе тырпаеп тора. Ярда сумалага буялган зур корсаклы өч көймә аунап ята. Кайчандыр гаять зур авыл булган урында бәскә төренгән алабута плантациясе генә. Арырак, уңда удмуртларның Кама арьягындагы кырлары күренә. Каршыда, ике чакрымнар арырак илленче еллар ахырында, алтмышынчы еллар башында Өшәр колхозчылары утырткан наратлык карачкыл булып күренеп тора. Сул яктарак калкулыкта Буазкүл, аннан арырак Бүләк авылы күренә. Габдулла хуҗалыгы тирәсендә берәү дә юк. Мөгаен, сыерларын, атын, башка мал-туарын өе тирәсенә кертеп япкандыр. Хәтта аның усал эте дә аваз салмый иде.

– Без зур җиргә картка караганда иртәрәк чыгарбыз, ахрысы, – диде Мирсәет, тынлыкны бозып. – Монда Агыйделдәгегә караганда боз ике көнгә иртәрәк күренәчәк.

– Моның белән нәрсә әйтмәкче буласың? – Рамил Мирсәеткә ачулы караш ташлады. – Картны үз карамагына калдырабызмыни?!

– Мин боз турында, ә син карт турында... – Мирсәет тә үпкә белдереп куйды. – Мин бит аны ташлап китәбез дип әйтмим. Может без башта Габдулла янына бара алырбыз, ашарга-эчәргә нәрсә булса да алырбыз.

(Дәвамы киләсе санда).

Ринат **МӨХӘММӘДИЕВ**

● Сулдан уңга: Гариф Ахунов, Әбрар Кәлимуллин, Ринат Мөхәммәдиев, Мөхәммәт Мәһдиев.

ТОРНАЛАР ТӨШКӘН ҖИРДӘ...

Табигатьне, туган як буйлап сәяхәтне Мөхәммәт Мәһдиев кебек яраткан әдипне очратканым булмады. Аеруча Казан артына, Арча якларына сәяхәт итүдән туймый торган иде. 1993 елның җәй урталарында без, бер төркем язучы һәм журналист, Тукайга багышланган фильм төшерүчеләр чакыруы буенча, чираттагы сәяхәткә Арча һәм Балтач якларына юл тоттык. Мин руль артында, арткы рәттә Гариф Ахунов һәм телевидениедә эшләгән каләмдәшебез Хәйдәр Гайнетдинов. Мөхәммәт абый алда, үзенең яраткан урынында. Гадәтенчә, тәрәзәне төшереп, тәрсәген тышка чыгарып утыра.

– Әй, егетләр, тоясызмы икән – тәрәзәдән безнең якның җиле керә башлады бит, Казан арты һавасы, – дип үзалдына хозурланып куймасынмы Мөхәммәт абый. – Биектауны чыккач та йөзгә бәрелә ул, маңгай чәчләреңә урала шушы кыска җил...

Кушлавычка килеп төшкәч, Мөхәммәт абый мине үзе белән ияртеп китте.

– Әйдә, телевидение егетләре камераларын көйли-сөрткәли торган арада Тукайның ничәмә-ничә буын бабалары суын эчеп үскән чишмәләрне, инеш буйларын урап меник.

Су буеннан чиләк-көянтә белән кайтып килгән үсмер кызга, башына бүрек, аягына киез-ката киеп инеш буена каз-үрдәк куып төшүче әбигә, вак ташлар арасыннан маймыч тотып мәш килгән малайларга юнәлтте ул игътибарымны. Әйтерсең мин авылда үсмәгән, болар һәммәсе Арчада, бары тик Кушлавычта гына шулай. Башка һичбер тарафта булмаган күренешләр диярсең...

Ташлар өстенә баса-баса, аяк киемнәрен юешләтмәскә тырышып, инешнең аргы тарафына чыктык. Карт өянке төбеннән кайнап чыккан чишмә янына килдек.

– Тыңла, – дип дәү бармагын иреннәренә китерде Мөхәммәт абый. – Ишетәсеңме? Шаулый... Тибә...

Мин дә сагаеп тынлыкка колак салдым. Инеш челтерәвен ишеттем. Карт өянке яфраклары лепердәшүен...

– Тукайны тудырган илаһи көч исән... Исән икән әле, әнә ничек аваз сала, шаулый... – дип ачыклык кертте әдип. Гүя үз-үзен җөпләп куйды.

Ул да түгел, җәһәт кенә өстендәге пинжәген салып, миңа сузды. Күлмәк җиңнәрен сызгана төшеп, чишмә янына барып басты. Ике кулы белән ташларга таянып, сузылып төшкән галстугын муен аша артка атып, йөзтүбән ятып су эчте. Йотлыгып-йотлыгып эчте ул Тукай чишмәсенең суын. Аягүрә баскач, күкрәк тутырып иркен сулап куйды. Аннан минем пинжәгемне сорап алды, мин дә ул башкарган йоланы кабатладым...

– Менә, – диде ул бераздан, башын калкыта төшеп, – кран суын эчеп үскән шәһәр балаларына аңлатып булмый бу рәхәтлекне. Шуңа да «Җәйге таң хатирәсе»н яза алмый инде алар. Яза да алмый, аңламыйлар да...

– Аңлавын, бәлки, аңларлар анысы, – дип, өлкән әдипнең хөкемен бераз йомшартмакчы булдым. Ә ул каршы төште.

– Минем сынап караганым бар, бер түгел, әллә ничә мәртәбәләр сынадым, – диде ул, тагын бер мәртәбә күкрәк тутырып сулыш алып куйгач. – Тукайның нинди шигырьләрен яратасыз? дигән сорауга беләсеңме нинди җавап кайтара бүгенге яшьләр... «Гали белән Кәҗә» диләр. «Туган тел»не хәтерләргә мөмкин алар, «Китмибез»не. Әмма арадан ник берсе «Җәйге таң хатирәсе»н искә алсын икән!

Мөхәммәт Мәһдиев белән бәхәсләшеп булмый, ул һәрчак дәлилле сөйли. Каплый да куя шул дәлилләре белән.

Ул арада авыл ягыннан яныбызга ике малай йөгереп төште.

– Язучы абыйлар, – диде алданрак йөгереп килгәне, мыш-мыш сулыш алып. – Сезне кинога төшәргә чакыралар...

– Бар, әйт Хәйдәр абыеңа, - диде Мөхәммәт абый, җавабы күптән әзер кеше сыман ике уйлап тормастан. – Киноны абзар артында түгел, чишмә янында башлау хәерлерәк булыр, дип әйтеп әйтте теге абзыйлар диген.

Ни сәбәпледер Хәйдәр үзе төшеп тә тормаган, кинооператоры, кара бөдрә чәчле Фәрдәт Мансуровны гына җибәргән булып чыкты. Аның белән бергә әле бая гына судан кайтып килгән үсмер кыз бала да янә төшкән иде.

– Өегез шулай бик якынмыни, аягың бик җиңел икән, кызый, – дип эндәште аңа Мөхәммәт абый.

– Юк, – диде кыз бала, – мин өйгә кайтып җитә алмадым шул. Капка төбендә утырган абыйлар эчте ул суны.

Кинооператор сәләтле булса да, шәһәрдә үскән егет. Мөхәммәт абый аны: «Тегеләй ит, болай ит», дип гел өйрәтеп торды. Ком астыннан тибеп чыккан чишмәнең сулышын, кыз баланың чиләкләрен мөлдерәмә тутырып су алганын, чалбар балакларын тездән югары сызганып, инеш буйлап йөгерешкән малайларны төшерергә кушты ул аңарга. Малайлардан өркеп читкә сибелгән каз-үрдәкләр, бакча башына арканлап куелган бозау, басудан яшел печән төяп, ат арбасына кыңгыр ятып кайтып килгән агай, әле алга атылып, әле калыша төшеп, шул ат әйләнәсендә гел уйнаклап йөргән колын җәлеп итте аның игътибарын. Үз илендә, үз төбәгендә иде шул Мөхәммәт абый. Аңа монда барысы да кадерле һәм үз...

Кушлавыч белән хушлашып, Кырлай тарафларына юлга чыккан идек инде. Машинаны туктатуымны сорады Мөхәммәт абый. Чыктылар... Юл читендә тын да алмый ике сабакташ – Гариф Ахунов һәм Мөхәммәт Мәһдиев янәшә басып тора. Бераздан, ни булган боларга дип, яннарына мин дә килергә батырчылык иттем.

– Шауламагыз, – диде Мөхәммәт абый, үтә дә мәгънәле итеп уң кулын сак кына күтәреп. – Әз генә сабыр итегез, узып барган машинаның тузаны басыла төшсен дә мин сезгә шундый хикмәтле манзара күрсәтәчәкмен.

Җил юк, яңгыр юк... Безнең сабырлыкны сынап, шактый көттереп кенә басылды ул тузан.

– Карагыз... Торналар... – диде ул, сабыйларча куанып. Бармагын төртеп-төртеп, зәңгәр рәшә уйнаган борчак басуына күрсәтте.

Ике торна. Икесе дә ап-ак. Борчак басуы өстендә атлап түгел, гүя йөзеп йөриләр. Әледән-әле очарга җыенгандай сикерә-сикерә талпынып та куялар, ул да түгел, пар канатларын җәеп, җилкенеп алалар. Сорау билгеседәй бөгелә төшкән зифа муеннары айкалып та, чайкалып та куя. Шунда вак-вак атлап, көязләнеп, бер-беренә якынаялар. Томшыклары томшыкка терәлә, аңлаша, серләшә, иркәләнә болар. Шулай бергә кушылганда аларның дугадай бөгелгән нәфис муеннары җәннәткә илтүче ап-ак күперне хәтерләткәндәй булып ала...

– Бу аларның мәхәббәт сәгате. Мәхәббәт биюе... – дип ачыклык кертте Мөхәммәт абый.

– Мөхәммәт белә инде, – дип, Гариф абый да миңа серле генә күзен кысып куйды.

Ә Мөхәммәт Мәһдиев гүя аны бөтенләй ишетмәде, ул авызын ачып, тып-тын калып, торналарга соклануда иде һаман...

– Күптән күргән юк иде. Торналар бетмәгән, торналар исән икән әле, – дип, ниһаять, куануын белдерде Гариф абый да. Ул, гомумән, сөйләшми-аралашмый торуны белми, өнәп тә бетерми иде.

Минем дә авылда үткән бала чакларымнан соң башка һичкайда һәм һичкайчан торналарны күргәнем, шулай сокланып үзләрен якыннан күзәтеп торганым юк иде кебек... Табигать тудырган иң гүзәл һәм иң сылу җан ияләре бит болар...

Яңадан машинага утырып киткәч тә, урман буенда үзебезне зарыгып көтеп торган телевидение «УАЗ»ын куып җиткәч тә, чираттагы мәртәбә Кырлай белән танышып йөргәндә дә, Арча белән Балтач районнары чигендә урнашкан умарталыкта әче бал татыганда да телебездә һәм күз алдыбызда гел шул торналар булды. Сирәк очрый торган бәхет – «Торналар төшкән җирдә» булдык бит без дә. Мөхәммәт Мәһдиевнең үзе белән булдык, аның белән янәшә басып тордык.

...Тамак ялгап алгач, балы белән очлап куйгач, умартачы өенә сыеша алмыйча, китәргә җыенып кояшлы аланга чыктык. Кунакчыл хуҗа безне озата чыкты. Аланлыкта, шуның улы иде булса кирәк, тирләп-пешеп печән чаба. Аяклар, ирексездән, машинага түгел, печәнчегә таба тартты.

– Әллә бер-ике селтәнеп аласыгыз киләме? – диде егет, безгә мөрәҗәгать итеп. Ул арада шәрә беләкләре белән маңгай тирен сөртеп куйды.

– Чалгың бер генә, ә без өчәү, – диде Гариф абый. – Өчебезгә дә булса, чабабыз аны... Печән чапмаган егетләр түгел, шулай бит, Мөхәммәт?

– Рәхим итегез, – дип, калын покос астыннан тагын ике чалгы тартып чыгарды бу егет һәм кулларыбызга китереп тоттырды...

Мин иң алдан кереп киттем. Артымнан ук, үкчәңә менә басам-менә басам дигәндәй Мөхәммәт абый килә. Гариф абый да бездән калышмый. Тиз-тиз җилпенеп алгарак киттем дә тагын артка каерылып карадым. Берьюлы татар әдәбиятының ике асыл заты, ике күренекле әдибенең чалгы тотып, печән чапканын күргәнегез булдымы? Ә мин бер мәл сокланып карап тордым... Хәйран калдым – мин күлмәктән, ә ике олпат язучы, кай арада бил тиңентен чишенеп үк аткан да, печәнне тигез покосларга каералар, хәрәкәтләренә күз иярерлек түгел. Болынга төшкән авыл егетләре, авыл агайларың бер якта торсын... Мөхәммәт абыйның колач киң, гәүдә-сын туры, ул кул белән, беләк көче белән алдыра. Яшь җилкенчәк сыман тешен кыскан да керт-керт кистерен кенә бара. Гүя шигырь яза – рифмасы шәп, ритмнары тигез... Ә Гариф Ахунов чабуыннан туктады да чаж да чож чалгысын кайрарга кереште...

Әле дә күңелемдә, әле дә күз алдымда, әле дә колак төбемдә яңгырап тора кебек – Кушлавычтагы чишмәнең агышлары, торналарның канат кагышлары, ике олы әдипнең чалгы кайраган, печән чапкан, бер-беренә төртмәле сүзләр әйткән булып шаяра-көлә сөйләшкән тавышлары...

1996 ел.

БӨГЕЛМӘДӘ

● Һади Атласи портреты.

Узган ел милли каһарманыбыз, тарихчы, мәгърифәтче, дин һәм җәмәгать эшлеклесе, ә иң аянычы – 1938 елда Сталин этләре тарафыннан атып үтерелгән бөек Һади Атласиның тууына 145 ел тулды. Милли җанлы зыялыларыбыз әлеге вакыйганы республика күләмендә билгеләми калмас, иң зур кичә һәм фәнни конференцияләр Казан каласында шаулап үтәр, дип өметләнгән иде. Ләкин, ни үкенеч, Казан бу юлы да милләтнең газиз каһарманы истәлегенә игътибарсыз калды. Ул шулай гадәтләнгән.

●Гимназиядәге милли музейда сәүдәгәрләр почмагы.

Инкыйлаб еллары алдыннан ук «милли юлбашчы»га әверелгән һәм хәтта бөек Тукаебыз тарафыннан да нәкъ шулай олыланган Гаяз Исхакый тууның 140 елын да билгеләп үтүдән качтылар. Исхакыйның туган авылы Яуширмәне Мари илендәге Звенигово ит комбинатына сатып җибәрделәр. Юлбашчының Яуширмәдәге музеен ремонтлау өчен 39 миллион сум акча бүлеп бирергә вәгъдә итсәләр дә, ул үтәлмәде һәм мирасханә бүгенгәчә ярым ташландык, ярым сырхау хәлдә җан асрап ята. Исхакыйның гомер буе иңгә-иң басып көрәшкән борадәре Садри Максудига һәйкәлне Төркия хөкүмәте үз хисабына китереп куйса, Гаяз әфәндегә Казан уртасында бюст та калыкмады. Башкаланың тимер юл вокзалы янындагы өч йортлы бер «тыкрык»ка гына Исхакый исемен китереп «чәпәделәр», газиз милләте хакына бер гөнаһсыз көе башын салган Атласи исеменә дә колхоз базары янындагы кечтеки генә урам «лаек» булды. Димәк, милли горурлыгыбыз булырга тиешле каһарманнарыбызга сан да юк бездә, кадер-хөрмәт тә юк.

●Һ.Атласи гаиләсе. 1965 ел.

Аптыраганнан, ут күршеләребез булган башкортларның мондый өлкәдә кылган изге гамәлләреннән көнләшергә кала. Гәрчә икесе дә татар милләте вәкилләре булса да, Башкортстан республикасын төзү өчен көрәшкән Зәки Вәлиди белән Шәехзадә Бабич истәлегенә күршеләребез Баймак районының Темәс һәм Дүртөйледәге Әсән авылларында күз явын алырдай музейлар ачып куйды. Республиканың үзәк китапханәсе З.Вәлиди исеме белән олыланды, Уфа үзәгендә Фрунзе атын йөрткән урамнарыннан берсе Вәлиди исеме белән яңартылды. Әле ике ел чамасы элегрәк шул урам башында Ш. Бабич хөрмәтенә искиткеч зур һәйкәл дә калкыттылар. Шушы гамәлләрне кылган республика җитәкчеләрен бүген бер генә явыз көч тә «милләтче» йә «куштан» дип тә телгә алмый...

Газиз халкы өчен кансыз җәлладлар тарафыннан җәзаланган һәм ахыр чиктә үзенең 8 дусты белән бергә атып үтерелгән бөек Һади Атласи да – данлау һәм баш июгә чиксез лаек шәхес. Аның үлеменә кадәр 30 ел алдагы гамәлләренә генә күз йөгертик. Әлмәт авылында (бүген шәһәр) «гап-гади» мулла һәм мәдрәсә мөгаллиме булып эшләгән Атласи 1907 елда Самара губернасы крестьяннары исеменнән империя Думасына депутат итеп сайлана. Думада мөселман фракциясе төзелгәч (бүген моны күз алдына китерү дә кыен, чөнки барча депутатлар фәкать «россиянлы»), милләттәше Садри Максуди һәм аның ярдәмчесе Йосыф Акчура белән кул тотышып эшли. С.Максуди бер үзе генә дә йөздән артык тапкыр Дума мөнбәреннән һәм комиссия утырышларында чыгыш ясый. Фракция исеменнән мөселман депутатлары мәктәп һәм мәдрәсәләрдә балалар бүгенгечә бүленештә бишенче сыйныфка кадәр белемнәрне фәкать туган телләрендә генә үзләштерергә тиешлеген даулый һәм җиңүгә ирешә. Шулай ук алар Россия империясе мөселман илләренә каршы сугыш ачса, аңа Россия мөселманнарын катнаштырмау таләбен куя һәм янә шуны Дума тарафыннан яклаттыруга ирешә. Шул ук депутатлар таләбе буенча урыс сәүдәгәрләре мөселман авылларында ачарга өлгергән кабак һәм аракы сату кибетләре дә ябыла... Йәгез, чагыштырыйк. Соңгы 30 ел эчендә безнең Татарстаннан гына да иллегә якын депутат Дума кәнәфиләренең төмен татый белде, мәгәр 2007 елда татар тарихын укытуны тыйган яисә 2018 елда татар теленең тамырына балта чапкан чакта һич югы берәрсе Дума мөнбәренә чәчрәп чыктымы да, аларны Садри Максуди яки Һади Атласи белән тиңләп буламы соң?!.

Ә Атласи депутатлык бурычын үтәгән көе дә Әлмәттә чакта ук башлаган мәгърифәтчелек эшен дәвам итә алган һәм газиз халкына бер-бер артлы

●Атласи исемендәге гимназиянең милли музеенда.

МИЛЛИ ТАНТАНА

●Һ.Атласи бүләге ияләре Д.Шакиров, К.Хәмидуллина, В.Имамов.

«Себер тарихы», «Казан ханлыгы», «Сөенбикә» атлы тарихи әсәрләрен дә бүләк иткән әле!

Революция елларында Бөгелмә, Шөгер, Зәй-Каратай авыл мәктәпләрендә тарих һәм немец теле укытучысы булып йөрсә дә, Атласи газиз халкының киләчәге турында кайгыртудан туктамаган. Латин графикасын кертүгә каршы чыккач, аны Соловки лагерена газапка озатканнар. Кискен авыруы сәбәпле азат ителсә дә, 1936 елда үзенең 8 якташы һәм хезмәттәше белән бергә кабат кулга алынган. 16 мәртәбә допрос-җәзалау дигән сират күперен кичкәннән соң, 1937 елның октябрендә Казанның Менжинский исемендәге клубта аларга суд кәмите оештырганнар. Хыялларында да булмаган Туран дәүләтен төзергә «омтылышлары» өчен тугызы да үлемгә хөкем ителгән. Аларны 1938 елның 15 февралендә Казан төрмәсе диварына терәп юк иткәннәр. Каберләре һаман билгесез...

Күз алдыннан шул кансыз елларда юк ителгән татар корбаннары йөгерешеп үтә. Нахак рәвештә атып үтерелгән бичаралар урыста да, чуашта да чиксез. Мәгәр каләм белән үз күзләрен үзе төртеп тишкән Шамил Усманов, үпкәләре череп беткән көе кулга алынып, төрмә хастаханәсендә җан биргән Галимҗан Ибраһимов – тик татарда гына. Шулай ук 68 яшендә Уфа төрмәсенең диварына терәп атылган Мөхлиса Буби кебек каһарман хатын да – тик татарда! Ә Казанда, менә, мәгърур һәм мәшһүр Мөхлиса исемендәге урам да юк, аның язмышы турындагы спектакльне дә Камал театры сәхнәсеннән алдыртып ташладылар. Легендар Һади Атласи хөрмәтенә сыңар гына да һәйкәл куйдырмыйлар. Җиребезгә усал көчләр хуҗа...

Ходайның рәхмәте, әле ярый Бөгелмә каласында Атласины маяк иткән асыл татарлар бар. Татар эшмәкәрләре һәм зыялылар әллә ничә ел элек үк бөек тарихчы һәм мәгърифәтче исемендәге хәйрия фонды булдырган. Шулар 17 ел рәттән Атласи һәм аның көрәштәшләрен искә алу кичәсе уздыра. Алар хәтта 14 нче татар гимназиясенә Һ.Атласи исемен бирдерүгә ирешкән. Уку йортында кечкенә бүлмәдә булса да аңа багышланган музей оештырылган. Һәр ел саен Атласи мирасына багышланган семинар-конференцияләр шаулап үтә. Ел саен шәһәрдә иң яхшы татар теле укытучысы һәм милли тәрбияче ачыклана, татар милләтенең иң зыялы мөгаллимнәренә һәм каһарман шәхесләренә Һ.Атласи исемендәге премия тапшырыла.

Быелгы тантанага алдан сөйләшү буенча Бөтендөнья татар конгрессының Башкарма комитет җитәкчесе Данис Шакиров, Мәгариф һәм фән министрлыгының милли мәгариф бүлеге башлыгы Энҗе Гыйззәтуллина, Энциклопедия һәм туган төбәкне өйрәнү институты директоры, тарих фәннәре докторы Искәндәр Гыйләҗев, «Мәдәни җомга» газетасы һәм «Безнең мирас» журналы мөхәррирләре Вахит Имамов белән Ләбиб Лерон, Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты хезмәткәре Ләлә Мортазина, күренекле җәмәгать эшлеклесе һәм язучы Фәүзия Бәйрәмова, филология фәннәре докторы Әнвәр Шәрипов, Татарстан Милли китапханәсенең директор урынбасары Ирек Һадиев, атаклы мөгаллимәбез Камәрия Хәмидуллина, шулай ук Әгерҗе районының Иж-Буби авылындагы бертуган Нигъмәтуллиннарга багышланган музей, Әлмәт районындагы Риза Фәхретдин һәм Фатих Кәрими музейларының хезмәткәрләре, Бөгелмә мәгариф идарәсе вәкилләре, дистәләгән татар теле һәм әдәбияты мөгаллимнәре кунак булып килгән. Бөек тарихчыны искә алу әүвәл Һ.Атласи исемендәге гимназиядә (директоры Фәнис Гайнуллин) башланды. Газиз телебез инде дүрт ел буе изелү кичерә бит, шуңадырмы күпчелек ачыну шул тарафта барды.

Ләкин үрнәк алырлык мисал да бар. Һ.Атласи исемендәге гимназиядә, ата-аналар ризалыгы белән, балаларга татар теле – атнасына өч, әдәбият исә ике сәгать керә. Димәк, барча мәктәп коллективлары да шушы Атласи гимназиясе тәҗрибәсен үзләренә өлге итә ала!..

Аннары әдәбият, тарих һәм иҗат тантанасы шәһәрнең милли-мәдәни үзәгенә күчте. Бинасы да тарихи һәм кыйммәтле: аны Балтач районының Түнтәр авылыннан чыккан сәүдәгәр Хәким бай, дөньяны шаккатыра башлаган синематограф үзәге буларак, 1912 елда төзеп биргән. Каладагы барча татарның милли учагына әверелгән бинаның кечкенә булса да музее, янәшәдә төрле күргәзмәләр үткәрерлек залы да бар. Без барганда залны җирле рәссам Дамир Хафизов эшләре бизи иде, аның кылкаләменнән төшкән картиналар белән дә хозурланып чыктык.

Үзәкнең тамашалар залында сәхнә түре Һ.Атласи исемендәге хәйрия фонды рәисе, тарих фәннәре кандидаты Алсу Мөхәммәтдинова белән татар конгрессының Бөгелмә бүлеге җитәкчесе Руслан Җәләев кулына күчте. Алар күптән килгән йола буенча, каланың иң булдыклы татар теле укытучысына һәм милли тәрбиячегә фонд һәм татар җәмәгатьчелеге исеменнән махсус диплом һәм бүләкләр тапшырды. Аннары сәхнәгә Бөтендөнья татар конгрессының Башкарма комитет җитәкчесе Д.Шакиров чыкты һәм ул да, үз чиратында, А.Мөхәммәтдинова белән Р.Җәләевне, шулай ук Бөгелмә халык театры режиссеры Флүрә Шәрипованы Һ.Атласи рухына кылган изге эшләре өчен конгресс медальләре белән олылады. Хуҗалар да әзерләнеп көткән, Данис әфәндегә һәм Татарстанның атаклы мөгаллимәсе, озак еллар буе Казан каласында Ш.Мәрҗани исемендәге татар гимназиясен җитәкләгән Камәрия ханым Хәмидуллинага шәһәр җәмәгатьчелеге исеменнән «Милләтпәрвәр» һәм «Мәгърифәтче» дәрәҗәләрен һәм Атласи фонды дипломнарын тапшырдылар. Шул ук җитәкчеләр филология фәннәре докторы Ә.Шәрипов белән тарихи романнар авторы В.Имамов күкрәгенә Атласи исемендәге премиянең махсус медальләрен такты...

Бөгелмә төбәгендә татар рухы, татар теле исән, бөек Һ.Атласи истәлеге аларга яңа буыннарны милләт балалары итеп тәрбияләүдә көч бирә. Без шуңа бөгелмәләләр фидакярлеге һәм аларның киләчәге өчен горурланып кайттык.

В.БАЙСАРЛЫ.

Автор фотолары.

●Истәлеккә күмәк фоторәсем.

Атнаның сәяси мизгелләре

ДӨРЕСЛЕК БЕРЬЯКЛЫ ГЫНА БУЛА АЛМЫЙ

БМО Генераль Ассамблеясенең (ГА) унберенче гадәттән тыш сессиясе 2 мартта Нью-Йоркта “Украинага каршы агрессия” дигән резолюция кабул иткән. Документ Россияне Украинага басып керүдә гаепли, аннан үз гаскәрләрен тулысынча чыгаруын, шулай ук ДНР һәм ЛНР республикаларын тану турындагы карарын юкка чыгаруын таләп итә. Резолюция проекты автордашлары булып 96 дәүләт чыккан. Рәсми мәгълүматларга караганда, резолюцияне яклап 141 ил тавыш биргән. Каршы илләр – бишәү (Беларусь, КХДР, Эритрея, Россия һәм Судан), битарафлар – 35 ил (алар арасында Әрмәнстан, Кытай, Куба, Һиндстан, Иран, Гыйрак, Казахстан, Кыргызстан һәм Таҗикстан да бар). Шуңа да игътибар итик, БМО КШ резолюциясеннән аермалы буларак, БМО ГА резолюциясе үтәү өчен мәҗбүри көчкә ия түгел. Ә БМО КШның 25 февральдә үткән утырышында Россияне гаепләгән резолюция, бу ил КШ ның даими әгъзасы буларак вето хокукын куллануы сәбәпле, кабул ителмәгән иде. Шуңа күрә БМО КШның чираттагы утырышында ул резолюцияне БМО ГА ның гадәттән тыш утырышына чыгару турында карар кабул ителде. Чөнки, андый утырыш җыйганда, вето хокукын кулланып булмый.

Инде рәсми хәбәрләрдә телгә алынган кайбер башка вакыйгаларга да тукталыйк. АКШ Россиянең БМОда эшләгән 12 дипломатын “нон грат персонасы” дип игълан итте. Алар дипломатиягә хас булмаган эшчәнлектә гаепләнә. Дөрес булмаган мәгълүмат таратуда гаепләнеп, Мәскәүдә “Эхо Москвы” радиостанциясе һәм кайбер башка мәгълүмат чыганаклары туктатылды, “Роскомнадзор” Twitter һәм Facebook социаль челтәрләренә керүне чикләде (җөмләдән, Казанда да кайбер электрон басмаларга керү кыенлашты). Шул ук вакытта Россия Президенты илдә “хәрби хәл” режимы кертү планы булмавы турында белдерде. Дөнья илләре Россиягә каршы яңадан-яңа санкцияләр кертүен дәвам итте. Әле Украинада гуманитар хәл начарлана бара, качаклар саны арта. Алар күбрәк хәрби хәрәкәтләр бармаган якка (Польшага, Молдовага) чыга. Россия хөкүмәте дус булмаган илләр исемлеге төзеде. Анда дистәләрчә илләр (ЕС илләре, АКШ, Австралия, Бөекбритания, Канада, Норвегия, Украина, Япония һ.б.) кертелгән. Россиядә рөхсәт ителмәгән протест акцияләре регуляр үтә. 6 мартта үткән акцияләрдә тоткарланган затлар саны гына да 3500дән артып киткән. 7 мартта Беларусьта Россия һәм Украина делегацияләре арасында сөйләшүләрнең өченче раунды үтте. Россия делегациясе башлыгы В.Мединский анда әлегә өметләрнең акланмавы турында әйтте.

Фоат УРАЗАЙ.

Минем һәр эшем

Г.Камал исемендәге театр артисты Камил Камалов күптән вафат инде. Ә сәхнәдә ул иҗат иткән рольләр һаман сагындыра. 1986 елда Мәскәүдә чыга торган “Театр тормышы” журналының олуг бүләгенә дә лаек булган иде. Иртә китте, ә үзен онытмадык. Ядкәр итеп, Камил турында шул журналда дөнья күргән бер язманы тәрҗемә иттек.

Руфия ХӘМИДУЛЛИНА.



Камил Камалов белән Казан урамнарын буйлыйбыз. Ул мине һәр йортының тарихын үзе яхшы белгән шәһәр белән таныштыра. Матур борынгы өй каршында тукталган саен, ә Казанда революциягә кадәр салынган биналар байтак саклангап, Камил чиксез горурлык хисләре кичерә. Ул миңа тупланмасындагы хәзинәсен халык хозурына куйган коллекционерны хәтерләтә.

Казан кирмәненә килеп җитәрәк, «хәзина»нең иң кыйммәтле өлеше шул икәнен бик тиз төшенәм. Юлдашым тыңдаучысез архитектур корылмага сокланып карап тора, шундый ук соклануны миннән дә көтә, бик мавыгып Казан кирмәне турындагы риваятьләрне хикәяли, ул да булмый, хәзерге татарларның бик ерак бабалары яшәгән гасырларга ук әйдәп, үз халкының тарихын сөйләргә керешә.

Аннары без театрга юл тотабыз. Тамаша башланырга әле шактый вакыт бар, шуңа да карамастан, минем гидым театрны карап чыгу өчен аны чак җитәчәк дип саный. Һәм ул хаклы. Камал театрында карарлык нәрсәләр бар: зиннәтле алгы зал (фойе), кышкы бакча, ачык верандалар, театрга нигез салган шәхесләрнең махсус заказга ясатылган сурәтләре. Профессиональ татар театрын оештырган затларның тантаналы йөзләре һәм мәгънәле кузләре диварлардан безгә төбәлгән. Сурәтләнгән театр эшлеклеләренең мәшһүрлеген, затлылыгын тиешенчә ачып биргән портретлар заманча бина диварларына эленгән һәм бу күңелгә зур тәэсир ясый. Язуларын укыганда, тәэсир тагын да көчәя: Камал I, Камал II... Портретлардан соң калган буш урынга шаяру катыш ишарәлим: янәсе, монда синең сурәтең эленеп торачакмы? Камил Камал дигән исемең бар икән, татар театрының «патшалар» нәселен дәвам итү синең өчен абруеңны саклау дәрәҗәсендәге зур эш булырга тиеш, дим. Камил елмая һәм мине сәхнәдә хәзер уйнаучы актерларның фотосурәтләре тезелеп киткән залга әйди. Иң башта – СССРның халык артистлары, аннары – «атказанган» һәм башкалар, ахырда – актерлык юлына яңа гына аяк баскан яшьләр; иң соңында – Камил Камаловның сурәте. Дан-шөһрәтле хезмәттәшләре дәрәҗәсенә җиткәнче аңа әле байтак юл үтәсе. Әммә Камил моңа һич борчылмый, зур театр гаиләсенә кабул ителүе белән генә дә ул үзен чиксез бәхетле тоя.

Бер сурәттән икенчесенә, аннары өченчесенә күчәбез, Камил кемнең кем булуы турында аңлатмалар биреп бара. Аның-ча, труппаның һәрбер артисты йә бөек, йә талантлы, ул башка сүзләр белми дә кебек, һәм мин бу хәлдән каушап калам. Актер туганнарым кичерсен: әмма шундый да ихласлык белән, сокланып үзенең таланты һәм ирешкәннәре турында түгел, ә башкалар турында сөйләүче артистны беренче тапкыр күрүем.

Аннары да, театрның бүгенге репертуары турында сөйләгәндә, Камил бик озаклап, хискә бирелеп, А.Гыйләҗевның «Өч аршын җир» премьерасы турында гәп кора. Бу спектакльдә бөтенләй уйнамавын ачыклагач, мин тагын гаҗәпкә калам. Камил сөйләргә ярата, мин Г. Камал исемендәге театрның иҗади тормышы, аның режиссерлары һәм артистлары, тамашачының театр белән даими кызыксынып торуы турында күп мәгълүмат алам.

Иртә белән үк башланган сөйләшүебез дәвам итә һәм мин аның һич тә әңгәмәгә охшамавыннан сискәнеп китәм – нәтиҗәдә Камил турында әле дә бернәрсә белмим бит. Ашыга-кабалана сорауларымны бирә башлыйм: кайда тудың? бала чагың ничек үтте? театрга кайчан килдең? беренче остазың кем? театрда сиңа нинди вакыйга иң көчле тәэсир ясады?.. Әлеге дә баягы, һәр журналист төнлә уятып сорасаң да әйтеп бирә торган сәальләр җыелмасы инде. Сүз уңаеннан, бу «җыелма»ның алай ук начар түгеллеген әйтеп китәсем килә. Камилнең җавапларыннан менә дигән очерк язарга мөмкин һәм анда тамчы да уйдырма булмас иде: ул шагыйранә атамалы Таулар авылында алты балалы гаиләдә тууын (авылның исеме җисеменә туры килми – анда таулар юк икән); тормышлары авыр булуын, әтиләре үлүен, үзенең интернатка эләгүен, шул вакытта ук инде артист булырга хыяллануын, әмма үзен көзге алдына бастыруларын, анда арык, кечкенә, сипкелле малайны – үз чагылышын күрүен, ахыр чиктә елга техникумына укырга керүдән башка юл калмавын сөйли.

Бу урында тын алып: «Талант – язмышыңны үзең язу сәләте ул», – дип, купшы сүзләр әйтергә булыр иде.

Камил Камаловның актерлык язмышын, әлбәттә, таланты билгели, анысын исә елга техникумында студентлар оештырган эстрада театрында шөгыльләнгәндә «табылмый» хәле булмый. Камил соңрак Марсель Сәлимҗанов җитәкчелегендә актерлык белеме ала һәм аның язмышы ачыклана. Г. Камал исемендәге театрның баш режиссеры Сәлимҗанов – аның тормышында бик зур роль уйнаган, актерлык шәхесен калыплаштыруга ярдәм иткән һәм хәзер дә ярдәм итүче Остаз шул инде.

Театрның хәзерге репертуарында Камил сәхнә тота... Укучы миннән көткән шушы сүзләр язылмаган очеркыбызда хакыйкатькә тәүге хилафлык булыр иде.

җайлы бара

Чынлыкта Камил бик аз уйный, аның нибары ике зур роле бар, гәрчә, аның фикеренчә, бу шулай булырга тиеш тә, труппада халык күп һәм аларның һәммәсенә роль бирергә кирәк. Мин әле күпләргә кызыклы тоелган тагын бер нәрсәне белдем: Камил театрда нибары 100 сум хезмәт хакы ала, ниндидер бер азык-төлек кибетендә рәссам-бизәүче булып эшли, аның өенә кадәр шәһәрдән 1 сәгатьлек юл. Шул ук вакытта ул үзен бик бәхетле тоя. «Минем һәр эшем җайлы бара, – ди ул нык ышаныч белән, – әгәр ничек тә булса уңышсызлыкка очрасам да, төгәл беләм, озакка түгел ул».

Минем тагын аңа исем китә: Камилдән башка кемнәрдер тарафыннан кыерсытылганлык, үзебезгә тиешле, хакыбыз бар дип санаган нәрсәләрдән мәхрүм ителгәнлек хисен кичермәүче бер генә кешене дә искә төшерә алмыйм. Һәрчак уңуы турында сөйләгәндә, Камил, үзе уйнауга яисә уйнамауга карамастан, яңа, яхшы спектакль чыгаруны; театрның төсле чирәп түшәп ясалган күк төсендәге түбәсен, аның фикеренчә, бинаның бизәген һәм, ниһаять, шәһәр хакимияте белән тарткалаша торгач, иске мәчетне яңадан торгызу турында кабул ителгән карарны да үзенең җиңүләре һәм казанышлары рәтенә кертеп карый.

Камил, дөресен әйткәндә, хәзерге заманда юкка чыга барган кешеләр кавемен – романтик-энтузиастларны хәтерләтә. Ул, артисттан битәр, комсомол төзелеше әйдаманына охшаган. Театр әһелләре корылтае кунагы буларак Бөтенроссия театр оешмасына теркәлергә килгәч, аны һич тә актер дип танырга теләмичә, бик озаклап «сорау алу»ларын Камил көлеп-шаярып сөйли. Үзенең бу сәфәре турында җитди сүзгә күчкәч, ул Мәскәүдә күргәннәреннән алынган тәэсоратның үзе өчен ни дәрәҗәдә кыйммәтле булуы, «Театр тормышы» (Мәскәүдә нәшер ителгән журнал) бүләгән – аны үз шәкерте дип таныган Театр алиһәсе – Мельпоменa сынын алганда, гаять дулкынлануы турында әйтә.

Бу сын аның грим өстәлендә тора. Менә хәзер дә аның җиңүчеләргә генә хас горур карашын тоеп, артист грим сала: тиздән спектакль башланачак.

Бүген күренекле татар драматургы Н.Исәнбәт пьесасы буенча «Портфельле кияү» спектакле куела. «Урындагылар» тирәсендә барган мәзәк хәлләр күрсәтелгән тамашаны «Ревизор»ның татарча укылышы дияргә була. Вакыйгалар 30 нчы елларда республика район үзәкләренең берсендә бара.

Ленинградтагы «Астория» ресторанында элек швейцар-ишек сакчысы булып хезмәт иткән берәү туган ягына кайта һәм җирле эреле-вакллы түрәләр аны зур кеше – прокурор дип ялгышып, нәкъ Гоголь әсәрендәгечә диярлек гамәл кылырга тотына: кунакка дәшү, ришвәт бирү, ялагайлану дисеңме; кызларның һәрберсенең, шундый «яхшы» кияүне үзенеке итәргә теләп, ярыша башлавы дисеңме... Хлестаковның башыннан үткәннәр кабатлана, әмма вакыйгалар милли җирлеккә күчерелгән, нәкъ милли характерлар, татар юморының бөтен нечкәлекләрен кулланып, осталарча сурәтләнгән. Марсель Сәлимҗанов куйган спектакльдә халыкчан шаян рух хакимлек итә. Ул шамакайлар тамашасы принципларына нигезләнеп тудырылган, алымнар гади, әмма бик ныгытып уйланылган, төсләр җете, бар нәрсә ачык, аңлаешлы.

Уен өермәсе тамашачыны шуның кадәр бөтереп ала ки, Камилнең сәхнәгә чыгуын хәтта күрми калганмын икән, алай гына да түгел, аны башта бөтенләй танымадым. Кәкре аяклы, сикерә-атлый йөрүче героен күргәч, артистның буе тәбәнәкләнгән кебек тоелды. Йөзендә гади аң чагылышы, уйларга азаплану шәүләсе дә күренми. Камалов бурлыкка бирелгән кооператор Камәретдинне уйный. Ул гадәттә сәхнәгә каяндыр яннан, бик зур хисап кенәгәсе күтәреп керә. Спектакль алдыннан Камил бу тамашада аның гримы бик гади булуын, бары тик мул итеп пудра сибәргә генә кирәклеген әйткән иде: «Онда әвәләнгән кооператив күсесе» менә шулай килеп чыга. Бу шулай, төгәлрәк итеп әйтеп тә булмас иде. Каһарман авызын ачуга ук, аның һәр сүзне тотлыгып, азапланып сытып чыгаруыннан зал дәррәү көлә башлый.

Камил интегеп, көчәнеп эшләми, сәхнә басымын бөтенләй тоймый, үзе уйлап тапкан мескен, әмма шулай да хәйләкәрлектән бөтенләй мәхрүм булмаган авыл гыйбаты битлеген киеп алган да, үзен бик уңай хис итә, күрәсең. Аның уенында дель арте комедиясенә тәңгәллек таптым, Труффальдино ролендә атаклы Марчелло Мореттиның башкалар сөйләве аша гына таныш булган кыланмышлары искә төште.

Спектакльдә Камил алдан әзерләмәгән, уен барышында уйлап тапкан берничә күренеш булды: ул гаярьләнеп гаять зур тизлектә, һәр мизгелдә көлке очкыннары чәчеп сәхнә буйлап хәрәкәт итә. Ул да булмый, прокурор килгәнлекне ишеткәч, үз героены куркудан үләр дәрәҗәгә җитүен сурәтли, урындыкта тыныч кына утыра алмый, аяклары йөгерә үк башлый, ә үзе, туң баш булганга, алар артыннан өлгерә алмый, куып җитәргә тырышуы гаҗәп мәзәк килеп чыга.

Камилнең уен алымнары спектакльдә фарс дәрәҗәсенә җиткереп кырланган, шул ук вакытта ул үзе җитди, бербөтен, каршылыксыз, игътибарын туплаган. Сәхнәдәге чаялык – үзмаксат түгел, спектакльдәге вакыйгалар автор күзаллавыннан тайпылмый, бозылмый. Минемчә, Камил Камаловның зур уңышы дип танылырга хаклы бу роль аның актер буларак беркемгә дә охшамаган шәхесенең, үз йөзенең, иҗатының кабатланмас сыйфаты – «көчле театраль оптимистлык» (П.Марков) дигән нәтиҗә чыгарырга мөмкинлек бирә һәм боларның барысы каһарманыбызның, яшь булуына карамастан, тормышны яратуына, яшәешнең тулы, катлаулы һәм төрледән-төрле булуын тоеп-аңлавына нигезләнә.

Татьяна ВАРТАНОВА.
«Театр тормышы» журналы, 1987, №10.

Якташ шагыйрь кичәсе

Агымдагы елның гыйнварында якташыбыз, язучы, Татарстанның халык шагыйре, күренекле җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе Разил Вәлиевкә 75 яшь тулды. Шул уңайдан Түбән Кама шәһәре китапханәләр берләшмәсендә 2022 елны "Киң колачлы иҗат"дип исемләнгән фәнни-гамәли конференция белән ачып җибәрдек.

Конференциядә язучыларның Чаллы бүлеге җитәкчесе Факил Сафин, Татарстан Милли китапханәсенең фәнни-методик бүлеге җитәкчесе Люция Нәҗметдинова, баш китапханәче

Зәйнәп Җамалиева, Бөтендөнья Татар конгрессының Түбән Кама бүлеге җитәкчесе Рөстәм Ганиев, архитектор Фирдәвес Ханов, Аксакаллар шурасы әгъзалары, шәһәребез шагыйрьләре, махсус белем бирү уку йортлары укытучылары, татар теле мөгаллимнәре, китап укучыларыбыз катнашты.

Берләштерелгән китапханәләр системасы җитәкчесе Гөлназ Арсланова, чараны ачып, Р.Вәлиев ярдәме белән китапханәләр тормышына икенче сулыш өрелүен ассызыклады. Кол Гали исемендәге милли китапханә мөдире Гүзәлия Гыйбадуллина әдип иҗатына күзәтү ясады.

Татарстан Милли китапханәсенең баш китапханәчесе Зәйнәп Җамалиева, Разил Вәлиев, "Ел китабы" бәйгесен оештырып, татар китабын популярлаштыруга зур өлеш кертүен әйтеп,үзенең дә әлеге конкурста җиңүләр яулавын әйтте.

Язучы моннан 24 ел элек, туган төбәгендә яшь каләм ияләрен барлап, аларга иҗади яктан үсәргә ярдәм итү нияте белән, үз исемендәге премия булдырган иде. Шул елларда әлеге бәйгедә Түбән Кама төбәгендә яшәүче 1800дән артык укучы катнашкан. Алар арасында язмышларын әдәбият, сәнгать белән бәйләүчеләр булу – күңелле күренеш.

Каенлы авылы китапханәчесе Флера Гарипова, язучы Ф.Сафин һ.б. Чыгыш ясаучылар Разил Вәлиевне милләтпәрвәр шәхес, сәясәт эшлеклесе, нечкә күңелле лирик шагыйрь итеп тә, менә дигән прозаик, драматург, үткен телле публицист, күп кенә җырлар авторы буларак та ачты. Чарада якташыбызның лирик шигырьләре яңгырады, кунаклар аның сүзләренә иҗат ителгән "Кышкы учак" җырын тыңлап хозурланды.

Айгөл ГӘРӘЕВА,
Кол Гали исемендәге милли китапханә хезмәткәре.
Лилия БУСЫГИНА фотосы.

Баянчы профессор

(Рәгъде Халитовка 80 яшь)

Рәгъде Халитовның иҗат эшчәнлегенә багышланган әлеге язманы халкыбызның "Тырышкан табар, ташка кадак кагар" дигән мәкале белән башлыйсы килә. Чөнки без бүген галим, укытучы-музыкант, җәмәгать эшлеклесе, оста оештыручы булып танылган Рәгъде Халитовны хөрмәт вә ихтирам итәбез икән, моның төп сәбәбе аның тырышлыгы, кешелеклелеге кебек күркәм сыйфатлары булуы бәхәссез. Бу язманың максаты Р.Халитовны күкләргә ашырып мактау түгел, ә бәлки Рәгъденең балачагыннан ук килгән омтылышка ия булуы, кечкенәдән үк хыялланып, үз алдына максат куеп, аны тормышка ашыру юлларын табып, морадына ирешүен башкаларга үрнәк итеп күрсәтү. Кайберәүләргә бөтен нәрсә тормышта балачактан ук бик җиңел бирелә. Әмма җиңел бирелгән уңышлар еш кына бәрәкәтсез, кадерсез була.

Р.Халитов 1942 елның 17 февралендә Әгерҗедә туган. 3 яшендә рус гармунында көйләр чыгарып, ачылып җитмәгән тел белән үзе уйлап тапкан сүзләргә җырлар тезә. Әтисенең: "Уйна әле, улым, кунак абыйларың ишетсен", – дип, гармун уйнарга кушкан чагы аның хәтерендә калган.

"Дүрт яшемдә балалар бакчасына йөри башладым. Бу вакытта анда музыка коралларында уйный белүче юк иде. Бакча мөдире Бәһәр апа, минем гармун уйнаганымны белгәч, Кыш бабай бәйрәмнәрендә уйнарга гармуным белән килергә куша иде", – дип искә ала Рәгъде.

Бу вакытларда Әгерҗе радиосы айга бер-ике тапкыр һәвәскәрләр катнашы белән концертлар оештыра. Шундый тапшыруларга бакча балаларын да чакыралар, Рәгъде дә шул концертларда гармунда уйный.

1949 елда, җиде яше тулгач, Рәгъде беренче класска укырга керә. Укытучы Заһидә апа көннәрнең берендә: "Рәгъде, Октябрь бәйрәменә әзерләнә башлыйбыз, син гармуныңны алып кил әле", – дип, малайны дәрес вакытында өенә кайтарып җибәрә. "Икешәр-өчәр параллель класслар булган олы мәктәптә уздырыла торган бәйрәмнәрнең еш булуы мине шатландыра иде, – дип искә ала үзе. – Рәхәтләнеп гармунда уйнап, классташларымның җырлауларына, биюләренә ярдәм итә идем. Күп көннәрдә мәктәпкә барганда минем бер кулымда – чүпрәктән теккән букча, икенчесендә гармун иде. Гармунымның яңгыр, кар асларында калган көннәре дә еш булды.

1955 елның көзендә әниемнең энесе Мөбәрәкҗан абый армиядән кайтып, Әгерҗегә эшкә урнаша. Бервакыт Мөбәрәкҗан абый кечерәк баян (полубаян) сатып ала һәм зур омтылыш белән уйнарга өйрәнергә тырыша. Шактый гына көннәр үтә, ләкин – нәтиҗәсез. Көн саен сәгатьләр буе баянны кулыннан төшермәсә дә, бер көйне дә башыннан ахырына чаклы шома итеп уйнап чыга алмый. Ләкин, баянын сорасаң да, бер кеше кулына да бирми, эшкә киткән вакытта баян савытын (футлярын) ачкыч белән бикләп куя иде. Ул баян уйнаганда мин читтән генә күзәтеп, йә дәрес әзерләп утырам, йә итегемә олтан салам, йә нәрсә булса да ясыйм. Әмма күңелемдә һаман баянда уйнарга өйрәнү теләге. Ләкин ничек кенә җаен табарга. Теләк булганда җай табыла икән ул. Хәзер мин Мөбәрәкҗан абыйның иртән эшкә киткәнен көтеп торам да, баян футлярын үзем ясаган ачкыч белән ачам, бер-ике сәгать баянын уйныйм да, кире савытына бикләп куям.

Мөбәрәкҗан абый шулай, көннәрнең берендә, гадәттәгечә, бер көйнең ахырына җитә алмыйча тирләп утырганда, мин түзә алмыйча баян төймәләренең кайсыларына басарга кирәклеген күрсәттем. Ул шунда: "Мә әле, башыннан ук уйнап күрсәт", – дип, баянның каешларын минем җилкәмә элеп куя. Миңа шул гына кирәк. Мин баянның мехын киң итеп сузып, "урлашып" кына өйрәнгән көйләрне берсе артыннан икенчесен ярсый-ярсый уйнадым. Уйнап бетергәч, үзе югында баянын алуны сизде, ахры, дигән шик белән гармунны абый алдына куйдым да, ишегалдына чыгып йөгердем. Ул баянны рөхсәтсез алганны сизде, ләкин ачуланмады, киресенчә, моннан соң ул аны бервакытта да бикләмәде..."

Тугызынчы класста укыганда Рәгъдегә баян алып бирәләр һәм шул вакыттан бирле ул сәхнәләрдә баянда гына уйнап чыгышлар ясый. Кулда баян булгач, аны баянда уйнау осталары тирәнтен кызыксындыра башлый. Радиодан еш кына чыгыш ясаган баянчылар белән якыннан танышасы килә, алар кебек оста итеп уйнауны үз алдына максат итеп куя. Уфа, Казан радиосыннан тапшырылган концерт программаларын зур кызыксыну белән иртәле-кичле тыңлый. Аннан соң шушы осталарга охшатып уйнап, берничә сәгать рәттән баянны кулдан төшермичә, шөгыльләнә. Бәхти Гайсин, Таһир Кәримов, Мөхтәр Кәримов, Мөхтәр Әхмәдиев, Рокыя Ибраһимова, Габдулла Халитов һәм Рәис Сафиуллиннарның иҗатлары белән якыннан таныша. "Миңа Рәис Сафиуллинның уйнавы аеруча ошый иде. 1959 елда унынчы классны тәмамлагач, эшкә керү нияте белән, Казанга килдем. Күңелемдә – һаман да шул Рәис абый белән очрашу минутларын якынайту. Адресы буенча өенә бардым. Ишекләрен кактым, барып керсәм, кечкенә генә бер бүлмә, шул бүлмәнең бәләкәйлеген күргәч, аптырап киттем. Рәис Сафиуллин сез буласызмы, дип икеләнеп сорау бирдем. Мин булам, әйдә, уз, энем, уз, дип, мине караватк ырыенда торган урындыкка утыртты, йомышларымны, исем-фамилиямне, каян килүемне сорады. Мин аңа җыр-музыка укытучым Фрид Абдуллович язган хатны тапшырдым. Ул, укып чыкты да, мәктәбебезнең җыр укытучысы Рәхмәтуллин турында матур-матур сүзләр әйтте. Син дә, Фрид кебек, музыка яратасың икән, диде. "Ә кайда укырга ният белән килдең?" – дип сорады. Мин аңа эшкә урнашырга теләгем барлыгын әйттем. Мин баянда уйнап күрсәткәннән соң, Рәис абый елмаеп: "Энем, синнән менә дигән баянчы чыга, шөгыльләнүеңне генә ташлама. Мин сиңа ярдәм итәрмен", – диде. Тиздән мин төзелешкә эшкә урнаштым, буяучы-шомартучы булып эшләдем. Ел буе атнага ике-өч тапкыр Рәис Сафиуллинның кечкенә генә, ләкин һәрвакыт җылы, якты, кунакчыл фатирына баянда өйрәнергә йөрдем. Фатирлары бик кысынкы булса да, Рәис абыйның хатыны Мөһимә апа мине һәрвакыт якты йөз, үзенең туган энесенә караган мөнәсәбәт белән каршы ала һәм озатып кала торган иде. Рәис абый миңа баян өчен махсус эшләнгән әсәрләрне башкару серләрен өйрәтү белән беррәттән, Г.Камал исемендәге академия театрында барган кайбер спектакльләрдә баянчы булып катнашу чараларын да күрде. Ул мине шушы елда данлыклы театр сәхнәсендә барган барлык спектакльләрнең музыкасы белән таныштырды. Ике айлык җәйге гастрольгә алмашчы баянчы итеп әзерләде һәм үзе белән алып чыкты. Анда милләтебезнең бөек артистлары Хәлил Әбҗәлилов, Габдулла Шамуков, Хәким Сәлимҗанов, Фоат Халитов, Касыйм Шамильский, Фатыйма Ильская, Вера Минкина, Рауза Хәйретдинова һ.б. бик күп артистлар белән иҗади аралашуда булдым. Хәй Вахит пьесасы буенча сәхнәгә куелган "Беренче мәхәббәт" спектакле шул җәйдә Бөгелмә, Әлмәт, Азнакай, Лениногорск, Октябрьский шәһәрләрендәге һәм районнарындагы 50 дән артык сәхнәдә күрсәтелде һәм анда спектакльләрнең музыкаль бизәлеш өлешен мин җиренә җиткереп башкарырга тырыша идем".

1960 елның июнь аенда Казан педагогика институтында музыка факультеты ачыла дигән хәбәр тарала. Рәгъде кабул итү комиссиясенә юл тота һәм шул көннән башлап аның язмышы шушы югары уку йорты белән бәйләнгән.

Чын профессиональ музыкант булып ул музыка факультетында мәшһүр укытучы-баянчы В.П.Плетнев классында белем алып, республикабызның күренекле җырчылары белән концертларда чыгышлар ясап танылa. Рәгъденең педагогик эшчәнлеге турында, әлбәттә, бик күп сөйләргә була. Чөнки 30 ел дәверендә йөздән артык яшүсмерне, шул исәптән авыл яшьләрен дә, баянда уйнарга өйрәтә. Аның шәкертләрен республикабызның барлык төбәкләрендә, Идел-Урал буе шәһәрләрендә, авылларында очратырга була һәм бу очрашулар гадәттә, бәйрәм төсен ала: күпме истәлекләр, хатирәләр, сораулар, җаваплар...

Рәгъдене мин күпкырлы баянчы дип әйтер идем. Миңа, аның белән бергә сәхнәләрдә 30 ел буе чыгыш ясаган кешегә, Рәгъде хакында шулай дип һич шикләнмичә әйтергә буладыр; чөнки бит күп тапкыр баянда аның соло уйнаганын ишеткәнем бар. Ә инде аңа кушылып җырлаганда ул бөтенләй икенче Рәгъдегә әйләнә: ул, сине тыңлап, сиңа комачауламыйча уйный, булыша. Баянчының бу сыйфатларга ия булуы бик мөһим. Аккомпаниаторлар белән үзара ниндидер аңлашу булмаса, ул инде җырлау түгел, ул – кәефсезләнү, канәгатьсезлек һәм бәхәсләшүгә кайтып кала торган хәл. Рәгъденең баянчы буларак иң күркәм, миңа ошаган гадәте дип әйтимме инде, әллә холкымы – ул бервакытта да репетициядән баш тартмас. Тәүлекнең теләсә кайсы вакытында баянын кулга алып, синең белән сәгатьләр буе җырларны кабат-кабат уйнарга әзер. Уйнаган саен яңа бизәкләр табыла, кабатлаган саен җырның гүзәллеге ачыла бара.

Рәгъденең тагын бер күркәм сыйфатын әйтми калу гонаһ: ул җырчы фикере белән исәпләшә белә, үзен җырчыдан өстен тотмый. Син теләгәнчә уйнарга тырыша. Менә бу сыйфатлары аның ни дәрәҗәдә үз профессиясенә тугрылыклы, гашыйк булуы турында сөйли.

Тынгысыз табигатьле Рәгъде Халитов педагогика университетының музыка факультеты деканы, татар музыка кафедрасы һәм халык музыка уен кораллары кафедрасы мөдире булып эшләде. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, сәнгать фәннәре кандидаты. "Ничек өлгерде икән соң ул бу кадәр эшләрне башкарырга?" – дигән сорау туа. Өлгерә, бик төгәл башкара ул үзенең төп эшен – укытучылык һәм администратор вазифаларын. Чөнки төгәллек, куелган максатка таба бару – аның бала чагыннан ук өйрәнеп, чыныгып үскән гадәте.

Рафаэль ИЛЬЯСОВ.
2012 ел.

Тормыш сәхифәләре

Мәшһүр татар галиме, җәдидче, дини реформатор, мәгърифәтче, җәмәгать эшлеклесе, педагог, җиденче мөфти Галимҗан хәзрәт Барудиның тууына 165 ел тулды. Бу билгеле шәхес 1920 елда авылдашым, Дүртөйле районының Үткен авылында туган дин әһеле, ахун Мөхәммәдшакир хәзрәт Сәфәров белән очрашкан булган.

●Галимҗан Баруди.

Галимҗан хәзрәт Баруди бу хакта "Хатирә дәфтәре"ндә (1920 елның 12 июненнән алып сентябрь ахырына кадәр) болай дип яза: "Якшәмбе көн иртәнге 6-7 сәгатьләрдә Бирскига килеп җитеп, аз гына торгач, шәһәр имамы ахун Шакир әфәнде һәм Казан адәмнәреннән элек тә Бирски мәчетендә мөәзинлек кылган Габделвәли агай килеп керделәр, безне ишетеп, күрешә килгәннәр иде. Ахунның бер дистә чи йомыркасы, бер шешә сөт бүләге бар иде. Болар белән күрешеп, бераз сөйләшеп утырдык.

Ахун Шакир әфәнде Шура хөкүмәте тарафыннан кайбер бәхетсезлекләргә очраган, таланган, төрмәгә кергән, байтак җәза күргән иде. Хәзер тынеч кына тора икән. Бирскиның бик зәгыйфь, халкы аз, мәчете юк вакытларында ук Өчбүләдә укып, имам булган, әхлаклы, идарәле генә адәм, халыкны оешырды, яхшы мөнәсәбәтләрен җәлеп итте, бәрәкәт күрде".

Мөхәммәдшакир Мөхәммәдзариф улы Сәфәров 1857 елда Бөре өязенең Әсән волосте (хәзерге Башкортстанның Дүртөйле районы) Үткен авылында туган. Бөре өязенең Өчбүлә авылы мәдрәсәсендә Әхмәтҗан хәзрәт Шаһингәрәевтан (1817 - 15.02.1890) дини белем алган, Уфа губерна идарәсенең 1881 елның 12 октябрендә кабул ителгән указы (№3758) белән, хәзерге Дүртөйле районындагы Үткен авылы мәчетенә имам-хатыйб һәм мөдәррис исемнәре бирелеп, 1нче имам итеп билгеләнә.

1898 елның 12 октябрендә Бөре шәһәрендә 40 ел дәвамында имам булып торган өлкән яшьтәге Җамалетдин хәзрәт Тләшев Диния нәзарәтенә, туган ягына кайту сәбәпле, аны бу вазифадан азат итү турында үтенеч биргән. Шул ук вакытта ул варис сыйфатында мулла Мөхәммәдшакир хәзрәт Сәфәровны үз урынына тәкъдим итә.

Өяз земство идарәсе чакыруы буенча Мөхәммәдшакир хәзрәт Сәфәров Бөргә килә һәм 1898 елның 1 ноябреннән өяз съездында һәм башка хөкүмәт учреждениеләрендә мөселманнарның антын кабул итү, земство дәваханәсендә вафат булган диндәшләрен җирләү мәрасимен башкару вазифасына керешә, шуның өчен елына 120 сум күләмендә жалование алган.

Мөхәммәдшакир хәзрәт Сәфәров 1910 елның 8 февралендәге указ (№ 506) буенча Бөре шәһәре җәмигъ мәчете имамы вазифасына тәгаенләнә. Моннан тыш, 1913 елның 31 октябрендәге указ (№ 4634) белән аңа "ахун" дәрәҗәсе бирелә.

Фәнүз ХӘБИБУЛЛИН.

"Кызыл таң".

* * *

Г.Баруди Бохарадан гыйлемне зиһенендә генә түгел, ә 600 килограмм авырлыктагы китапларда да алып кайткан. 5-6 мең сумлык китап җыеп, Казан каласына кайтып төшә ул. Чагыштыру өчен: XIX гасыр азагында, бер ат яки сыер 25 сум торган, тышлы тунның бәясе дә - 25 сум булган.

* * *

Татар мәктәпләре өчен уку китапларына булган кытлык мәсьәләсен хәл итү йөзеннән, Г. Баруди 1890 елларда «Мәгарифел исләмия» исеме белән тугыз китапчык әзерләп бастыра, алар дистә тапкыр һәм аннан да күбрәк нәшер ителеп, бөтен ил буенча тарала. Сериянең тәүге басмасын «Сәвад хан» («Белемле бала») исемле әлифба тәшкил иткән. Ул Исмәгыйль Гаспралының кырымтатар телендә бастырылган әлифбасыннан Идел төбәге татар балалары өчен атап язылуы һәм аларның тел үзенчәлекләрен исәпкә алып эшләнгән булуы белән аерылып торган.

* * *

Галимҗан Барудиның берничә тәхәллүсе булган. Тулы исеме – Галимҗан бине Мөхәммәтҗан бине Бинәмин бине Гали бине Колмөхәммәт. Дарының гарәпчәсе – "баруд", киләчәктә галим булып киткән Галимҗан "Баруди" дигән тәхәллүсне әнә шул сүздән ала. Шунысы мәгълүм: башлангыч чорларда Галимҗан язганнарын "Пороховой" дип имзалый торган була. Әмма ул вакытта Казанда "Пороховой Фатих" дигән җиңелчәрәк җыр һәм "Пороховой Фатыйма" кушаматлы борынгы һөнәр иясе – бер хатынның даны таралган була. Шуңа күрә, мәшһүр остаз үз тәхәллүсен гарәпчәләп "Баруди"га үзгәрткән.

* * *

1908 елның март аенда Габдулла Апанаев, бертуган Салихҗан һәм Галимҗан Галиевләр, Габделхәмид Казаков гаиләләре белән бергә «сәяси яктан зарарлы эшчәнлекләре өчен» Вологда губернасына сөреләләр. Соңрак Россиянең эчке эшләр министры Себергә сөрүне чит илгә китү белән алыштыра. Шулай итеп, Галимҗан Баруди 1908 елның көзендә Россиядән чыгып китеп, Төркия шәһәрләре аша узып, хаҗ кыла, Сүриядә яши. 1910 елның 10 апрелендә Галимҗан, Казанга әйләнеп кайтып, яңадан "Дин вә әдәб" журналын чыгара башлый һәм "Мөхәммәдия" мәдрәсәсендә укытуын дәвам итә.

* * *

1912 елның 28 февралендә Галимҗан Баруди Казан губернаторына шәһәрдә бушлай хезмәт күрсәтә торган китапханә ачу турында рөхсәт сорап мөрәҗәгать итә. 1914 елның 11 гыйнварында аңа гарәп, фарсы, төрек, рус һәм татар телләрендә язылган китаплардан торган китапханә ачу рөхсәте бирелә. Җәмәгатьчелеккә бушлай хезмәт күрсәтүче беренче китапханәне ачкан шәхес буларак та тарих битләрендә теркәлгән.

* * *

Галимҗан Баруди 1917 елның Февраль инкыйлабын Төркестанда каршылый. Биредә ул танышлары белән очраша, мәчетләрне зиярәт кыла, вәгазьләр укый. Май башында аңа көтелмәгән телеграмма килә. Әлеге телеграммада Галимҗан Барудиның Бөтенроссия мөселманнар съезды тарафыннан Диния нәзарәте мөфтие итеп сайлануы хәбәр ителә. Туганнары белән киңәшләшеп, якыннарының хәер-фатыйхасын алып, ул әлеге тәкъдимгә уңай җавап бирә һәм, сайланылган мөфти буларак, Уфага китә.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

12 март (шимбә). ***Шәгъбән аеның 9 нчы көне. 11 нче Ай тәүлеге. Ай Кысла йолдызлыгында,10.07 сәгатьтә калка, 4.57 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 11.33 сәгать.***

Үзгәрү, сафлык, катгыйлык көне. Һәр эштә дә сак һәм игътибарлы булу сорала. Башланган эшне ахырына җиткерергә кирәк. Бу көннең энергетик куәте бик зур, кешедә искиткеч табигый көч уянырга мөмкин. Арып-талганчы эшләргә ярамый. Сизү әгъзалары, йөрәк, умырткалык, үпкә зәгыйфь.

Ангинадан – канәфер

5 канәфер кадагын төеп, 1 стакан кайнар сөткә салалар да, бераз суыткач, һәр йотымны озаклап авызда тотып, эчеп бетерәләр. Яисә 10 данә канәферне 250 мл кайнар суга салып, төнәтәләр һәм шуның белән көненә 4 тапкыр авызны чайкыйлар. Зарарлы бактерияләрне юк итү өчен, 1 канәфер кадагын кәнфит кебек суырырга кирәк, бүленеп чыккан селәгәйне йота баралар, туйдыргач, канәферне чәйнәп йоталар – ул эчтәге суалчаннарны да үтерә.

13 март (якшәмбе). ***Шәгъбән аеның 10 нчы көне. 12 нче Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында, 11.09 сәгатьтә калка, 5.27 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 11.38 сәгать.***

Шәфкать, сабырлык, мәхәббәт энергиясенә бай көн. Сәламәтлеккә игътибарлы булырга, йөрәккә киеренкелек китермәскә кирәк. Ашкайнату әгъзалары, кан әйләнеше системасы зәгыйфь. Дарулар яхшы үзләштерелә.

Банан һәм анар кесәле

Бронхиттан банан кесәле файдалы. 1 банан, 1 аш кашыгы шикәр, 200 мл су кирәк. Бананны изәләр, шикәр, кайнар су кушып, яхшылап болгаталар, капкач каплыйлар һәм 30 минут төнәтеп, эчәләр. Йөрәк авыртканда, анемия булганда исә анар кесәле файдалы. 3 стакан анар согы, 40 г крахмал, 0,5 стакан су, тәмен чә шикәр кирәк. Крахмалны салкын суда эретәләр. Сокны кайнарлатып, әкрен генә крахмал өстенә агызалар, тиз генә болгаталар, шикәр өстиләр, кайный башлауга, уттан алалар.

14 март (дүшәмбе). ***Шәгъбән аеның 11 нче көне. 13 нче Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында,12.23 сәгатьтә калка,5.48 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 11.42 сәгать.***

Үзгәрешләр көне. Үткәннәр турында уйланып, нәтиҗә ясау яхшы. Ач торырга ярамый – теләсә нәрсә ашарга була. Аралашу, белем алу өчен уңай вакыт. Йөрәк, тире, кан тамырлары зәгыйфь. Чикләвек ашау файдалы.

Чабыр шифа бирә

Түбән кислоталы гастрит булганда, 1 аш кашыгы чабыр үләнен ярты стакан кайнар суга салып, бүлмә температурасына кадәр суыталар, ашарга ярты сәгать кала кала жылы килеш эчәләр. Пиелонефрит булганда, 1 аш кашыгы чабыр үләне һәм чәчәген 1 стакан кайнар суда 30

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга карама

минут төнәтәләр, көненә 5 тапкыр 1әр аш кашыгы эчәләр. Катаракта булганда, коры үләнне порошок итеп төяләр, 100 г үләнгә 500 г бал кушып, сулы савыт эчендә 1 сәгать җылыталар, әледән-әле болгаталар. Суыткычта саклыйлар, көн саен йоклар алдыннан 1әр чәй кашыгы кабалар.

15 март (сишәмбе). ***Шәгъбән аеның 12 нче көне. 14 нче Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында,13.44 сәгатьтә калка,6.03 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 11.47 сәгать.***

Иң әһәмиятле эшкә тотыну өчен уңайлы көн. Бүген башланган эш бик яхшы тәмамланачак. Теләсә нинди вак-төяккә игътибарлы булу сорала. Эчәклек һәм тирене чистарту уңай нәтиҗә бирә. Ашказаны асты бизе зәгыйфь. Балан, фасоль, борчак, арпа ашау файдалы.

Йолдызак – йөрәккә дәва

Йөрәк авыртканда, 1-2 уч йолдызак (мокрица) үләнен ярты литр кайнар суда, яхшылап төреп, 6 сәгать төнәтәләр, көненә 3-4 тапкыр, ашарга 30 минут кала, яртышар стакан эчәләр. Дәва курсы - 2-3 атна. Атеросклероз булганда, 4 чәй кашыгы вакланган петрушка тамырын 300 мл кайнар суда 10 сәгать төнәтәләр, сөзеп, көненә 4 тапкыр, ашарга 30 минут кала, 1 әр аш кашыгы эчәләр.

16 март (чәршәмбе). ***Шәгъбән аеның 13 нче көне. 15 нче Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында,15.07 сәгатьтә калка,6.14 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 11.52 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Бүген кеше үз нәфесенең теләк һәм коткыларына бигрәк тә бирешүчән.Тиелгәсыз хисләр күңелсез вакыйгага китерергә мөмкин. Тәэсирләнүчән кешегә аеруча кыен. Балан, мүк җиләге ашау файдалы.

17 март (пәнҗешәмбе). ***Шәгъбән аеның 14 нче көне. 16 нчы Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында, 16.31сәгатьтә калка,6.24 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 11.56 сәгать.***

Тыныч, иҗади, уңышлы көн. Һәрнәрсәдә гармониягә омтылу, җан тынычлыгын саклау мөһим. Дулкынландыргыч очрашулар булырга мөмкин. Килешүләр төзү уңай нәтиҗә бирә. Кан авырулары кискенләшә. Беркемгә дә үпкә сакларга ярамый.

18 март (җомга). ***Шәгъбән аеның 15 нче көне. 17 нче Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында, 17.56 сәгатьтә калка,6.33 сәгатьтә бата. 10 сәгать 17 минуттан тулы Ай. Көн озынлыгы 12.01 сәгать.***

Мәхәббәт, иҗат, яшәү шатлыгы көне. Бернәрсә дә планлаштырмыйча, теләгән нәрсәне генә эшләү яхшы. Нерв һәм эндокрин системаларга, күзгә игътибарлырак булу сорала. Үпкәләшкән кешеләр белән дуслашыр вакыт. Яшелчәләрне күбрәк ашау файдалы.

Кабак коймагы

300 г чистартылган кабак, 1 стакан кефир, 2 йомырка, 5 аш кашыгы он, ярты стакан шикәр, бер чеметем ванилин, үсемлек мае кирәк. Кабакны уртача угычтан уалар. 30-35 градуска кадәр җылытылган кефирга шикәр һәм ванилин салып болгаталар, аннары он кушып туглыйлар. Йомырка сыталар, кабакны өстәп болгаталар һәм табада кыздыралар. Табынга каймак белән бирәләр.

Моң кайтты

«Казан утлары» журналының 2022 елгы 1 нче санында Айдар Хәлимнең «Моң кайтты» дигән повесте басылды.

Повесть, туган якларыннан читкә китеп, гомере буе кендек каны тамган җирен сагынып яшәгән Сабирҗан образы белән таныштырудан башлана. Ят җирләрдә аның җанын моң саклап яшәтә. Ул Сара Садыйкова көйләренә, тегәләрәк әйткәндә, аның Х.Туфанның «Тын сукмакта тал тирбәлә» шигыренә һәм Г.Бәшировның «Җидегән чишмә» сүзләренә язылган җырларына гашыйк. Аның беренчесен Хәйдәр Бигичев, икенчесен Зөһрә Сәхабиева башкара. Сабирҗан әлеге көйләрне тыңлап туя алмый. Ошбу талантлар турында, кайда очратса да, ташка басылган мәгълүматлар җыя. Аларның «бердәм гаилә, бербөтен моң академиясе» булып яшәүләренә соклана...

Әсәр фәлсәфи уйланулар, тирән психологик кичерешләр белән язылган, аны күз яшьләрсез, Сабирҗан кебек кайта-кайта «сагышыңны сыкмый» уку мөмкин түгел. Автор әйтмешли, «Хәйдәр Бигичевне югалту – Тукай, Такташ, Сәйдәш, Хәсән Туфан кебек бөекләребезнең вафатыннан соң, милләткә килгән бишенче зур югалту иде»... Милләтнең дүрт алтын баганасын югалтканнан соң, бишенче зур каза!..

Ул авыр көннәр, йөрәгемне әчеттереп торган тирән яра булып, минем дә хәтеремдә саклана. Чөнки без Зөһрә һәм Хәйдәр Бигичевләр белән дистә еллар буена бер йортта, бер подъездда ут күршеләр булып, аралашып яшәдек. Мин Зөһрәнең озын буйлы этисен – һәрвакыт түбәтәйдән йөргән Котдус абыйны, кайбер туганнарын да, шулай ук Хәйдәрнең әтисе Габбас әфәндене, әнисе Рәшидә ханымны да күргән, бер-ике кәлимә булса да сүз алышкан кеше. Хәйдәрнең эти-әниләре бик чибәр, төз буйлы, яшь чырайлы иде. Алар, парлап килүләренең берсендә, Хәйдәрләрдә байтак озак кына торып, табибләргә дә күренеп, олы уларының зур тәрбия, даими кайгыртучанлыкта яшәвен күреп, бик канәгать калып китте. Хәйдәр кебек үк азамат гәүдәле, өчесе бергә Мәскәүдән килеп төшкән энеләре белән, Зөһрә пешергән ит бәлеше белән сыйланып, табында утыргагыным да булды. Энекәшләре аз сүзле кебек булып исемдә калса да, бер-берсен күз карашларыннан аңлаган ир белән хатын, кунакларның күңелен күреп, әле берсе, әле икенчесе төрле кызык хәлләр турында сөйли иде. Хәйдәр кычкырып көлә, Зөһрә егетләрне кыстый-кыстый кунак итә...



Ә Хәйдәрнең сеңлесе Халидә, гомумән, ике арага тузан төшермәде, дип әйтсәм дә ялгышмам. Үзе белән Мәскәүдән дефицит тәм-том да алып килә. Без Зөһрә белән аларны «урнаштыру» өчен тиз генә күршеләргә эндәшеп чыгабыз. Ул исә: «өче белән», «бише белән» дия-дия «Казан хәерчеләре»нең күңелен күрә...

Мин дә тол, Зөһрәбез дә көтмәгәндә генә ирсез калды. Җирләү мәшәкатьләрен, хушлашканнан соң башкарыла торган бөтен йолаларны үтәп, Зөһрә акыл зирәклеге белән Хәйдәрнең мирасын туплаgra, аларны кассеталар, китап-альбомнар итеп халыкка җиткерергә, истәлекләр язарга тотынды. Затлы нәселеннән килгән иман-гыйбадәт канунларына керен чумды. Хәйдәренең репертуарын тулысы белән күңеленә сеңдерде, үзе дә яңа җырлар өйрәнде. Йөрәге сайлаган сүзләргә көйләр иҗат итте. Чакырган бер генә җирдән дә баш тартмыйча, халкына хезмәт күрсәтте. Мәхәббәтенә, мәгърур арысланына (Хәйдәр – гарәпчәдә «арыслан» дигәнне аңлата) лаек булып яшәү өчен бөтен көчен, талантын багышлады!

Айдар Хәлим әсәрен «Моң кайтты» дип атаган. Әйе, Зөһрә Сәхабиева-Бигичева исән вакытта ул моңнар татар халкын ташлап китә алмас! Хәерле, бәрәкәтле озын гомер бирсен Зөһрәбезгә – Татарстаныбызның Салих-Тукай авылы кызы, моңлы сандугачыбызга!.. Ә инде каләмдәшебез Айдар Хәлимгә килгәндә, халкыбызның йөрәгеннән өзелеп төшкән кадерлеләребезне зурлаганы, алар истәлегенә шулкадәр дә гүзәл, иманлы әсәр иҗат иткәне, Моңга һәйкәл куйганы өчен мең-мең рәхмәт!

Бүген дә янып-ялкынланып иҗат итүче, сиксән яшенә җитеп тә каләмен кулыннан төшермәгән, һәркайсы тирән егәрле 72 китап язган, татар халкының якты киләчәге өчен сәяси ачлыкларда утырган, каләмдәшләренең (олысының-кечесенең) уңышларына сөенеп, матбугат аша һәрдаим рәхмәтен җиткереп торган, киң, әмма ифрат та яралаучан күңелле, саекмас талант иясе Айдар Хәлимнең үзен дә татар халкының алтын баганасы, дип атыйсы килә. Ул гына яза ала торган тирән эчтәлекле, кешелекле әсәрләре белән куандырырлык, көч һәм илһам бирсен аңа!

Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА.

Тамаша заллары чакыра

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

11 март – «Сагынырсызмы?» (А.Шәйдуллин).
12 март – 12.00, 12.30 – «Дәрсе гыйбрәттер театр...» (Р.Мөхәммәтшин). 18.00 – «Килә ява, килә ява» (З.Хәким). 19.00 – «Килмешәк» (С.Гаффарова).
13 март – «Зәңгәр шәл» (К.Тинчурин).
16 март – «Бию пәрие» (И.Зәйниев).
17 март – «Әтәч менгән читәнгә» (А.Гыйләҗев).
18 март – «Бабайлар чуагы» (И.Зәйниев).

М.ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

12, 13 март – «Шүрәле» (Ф.Яруллин).
16 март – «Турандот» (Дж.Пуччини).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

11 март – «Алай түгел, болай ул» (Т.Миңнуллин).
12 март – «Акча бездә бер букча» (З.Хәким).
13 март – «Чулпан» (Ш.Хөсәенов).
15 март – «Мәхәббәт баскычы» (Ш.Фәрхетдинов).
16 март – «Кияүләр» (Х.Вахит).
17 март – «Ак тәүбә, кара тәүбә. Безнең көннәр» (Т.Миңнуллин).
18 март – «Ядәч! Исемдә! Бер гаилә трагикомедиясе» (Й.Миңнуллина, М.Гафурова, А.Бикбулатов, Э.Дусаева).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

12 март – 13.00 – «Асылкош җыры» (Р.Мөхәммәтшин). 18.00 – «Супер кияү» (Т.Миңнуллин).
13 март – «Микулай» (М.Гыйләҗев).
15 март – «Озын-озак балачак» (М.Кәрим).
18 март – «Алтынч[ае]ч» (Л.Янсуар, Р.Гарипова).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

11 март – 11.00, 13.00 – «Аленький цветочек» (С.Аксаков). 19.00 – «Адәмнәр» (Г.Ибраһимов).
12 март – 11.00, 13.00, 15.00 – «Гуси-лебеди» (Л.Кожевников). 13.00 – «Кәтүкнең сихри төшләре» (И.Әхмәдиев, Х.Ибраһим).
13 март – 10.00 – «Один день из жизни улитки» (Ольга һәм Юрий Устюговлар).12.00, 14.00 – «Теремок» (С.Маршак).
16 март – 11.00, 13.00 – «Хаврошечка» (Л.Савчук).
17 март – 11.00, 13.00 – «Принцесса Крапинка» (А.Шмидт).
18 март – 11.00 – «Принцесса Крапинка» (А.Шмидт). 19.00 – «Әлдермештән Әлмәндәр» (Т.Миңнуллин).

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

11 март – Татарстан Республикасы дәүләт филармонияджаз оркестрына кушылып Олег Бутман һәм Наталья Смирнова-Бутман уйный һәм җырлый.
12 март – Җырчы Владимир Васильев концерты.
13, 14 март – Татарстанның атказанган артисты Филүс Каһиров концерты.
15 март – «Нотр дам де пари» мюзиклы.
16 март – Филүс Хисаметдинов җырларыннан концерт.
17 март – Татарстан Республикасы халык музыка уен кораллары дәүләт оркестры концерты. Солистлар – В.Змеу, М.Селезнева.

С.СӘЙДӘШЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ЗУР КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

11 март – Наталья Железных ансамбле концерты.
13 март – Балалар өчен «Lego-music» дип исемләнгән музыкаль уен.

Зөлфәт Хәйруллин кытыклары

Һич онытылмый

1974 ел. Мин Казанның В.И.Ленин исемендәге мәдәният сараенда рәссам Илдар Зариповның студия-остаханәсендә рәсем ясау серләренә өйрәнәм. Безне бервакыт Социалистик шәһәрчектәге Бакый Урманче остаханәсенә алып бардылар. Шуннан мин бөек рәссам янына кергәләп йөри башладым. Остаханәнең ишек алдына керүгә зур сыннар каршы ала. Бакый ага бик гади, имәндәй нык кеше. Мин аны төрле сораулар биреп йөдәтәм. Ул иренмичә, әкрен генә җавап бирә. Бервакыт аның белән трамвайда кайтырга туры килде. Мин аңа билет алдым. Ул: «Алай ярамый!», – дип билет өчен акча бирде. Менә шундый кечкенә хәлләрдә дә ул кеше булып кала белде.

Армиядән урта белемле булып кайттым

Армиягә киткәндә мин үз алдыма максат куйдым: Мәскәү, Ленинград, Казан кебек өч шәһәрнең берсенә эләгергә һәм армиядә хезмәт иткән вакытта кичке мәктәпне тәмамлап, урта белем алып кайтырга! Бәхетемә, шулай килеп чыкты да. Мин хәрби хезмәтне Казан югары танк училищесында укыту ремонт ротасында үттем.

Бу болай булды. Армиягә китәр алдыннан, рәссам буларак, Балтач хәрби комиссариатын рәсемнәр, плакатлар белән бизәүдә катнаштым. Татвоенкоматта безне Балтачтан озата килгән лейтенант бер подполковникка мине рәссам буларак күрсәтте. Ул миңа кәгазь белән карандаш биреп, рәсем ясап күрсәтергә кушты. Мин тоттым да шундагы бер капитанның рәсемен ясап бирдем. Рәсем подполковникка ошады. Бер-ике сәгатьтән мин инде танк училищесында карантинда идем.

Рәссам һөнәре армиядә күп кенә авырлыклардан коткарды. Бер ел тулгач, замполит белән Павлюхин урамындагы 16 нчы кичке эшче-яшьләр мәктәбенә барып сөйләштек. Инде укулар башланып 4-5 ай үтсә дә, мине алдылар. Шунысы кызык, бу турыда рота командиры да, югары хуҗалар да белмәде. Замполит белән старшина гына белде. Кич эштән кайтуга мин укырга китәм. Кич белән тикшергәндә сержантлар аптырый: мин юк! Старшинага әйтәләр, ә ул дәшми. Мин төнлә укудан кайтышлый старшинага күз кысам, ул да шулай итә. Бу инде бөтенесе тәртиптә дигәнне аңлата. Шулай итеп, аттестатны мин «самоволка»га йөреп алдым.

Шулай да була...

Казанда бер елны бер көндә ике җиргә тамада итеп чакырдылар. Шуларның берсе хәзер инде эшмәкәр, кем әйтмешли, «кәттә» иде. Ул: «Әгәр миңа килмәсәң, ни өчен бармагаыңны дусларым аркылы беләм. Мин фәлән ел төрмәдә утырган кеше, бөтен бандитларны җыям, сүзең дөрес булмаса, ике кулыңның да бармакларын чабам!» – дип янады. Нишләтәсең, аңа барырга туры килде. Шунысы кызык: мәҗлес тәмамлангач, чын дусларча, бик хөрмәтләп өйгә китереп куйды. Ә шуның аркасында икенче җиргә чакырган дустымны югалттым.

Казанга терәлеп торган Петровский бистәсендәге туй ахырында ботинкамның бер сыңары югалган иде. Күршеләреннән көчкә эзләп таптык.

Язучы Хәбир Ибраһимовка

Язу, сызуга Хәбир,
Бөтен яктан да маһир.
Икенче төрле әле,
Аны атыйлар Ахир.
Үзе шагыйрь, драматург,
Юмор, сатира остасы.
Шуңа күрә бу талантны
Көн дә килә котлыйсы.

Юмор остасы, алып баручы Рамил Шәрәповка

Айга да менәр, кояшка да җитәр,
Мондый кешеләр сирәк.
Безнең халыкка менә шундый,
Уңган егетләр кирәк.
Әллә кайдан кызык таба,
Шул арада көлдерә.
Көне буе мәзәк сөйли,
Ничек ятлап өлгерә.

Шагыйрь Ленар Шәехка

Ленар Шәехны
Кем итсен гаеп.
Талантлы егет,
Бара шәбәеп.

Буйга да үсте,
Сәләте көчле.
Галәмдә йөргән
Ракета төсле.

Рәссам-моменталист



Язучы, сәхнә остасы Алмаз абый Хәмзин мине дә үзе оештырган концертларына ала иде. Бөекләр, даһилар арасында йөрү, минем өчен горурлык иде. Без биш татар: Равил Шәрәфиев, Рәшит Шамкай, Алмаз Хәмзин, Камил Кәримов һәм мин – Зөлфәт Хәйруллин Казан Сабан туйларында катнаша идек. Татарның атаклы тел бистәләре чыгышлар ясаганда, мин Сабан туена килгән кешеләргә портрет – шаржларын ясарга тиешмен. Дәү, кәкре борынлы, зур колаклы, кысык күзле кешеләр очраса, рәсем ясавы җиңел, мин аларны берничә минутта сызгалап, кәгазьгә төшереп бирәм. Ә менә, хатын-кызларны һәрвакыт матур иттереп ясарга кирәк, чөнки алар үпкәләргә дә мөмкин. Иң карт әби дә, үзен матур, яшь кыз итеп күрергә тиеш.

А.Хәмзин: «Син сәхнәгә чыгып, теләгән кешенең рәсемен берничә секундта ясап бирергә тиешсең, син аны булдырасың!» – дия иде. Шунан соң Камил абый Кәримов мине: «Рәссам – моменталист» дип атый башлады, янәсе, мин рәсемнәрне момент эчендә ясап бирә алам.

Вәт, ичмасам, сыйлады

Бер тапкыр туганым Дамил белән аның бер танышына кунакка бардык. Ул иске генә фатирында безне бик яхшы итеп, ачык йөз белән каршы алды, аңлашылганча, күрәзәчелек белән шөгыльләнә икән. Нindидер китаплар актарып, төрле цифрлы әйберләр әйләндерә-әйләндерә, ул безнең киләчәкне юрый башлады. Имеш, тиздән сугыш башланачак, безгә ничек тә хәрби хезмәттән котылып калырга кирәк. Тагын әллә нинди киңәшләр яудырды, озак кына итеп ит һәм аның файдасы турында сөйләде. «Ит ашарга кирәк, ул бөтен авырулардан да коткара», - диде ул һәм безне аш бүлмәсенә чакырды. Безгә берәр тәлинкә аш бүлеп бирде. Шуннан соң чүмеч белән кәстрүлдән нидер эзли башлады. «Монда ит булырга тиеш иде, кая гына юкка чыккан», – диде ул, аптырап. Тәки табылмады, итсез аш чөмереп кайтып китәргә туры килде. Бу хәл исемә төшкән саен ит ашыйсы килә башлый.

Татарстанның халык артисты, «Мунча ташы» театры җитәкчесе Гамил Әсхәдуллага

Бар бит шундый кешеләр,
Алар булганда кызык.
Авырлыклар онытыла,
Җырлыйсы килә сузып.
Гамил дустым менә шундый,
Ямь таба ул тормышта.
«Мунча ташы» театры да
Гел ирешә уңышка.

Ачлык яшәртә икән

Академик Владимир Скулачев инде күп еллардан бирле картаю проблемалары белән шөгыльләнә һәм, тере күзәнәккә хас биология законнарын яхшы белгәнгә, картаюдан “дәвалап” була, дип саный. Яшьлек эликсирын эзләп галимнәр күптән баш вата, әмма бүгенгә кадәр картаюны акрынайта торган беринди матдә яки ысул табылмаган. Шулай да бер ысул бар, дип саный академик. Бу – ашауны чикләү. Әгәр хайван ярым ач тора икән (ягъни аңа үзе ашый алган ризыкның 70 проценты гына бирелә), ул озаграк яши. Тәҗрибәләр күрсәткәнчә, гомер озаеп кына калмый, бәлки картаю процессы да акрыная, йөрәктәге ишемия чире, глаукома, катаракта кебек картлык авырулары һәм хәтта яман шеш тә чигерелә икән. Туклануны чикләү нинди дәрәҗәдә картаюның генетик программасын (Скулачев картаюны программа дип саный) “сүндереп тора”. Эволюция барсын өчен, гадәттә организм үзен-үзе картаерга мәҗбүр итә, ә инде ачлык башланган икән – монда эволюция турында уйларга вакыт калмый, гомерне саклау өчен көрәшергә туры килә! Организм үз резервларын эшкә җикмәсә, бу очракта кешелек үлеп юкка чыгачак. Һәм организм бик күп энергия суыра торган картаю процессын туктата да, бөтен көчен ризык табуга юнәлтә. Ә инде житәрлек ризык табылгач, тормыш балдай тоелмасын өчен, картаю программасы кабат “кабына”. Академик Скулачев, картаюны акрынайтуның бердәнбер ышанычлы юлы – туйганчы ашамау, дип саный, тик монда чама хисен югалтмау мөһим – Хуҗа Насретдин ишәге кебек ашамыйча торырга өйрәнгәч кенә аягыңны сузмагаең.

(“МедНовости.ру”).

Аспирин: дәвамы, зыянмы?

Инфаркт һәм инсульттан саклану өчен, дөньяда миллионлаган кеше һәр көнне аспирин эчә. Тик менә Оксфорд галимнәре фикеренчә, әлеге гамәл кайберәүләрнең сәламәтлегенә житди куркыныч тудырырга мөмкин икән. Аспирин, канның агучанлыгын арттырып, йөрәктәге һәм баш миендәге тамырларда тромблар оешудан саклый. Оксфорд тикшеренүе исә, киресенчә, аспиринның инсульт бәрү куркынычын арттыруын дәлилләгән, бигрәк тә өлкән яшьтәге кешеләрдә. Ни өчен шулай килеп чыга соң? Әлеге афәтнең ике төре бар: ишемия инсультын тромблар китереп чыгара, геморрагик инсульт вакытында исә тамырлар шартлый һәм баш миенә кан сава. Нәкъ менә икенче төр инсультларның артуында аспирин гаепле икән. Чөнки, канны агучанрак итеп, әлеге препарат эчке кан агуын берничек тә туктатып булмаслык ясый. Шунлыктан, 50 яшьтән узган һәркемгә аспирин эчәргә киңәш бирсәләр дә, йөрәге авыртмаган кеше моннан тыелырга тиеш. Инсульттан саклану юллары исә бик гади: кан басымын даими тикшереп тору, дөрес туклану, тоз куллануны чикләү, тәмәке тартмау, алкоголь белән мавыкмау, физик күнегүләр ясау.

(“Le Figaro”).

Куркыныч картиналар

Курку, хәвеф хисе тудыра, хуҗасын акылдан язар дәрәҗәгә җиткерә торган картиналар була. Шундыйлардан иң күренеклесе – Леонардо да Винчиның “Джоконда”сы. Ул кешенең яшәү көчен суыра икән. Моны беренче булып XIX гасырда яшәгән атаклы француз язучысы Стендаль сизгән. Лувр хезмәткәрләре дә моны раслый. Әгәр картина янына кешеләр кертелмәсә, “Мона Лиза” күзгә күренеп тоныклана, тамашачылар залга керүгә үк, картинаның буяулары бик ачык төскә керә, Джоконданың елмаюы тагын да серлерәк тоела башлый икән. Аның каршында озак басып торучылар исә аңын югалтып егыла. Эдвард Мункның “Кычкыру тавышы” картинасы үзен “үпкәләткәнне” яратмый. Бервакыт музей хезмәткәре 120 миллион доллар торган әлеге җәүһәрне ялгыш кулыннан төшереп җибәргән, шул көннән соң мескенкәйнең бик каты башы авырта башлаган. Авыртуга түзә алмыйча, егет үз-үзенә кул салган. Ә бервакыт музейда берәү картинага бармагын тидереп алган. Шул ук көнне өендә янгын чыгып, әлеге кеше терелэй янып үлгән. 1906 елда Клод Моне язган “Су лаләләре”н кая элләр, шунда янгын чыга. Диего Веласкесның “Көзге каршындагы Венера”сын сатып алган һәркем хәерчеләнә. Питер Брейгельнең “Сихерчеләргә табыну” картинасына кызыгучылар исә баласызлыктан интегә: кем генә сатып алмасын, гаиләдә 10-12 ел буе бала тумый.

(“Die Welt”).

Озын гомерлеләр авылы

Кытайның Гуанси Чжуан районындагы Бама Яо округы үзендә озын гомерлеләр күплеге белән дан тота, Пиньан авылында йөзьяшәрләр бигрәк тә күп. Әлеге авыл таулар арасында урнашкан, халкы дөге һәм яшелчә үстерә. Һавасында кислородның тискәре ионнары күп, магнит кыры да кеше организмына физик яктан да, психологик яктан да бик уңай тәэсир итә – хәтта бирегә беразга гына кунакка килүчеләрнең дә бөтен шик-шөбһә, курку-хәвефләре юкка чыга. Эчә торган сулары да, таудагы табигый фильтрлар аша үтеп, сафлана һәм минераль матдәләргә байый. Иген һәм яшелчә үстерә торган җирләрендә исә файдалы микроэлементлар искиткеч күп. Бирегә еш кына яман шештән интегүчеләр килеп урнаша, бераз вакыттан соң алар сихәтләнә. Җирле халык ризыкка талымсыз. Тоз һәм шикәр – алар табынында сирәк кунак. Нигездә халык дөге һәм арпа боткасы, бәрәңге, кукуруз һәм балык ашый. Соядан ясалган тофу белән женьшеньне ризыкны тәмләтер өчен өсти. Су яки яшел чәй эчәләр, алкоголь кулланучы, тәмәке тартучы юк диярлек. Авыл халкы яшьлек һәм үлемсезлек үләне саналган гиностемма һәм башка үлән төнәтмәләрен еш эчә. Күпчелек көненә бер-ике тапкыр гына ашый, иртә йокыга ята һәм иртүк тора да. Бамбуктан ясалган, чирәп белән ябылган йортларда яшиләр. Бирәдәге халык бик тыныч холыклы, сабыр, кунакчыл, юмарт, юкка-барга борчылмый, көнләшми, байлык артыннан кумый. Музыка уен коралларында уйнарга яраталар. Геронтологлар фикеренчә, җирле халыкның сәламәтлеге нык, гомере озын булуның тагын бер сәбәбе – генетикада. Бирәдә кытайлар түгел, бәлки азчылык милләт вәкилләре – чжуаннар яши, алар шушы экологик чиста тау итәгендә гомер-гомергә алны-ялны белми дөге иккән һәм, ихтимал, нәкъ менә шуңа нык, актив, сәламәт, шат күңелле халык формалашкандыр. Ни кызганыч, туристлар күбәйгәч, Бамадагы экосистема һәм гармония зыян күрә башлаган.

(“РБК”).

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

14 март

Телевизор караучылар игътибарына! Хоккей буенча Гагарин кубогы уеннары башлану сәбәпле? программада үзгәрешләр булуы ихтимал.

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 15.15 «АК ЧӘЧӘКЛӘР». 12+
10.00, 23.30 «ЛЮБОВЬ ПО ПРИКАЗУ». 12+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.40 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
13.00 «Семь дней». 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 12+
14.45 «Уймак» һәм «Сәйлән».
17.00 «Мин». 12+
17.30 «Татарстан без коррупции». 12+
19.00, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру». 12+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «Реальная экономика». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.20 «Шаян хәлләр». 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
15.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+
21.25 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЛАНЦЕТ». 12+
10.30, 21.00 «ДВОЙНАЯ ЖИЗНЬ». 12+
11.30, 17.10 «ФАМИЛЬНЫЕ ЦЕННОСТИ». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «СПАРРИНГ». 16+
14.35 «Люди РФ». 12+
15.00 «Это лечится». 12+
15.30 «Мечтатели». 12+
16.20 «Фиксики».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00, 9.25 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор».
12.15, 17.00 «Время покажет». 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
18.40 «На самом деле». 16+
19.45 «Пусть говорят». 16+
21.00 «Время».
21.30 «ЯНЫЧАР». 16+
23.25 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 Минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.40, 10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Невский ковчег. Теория невозможного. Даниил Хармс.
7.35 «Мозг. Эволюция».
8.50 «ПОД КУПОЛОМ ЦИРКА».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 XX век. «По ту сторону рампы. Валентина Талызина».
12.15 «Дом полярников».
12.55 К 65-летию Дмитрия Астрахана. Линия жизни.
13.50 «Феномен Кулибина».
14.30 «Другая жизнь Натальи Шмельковой. Леонид Губанов и Лев Рыжов».
15.05 Новости. Подробно. АРТ.
15.20 «Агора».
16.20 Цвет времени. Камера-обскура.
16.35 Феликс Мендельсон. Инструментальные концерты. Никита Борисоглебский, Борис Березовский и ГАСО России им. Е.Ф. Светланова.
18.05 «Новый взгляд на доисторическую эпоху».
19.00 Кто мы? «Имперские портреты». «Творец Империи».
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 «Бунин - Чехов. Неоконченная книга».
21.30 «Сати. Нескучная классика...»
22.15 «БЕРЕЗКА».
23.10 «Школа будущего».

«НТВ»

4.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.20 Сегодня.
8.25, 10.25 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ. СУДЬБЫ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ПЕРВЫЙ ОТДЕЛ». 16+
23.40 «ПЁС». 16+

Сишәмбе

15 март

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР». 12+
10.00, 23.00 «ЛЮБОВЬ ПО ПРИКАЗУ». 12+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
11.15 «Память сердца». 12+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
13.00 «Туган җир». 12+
13.30 «Юлчы». 6+
14.00 «Путь». 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
14.45 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ». 12+
15.15 «Уймак» һәм «Сәйлән».
16.00 «Ватандашлар». 12+
18.00 «Казаннан - казанга». 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00, 0.15 «Соотечественники». 12+
23.50 «Видеоспорт». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Җырлыйк әле!» 6+
9.40 «Туган җир». 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
15.30 «Тамчы-шоу». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЛАНЦЕТ». 12+
10.30, 21.00 «ДВОЙНАЯ ЖИЗНЬ». 12+
11.30, 17.10 «ФАМИЛЬНЫЕ ЦЕННОСТИ». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «КРОМОВЪ». 16+
15.00 «Инвиво». 12+
15.30 «Погоня за вкусом». 16+
16.20 «Фиксики».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00, 9.25 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор».
12.15, 17.00 «Время покажет». 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
18.40 «На самом деле». 16+
19.45 «Пусть говорят». 16+
21.00 «Время».
21.30 «ЯНЫЧАР». 16+
23.25 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 Минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05, 20.05 «Правила жизни».
7.35, 18.05 «Новый взгляд на доисторическую эпоху».
8.35, 17.50 «Первые в мире».
8.50 «ПОД КУПОЛОМ ЦИРКА».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 XX век. «Муслим Магомаев. Первый сольный концерт».
12.10 Дороги старых мастеров. «Мстёрские голландцы».
12.25, 22.15 «БЕРЕЗКА».
13.20 Жизнь замечательных идей. «Телепортация: правила игры в кости и квантования кроликов».
13.50 «Игра в бисер» «Василий Белов. «Лад».
14.30 «Другая жизнь Натальи Шмельковой. Анатолий Зверев».
15.05 Новости. Подробно. Книги.
15.20 «Эрмитаж».
15.50 «Сати. Нескучная классика...»
16.35 К 30-летию Камерного ансамбля «Солисты Москвы».
19.00 Кто мы? «Имперские портреты». «Просветитель Империи».
19.45 Главная роль.
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.50 Искусственный отбор.
21.30 «Белая студия».
23.10 «Школа будущего».

«НТВ»

4.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.20 Сегодня.
8.25, 10.25 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ. СУДЬБЫ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ПЕРВЫЙ ОТДЕЛ». 16+
23.40 «ПЁС». 16+

Чәршәмбе

16 март

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР». 12+
10.00, 23.00 «ЛЮБОВЬ ПО ПРИКАЗУ». 12+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
13.00, 0.40 «Җырлыйк әле!» 6+
14.00 «Азбука долголетия». 6+
14.15 «Если хочешь быть здоровым...» 12+
14.45 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ». 12+
15.15 «Шома бас» һәм «Калеб».
16.00 «Переведи!» 6+
18.00 «Халкым минем...» 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00, 23.50 «Соотечественники». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 8.40, 23.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
9.40 «Ачыктан-ачык». 12+
10.30, 20.30 «Юлчы». 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
15.30 «Яшьләр тукталышы». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЛАНЦЕТ». 12+
10.30, 21.00 «ДВОЙНАЯ ЖИЗНЬ». 12+
11.30, 17.10 «ФАМИЛЬНЫЕ ЦЕННОСТИ». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «Я, СНОВА Я И МАМА». 16+
14.30 «Люди РФ». 12+
15.00 «Без химии». 12+
15.30 «Инстаграмщицы». 16+
16.30 «Фиксики».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00, 9.25 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор».
12.15, 17.00 «Время покажет». 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
18.40 «На самом деле». 16+
19.45 «Пусть говорят». 16+
21.00 «Время».
21.30 «ЯНЫЧАР». 16+
23.25 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 Минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05, 20.05 «Правила жизни».
7.35, 18.05 «Новый взгляд на доисторическую эпоху».
8.35 «Первые в мире».
8.50 «БАЛ В «САВОЙЕ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «Опознание, или По следам людоеда».
12.10 «Забытое ремесло».
12.25, 22.15 «БЕРЕЗКА».
13.20 Жизнь замечательных идей. «Поймать неуловимое и взвесить невесомое...»
13.50 Искусственный отбор.
14.30 «Другая жизнь Натальи Шмельковой. Владимир Яковлев».
15.05 Новости. Подробно. Кино.
15.20 «Библейский сюжет».
15.50 «Белая студия».
16.35 Всероссийский юношеский симфонический оркестр под управлением Юрия Башмета «Триптих».
17.20 Больше, чем любовь. Татьяна Шмыга.
19.00 Кто мы? «Имперские портреты». «Герой Империи».
19.45 Главная роль.
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.50 Абсолютный слух.
21.30 Власть факта. «Наследие де Голля и современная Франция».
23.10 «Школа будущего».

«НТВ»

4.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.20 Сегодня.
8.25, 10.25 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ. СУДЬБЫ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ПЕРВЫЙ ОТДЕЛ». 16+
23.40 «ПЁС». 16+

Пәнҗешәмбе

17 март

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР». 12+
10.00, 0.00 «ЛЮБОВЬ ПО ПРИКАЗУ». 12+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 23.10 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Здоровая семья: мама, папа и я». 6+
14.15 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
14.45 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ». 12+
15.15 «Бергәләп өйрәник» һәм «Сәйлән».
16.00 «Казаннан - казанга». 12+
18.00 «Юлчы». 6+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00 «Ватандашлар». 12+
22.10 «Наша Республика - наше дело». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Кәмит Җәвит». 16+
9.40 «Кунак БИТ Шоу». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
15.30 «Халкым минем». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.30 «Калеб». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЛАНЦЕТ». 12+
10.30, 21.00 «ДВОЙНАЯ ЖИЗНЬ». 12+
11.30, 17.10 «ФАМИЛЬНЫЕ ЦЕННОСТИ». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «ЛЮБОВЬ НЕ ПО СЦЕНАРИЮ». 16+
14.50 «История образования». 12+
15.00 «Это лечится». 12+
15.30 «Верю не верю». 16+
16.20 «Фиксики».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00, 9.25 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор».
12.15, 17.00 «Время покажет». 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
18.40 «На самом деле». 16+

19.45 «Пусть говорят». 16+
21.00 «Время».
21.30 «ЯНЫЧАР». 16+
23.25 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 Минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 «Правила жизни».
7.35 «Новый взгляд на доисторическую эпоху».
8.35 «Первые в мире».
8.55 «БАЛ В «САВОЙЕ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 100 лет Музею-заповеднику «Михайловское». XX век. «Семен Гейченко. Монолог о Пушкине».
12.10 «Забытое ремесло».
12.25, 22.15 «БЕРЕЗКА».
13.20 Жизнь замечательных идей. «Путешествие в параллельные вселенные».
13.50 Абсолютный слух.
14.30 «Другая жизнь Натальи Шмельковой. Венедикт Ерофеев».
15.05 Новости. Подробно. Театр.
15.20 Моя любовь - Россия! «Песня - душа казака».
15.50 «2 Верник 2».
16.35 Всероссийский юношеский симфонический оркестр под управлением Юрия Башмета «Триптих».
17.20 Больше, чем любовь. Роман Карцев.
18.05 «Куда ушли динозавры?»
19.00 Кто мы? «Имперские портреты». «Святой Империи».
19.45 Главная роль.
20.05 Открытая книга. Максим Лаврентьев. «Весь я не умру...»
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.50 «Гардемарины, вперёд!» Невидимые слёзы».
21.30 «Энигма. Рене Папе».
23.10 «Школа будущего».

«НТВ»
4.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.20 Сегодня.
8.25, 10.25 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ. СУДЬБЫ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ПЕРВЫЙ ОТДЕЛ». 16+
23.40 «ЧП. Расследование». 16+

Җомга

18 март

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР». 12+
10.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
11.00 «Нәсыйхәт». 6+
11.30, 16.30, 21.00 «Татарлар». 12+
12.00, 23.10 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 6+
14.15 «Рыцари вечности». 12+
14.45 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ». 12+
15.15 «Тәймә» һәм «Сәйлән».
16.00 «Мин». 12+
18.00 «Родная земля». 12+
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «КВН РТ-2022». 12+
0.00 «Соотечественники». 12+
0.25 «Вехи истории». 12+
0.50 «КИТӘМ, ДИМӘ...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Ком сәгате». 12+
9.40, 15.30 «Нәсыйхәт». 6+
10.30 «Казаннан казанга». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ». 16+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
19.10 «Туган җир». 12+
20.00 «Йөрәктән-йөрәккә». Гамил Әсхәдулла турында телеочерк. 6+
21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЛАНЦЕТ». 12+
10.30, 21.00 «ДВОЙНАЯ ЖИЗНЬ». 12+
11.30, 17.10 «ФАМИЛЬНЫЕ ЦЕННОСТИ». 16+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.50 «ВСЕ ПУТЕМ». 16+
14.40 «Люди РФ». 12+
15.05 «Инвиво». 12+
15.35 «Еда, я люблю тебя». 16+
16.30 «Фиксики».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.30 «Fam TV». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00, 9.25 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор».
12.15, 17.00 «Время покажет». 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.30 «Голос. Дети».
23.05 «Большая игра». 16+
0.05 «Джоди Фостер. Строптивое дитя». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 Минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.00 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 «Врубель».
7.35 «Куда ушли динозавры?»
8.35 Цвет времени. Эдгар Дега.
8.45 «ЛЕВ ГУРЫЧ СИНИЧКИН».
10.20 «СЕЛЬСКАЯ УЧИТЕЛЬНИЦА».
12.00 Открытая книга. Максим Лаврентьев. «Весь я не умру...»
12.25 «БЕРЕЗКА».
13.20 Цвет времени. Уильям Тёрнер.
13.35 Власть факта. «Наследие де Голля и современная Франция».
14.15 «Земляничная поляна Святослава Рихтера».
15.05 Письма из провинции.
15.35 «Энигма. Рене Папе».
16.20 «Забытое ремесло».
16.35 Всероссийский юношеский симфонический оркестр под управлением Юрия Башмета «Триптих».
17.20 «Цецилия Мансурова. Прекрасная насмешница».
18.05 «Царская ложа».
18.45 «Первые в мире».
19.00 «Смехоностальгия».
19.45 К 75-летию Аристарха Ливанова. Линия жизни.
20.40 «НА МУРОМСКОЙ ДОРОЖКЕ...»
22.10 «2 Верник 2».
23.20 «АБУ ОМАР».

«НТВ»
4.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 Сегодня.
8.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим». 6+
9.25, 10.25 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.45 «ДНК». 16+
17.55 «Жди меня». 12+
20.00 «Следствие вели...» 16+
21.00 «Страна талантов». 12+
23.40 «Своя правда». 16+

Шимбә

19 март

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
7.00 «Sиңа Миннән Sәлам». 6+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00 «Мин». 12+
11.30 «Казаннан - казанга». 12+
12.00, 0.30 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 12+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
13.30 «Созвездие - Йолдызлык-2022». 6+
14.30 «Юлчы». 6+
15.00 «Дусларыма - җырларым». Вәис Бәйрәмов концерты. 6+
16.00 «Әйдә, шаяРТ!» 12+
17.00 «СТЭНДАПхана». 16+
17.30 «Татарлар». 12+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Халкым минем...» 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
22.00 «КунакБиТ- шоу». 12+
23.00 «МИЛЛИОН В БРАЧНОЙ КОРЗИНЕ». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00 «Бәркет канатында хөрлек бар». Адлер Тимергалин турында телеочерк. 6+
7.00, 15.00 «Sиңа Миннән Sәлам». 6+
9.00 «Кәмит Җәвит». 16+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 6+
13.00 «Көлке чыбыркысы». «Мунча ташы» театры спектакле. 12+
17.10 «Казаннан казанга». 12+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Серләреңне миннән яшермә». Ринат Мөслимовның иҗат кичәсе. 6+
23.10 Спектакль «Гөлҗамал». 12+

«ЭФИР»
5.00 «Без химии». 12+
5.30 «Люди РФ». 12+
6.30 «Опыты дилетанта». 12+
7.00 «Катя и Эф. Куда-Угодно-Дверь».
7.30 «Лекс и Плу: Космические таксисты».
8.00 «Прокуроры 2». 16+
8.45 «ОДНА ЛОЖЬ НА ДВОИХ». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «РЕПРОДУКЦИЯ». 16+
14.50 «Все, кроме обычного». 16+
16.00 «ПСИХОЛОГИНИ 2». 16+
18.10 «УЛЕТНЫЙ ЭКИПАЖ». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «СКРЮЧЕННЫЙ ДОМИШКО». 16+
23.00 «Человек - невидимка». 16+
23.55 «ДЕВЯТЬ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.00 «Умницы и умники». 12+
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00 Новости.
10.15 «Амурский тигр. Хозяин тайги». 16+
11.15, 12.15 «Видели видео?»
14.00 Балет на льду Татьяны Навки «Лебединое озеро».
15.45 «Кто хочет стать миллионером?»
17.20 «Наша Надя». 16+
19.20 45 лет ансамблю «Русская песня». 12+
21.00 «Время».
21.20 «ОДИН ВДОХ». 12+
23.15 «ОДИССЕЯ». 16+

«РОССИЯ»
5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00 Вести.
11.30 «МОЙ ЧУЖОЙ РЕБЕНОК». 12+
13.30 «ТОЛЬКО О ЛЮБВИ». 12+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
20.00 Вести в субботу.
21.00 «ПРОСТИ ЗА ЛЮБОВЬ». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Библейский сюжет».
7.05 Мультфильмы.
8.10 «НА МУРОМСКОЙ ДОРОЖКЕ...»
9.40 «Обыкновенный концерт с Эдуардом Эфировым».
10.05 «ЖЕНИТЬБА».
11.45 «Гиперболоид инженера Шухова».
12.25 «Брачные игры».
13.20 «Рассказы из русской истории. XVIII век». Владимир Мединский.
14.25 «УРОКИ ФРАНЦУЗСКОГО».
15.50 «Валентин Распутин. Во глубине Сибири».
16.30 «Гардемарины, вперёд!» Невидимые слёзы».
17.10 К 100-летию со дня рождения Ирины Антоновой. «Одиночество на вершине».
18.05 «Первые в мире».
18.25 75 лет Владимиру Урину. Линия жизни.
19.20 «АНАТОМИЯ УБИЙСТВА».
22.00 «Агора».
23.00 XV Зимний международный фестиваль искусств в Сочи.

«НТВ»
4.55 «ЧП. Расследование». 16+
5.25 «ДВЕНАДЦАТЬ ЧАСОВ». 16+
7.20 Смотр.
8.00, 10.00, 16.00 Сегодня.
8.20 «Готовим с Алексеем Зиминым».
8.50 «Поедем, поедим!»
9.25 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда с Сергеем Малозёмовым». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.05 «Однажды...» 16+
14.00 «Своя игра».
15.00, 16.20 «Следствие вели...» 16+
19.00 «Центральное телевидение».
20.20 Ты не поверишь!. 16+
21.20 «Секрет на миллион». 16+
23.30 «Международная пилорама». 16+

Якшәмбе

20 март

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 Нәфкать Нигъмәтуллин концерты. 6+
7.00 «Sиңа Миннән Sәлам». 6+
8.00, 13.00 «Адымнар». 12+
8.30 «Хайкю». 12+
9.00 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы». 12+
10.15 «Ачыктан - ачык». 12+
11.00 Илсөя Бәдретдинова концерты. 6+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент.Общество». 12+
13.30 «Созвездие - Йолдызлык-2022». 6+
14.30 «Дания Нуруллинаның юбилей кичәсе». 6+
16.00 «Ком сәгате». 12+
17.00 «Видеоспорт». 12+
17.30 «Татарлар». 12+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». 12+
20.00 «Ватандашлар». 16+
20.30 «Болгар радиосы» концерты. 6+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
23.00 «ГОЛОГРАММА ДЛЯ КОРОЛЯ». 18+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05, 12.35, 23.20 «Халкым минем». 12+
5.30, 13.35 «Нәсыйхәт». 6+
6.00, 13.00, 0.40 «Татарлар». 12+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
7.00, 16.00 «Sиңа Миннән Sәлам». 6+
8.00 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
9.00 «Йөрәктән - йөрәккә». Мәсгудә Шәмсетдинова турында телеочерк. 6+
10.00 «Юлчы». 6+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.45 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05 «Яшьләр тукталышы». 12+
14.05 «Олы юл әйтте...» циклыннан. Үткәннәрне барлап... Айдар Фәйзрахманов. 6+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате». 12+
20.00 «Семь дней». 12+
21.10 «Айлы кичтә». Энҗе Шәймөрзина концерты. 6+

«ЭФИР»
5.00 «Инвиво». 12+
5.30 «Люди РФ». 12+
6.30 «Опыты дилетанта». 12+
7.00 «Катя и Эф. Куда-Угодно-Дверь».
7.30 «Лекс и Плу: Космические таксисты».
8.00 «Прокуроры 2». 16+
8.45 «История образования». 12+
9.00 «ПСИХОЛОГИНИ 2». 16+
11.10 «УЛЕТНЫЙ ЭКИПАЖ». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «СКРЮЧЕННЫЙ ДОМИШКО». 16+
15.00 «Мечтатели». 12+
15.45 «ОДНА ЛОЖЬ НА ДВОИХ». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «РЕПРОДУКЦИЯ». 16+
22.50 «Человек - невидимка». 16+
23.45 «Не оглядывайся». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.20, 6.10 «ВОПРЕКИ ВСЕМУ». 12+
6.00, 10.00, 12.00 Новости.
6.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.40 «Часовой». 12+
8.10 «Здоровье». 16+
9.20 «Непутевые заметки». 12+
10.15 Жанна Бадоева в проекте «Жизнь других». 12+
11.15, 12.15 «Видели видео?»
14.05 «Суровое море России». 12+
15.55 Ко дню рождения Александра Вертинского. «Жил я шумно и весело». 16+
17.05 «Доченьки». 16+
18.00 «Вертинский. Песни». 16+
19.05 «Две звезды. Отцы и дети». 12+
21.00 «Время».
22.00 «ТРОЕ». 16+

«РОССИЯ»
5.20 «ФОРМУЛА СЧАСТЬЯ». 12+
7.15 «Устами младенца».
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00 Вести.
11.30 «РАБОТА НАД ОШИБКАМИ». 12+
13.40 «ТОЛЬКО О ЛЮБВИ». 12+
17.50 «Танцы со Звёздами». 12+
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Маугли».
8.10 «УРОКИ ФРАНЦУЗСКОГО».
9.35 «Мы - грамотеи!»
10.20 «МОЙ НЕЖНО ЛЮБИМЫЙ ДЕТЕКТИВ».
11.45 Письма из провинции.
12.10 Диалоги о животных.
12.55 Невский ковчег. Теория невозможного. Августин Бетанкур.
13.20 «Рассказы из русской истории. XVIII век». Владимир Мединский.
14.40 Закрытие международного фестиваля искусств в Сочи Юрия Башмета.
16.30 «Картина мира с Михаилом Ковальчуком».
17.10 100 лет со дня рождения Ирины Антоновой. «Одиночество на вершине».
18.25 «Романтика романса».
19.30 Новости культуры.
20.10 «ЖЕНИТЬБА».
21.50 Балет «Корсар».
23.50 «Кинескоп». Международный кинофестиваль в Гётеборге.

«НТВ»
4.45 «ЗОЛОТОЙ ТРАНЗИТ». 16+
6.35 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 Сегодня.
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
12.00 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.00 «Своя игра».
15.00, 16.20 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации». 16+
19.00 Итоги недели.
20.10 «Маска». 12+
23.20 «Звезды сошлись». 16+

Мөлкәт белән бәйле җинаятьләрнең күпчелеген вак-төяк әйбер урлау очраклары тәшкил итә. Ошбу бурлар арасында даими рәвештә аннан-моннан чәлдереп көн күрүчеләр дә, кул астына эләккән малга кызыгып хур булучылар да бар. Бу яктан Балтач яклары да башкалардан аерылмый.

Хурлыклы вак бурлыклар

Узган ел 21 августта район үзәгендә яшәүче Илсур (зарар күрүчеләрнең исемнәре үзгәртелә) телефонында саклык банкы картасындагы акчасы чигерелү турындагы өч СМС хәбәр күреп ала да шунда ук андагы кушымта ярдәмендә хәзинәсен «биккә» куя. Моның бик вакытлы эшләнүе тиз ачыклана, чөнки биш минут та узмый «Магнит Косметик» кибетендә 799 сумны күчерергә омтылыш ясалуы хакындагы дүртенче язма килә.

Илсур шул көнне үк полициягә гариза яза. Оперативник Рөстәм Хәлиуллинга эшне кайдан башларга дип баш ватып торырга туры килми. Телефонда көндезге сәгать 11 белән 12 арасында Нормадагы ягулык салу станциясендә, Кариледәге «Светофор», Балтачтагы «Магнит» кибетләрендә 500, 565 һәм 899 сум акча сарыф ителүе һәм, әйтелгәнчә, «Магнит-Косметик»та акча шудыру кисәтелү турында мәгълүмат бар бит. Соңгысында видеокүзәтү җайланмасы эшләмәсә дә, калган өчесендә яшь егет аермачык күренеп тора, «заправка»да үзе генә түгел, «Лада Калина» машинасы да эләгә объективка.

Кыскасы, шул ук көнне кичкә таба 22 яшьлек Фирзәр Билаловның телефонына таныш булмаган ир-ат шалтырата һәм район эчке эшләр бүлегенә чакыра. Бу инде егетнең, иң әүвәл, үзе өчен зур мәшәкать чыгаруын белдерә. Банк картасын алдагы кичтә Карадугандагы «Радик» кибете каршында табып кесәсенә шудырган һәм күктән төшкән байлыктан файдаланмыйча кала алмаган ул.

Район полициясе тикшерүчесе Ирек Галимуллин аңа җәмгысе 2765 сум чит кеше акчасын чәлдерергә омтылыш ясау дигән гаепләү белдерә. Ул хуҗаның счетны ябып куюы аркасында гына максатына ирешә алмаган дип санала, ә анда 241 мең сум акча була. Матди зыян кайтарып бирелә, әлбәттә. Шулай да моңарчы хөкемгә тартылганы булмаган юньле егеткә хөкемдар чагыштырмача кырысрак җәза билгели кебек, чөнки ул бер елга ирегеннән мәхрүм ителә. Шартлы рәвештә, әлбәттә.

* * *

Сырья дигән удмурт авылында яшәүчеләр Ираида һәм Петр Пчельниковларны бары тик уңай яктан бәялиләр. Өч балалы гаилә мал-туар асрап, элеккеге күмәк хуҗалык урынында барлыкка килгән аерым затлар карамагындагы «Труд» җәмгыятендә эшләп яши. Ир кеше слесарь-механизатор, хатын-кыз фермада дуңгызлар карый.

Колхозныкы җәл түгел дигәндәй, авыл җирләрендә әкренләп урлашу гадәте сакланган әле. 2021 елның 17 мартында Пчельниковлар да җәмгыять дуңгызларына дигән азыктан үз малкайларына да өлеш чыгарырга уйлый. Алдан хәзерләнгән план буенча, кич белән көндез терлекче, төнлә каравылчы булып эшләүче хатын күрмәгәндә, Ираида 25 әр килолы капчыкларны шлагбаум янына ташып куярга, Петр «Шевроле-Нива» белән шунда килеп туктарга тиеш була.

Бу кадәресе шома гына бара. Бер капчык ясалма («заменитель цельного молока») һәм ике капчык вакланган ашлык салынган машина Пчельниковлар йортына таба кузгала. Ләкин хәерчегә җил каршы, дигән әйтем дә бар бит әле. Шул мәлдә бу якларда, кем әйтмешли, биш былтыр күренмәгән «ДПС» машинасы пәйда була. Инспектор Айрат Петрның документларын тикшереп үзенең аек икәненә инангач, багажникка күз төшерә, әлбәттә, теге өч капчыкка игътибар итә һәм аларның килеп чыгышы белән кызыксына башлый.

Ялган оештырып торуның файдасыз икәнен төшенгән ирле-хатынлылар «Труд» җәмгыяте дуңгызлары өлешенә керүләрен әйтеп бирәләр. Урланган малны янәшәдәге фермага илтеп ташлау, ягъни җинаять җаваплылыгыннан котылу мөмкинлеге бирелми. Хуҗалыктан җитәкче хезмәткәр, эчке эшләр бүлегеннән тикшерү төркеме килә, барлыгы 3300 сум торган байлыкның урлануы рәсми рәвештә теркәлә. Билгеле ки, төркем белән, төгәлрәге, парлашып урлау очрагы буенча җинаять эше кузгатыла.

Зарар күрүче якның үз эшчеләрен җинаять җаваплылыгына тартуны сорап язган гаризасы шулай кирәк булганга һәм аларга сабак, башкаларга гыйбрәт өчен генә була. Берәү дә аларга кырыс җәза бирергә теләми. Урланган мал да урынына кайтарып куела бит. Нәтиҗәдә, Балтач район суды якларның килешүе сәбәпле дигән билгеләмә белән Пчельниковларны җинаять җәзасыннан азат итәргә дигән карар чыгара.

* * *

Балтачтагы «Магнит» кибетендә товаровед булып эшләгән Илнар Зарипов та (исеме үзгәртелә) тел-теш тидерерлек кеше түгел. Бары тик 2019 елда шушы сәүдә үзәгеннән урлашуы калкып чыгу аркасында гына хур булды ул.

Аның әйтүенчә, бушаган контейнерларны кире озату өчен машинага төягәндә, икесенә урын җитми һәм алар кибеттә кала, ә шофер алдан язылган кәгазьләргә кул куя, ягъни алар алып кителгән булып исәпләнә. Искәртеп үтик, Франциядә эшләнгән 900 литр сыйдырышлы тәгәрмәчле әлеге контейнерларның һәрберсенең бәясе 50 мең сумга якын, алар бозыла торган товарны салкында тоту өчен файдаланыла, термобокс, термос дип йөртелә.

Шул рәвешле, ике кыйммәтле әйбер янга кала. Кибеттә ремонт эшләре башлангач И.Зарипов «Нива» машинасына тагылма арба тагып килә дә, аларны төяп Кариледәге гаражына кайтарып куя. Ике елдан артык вакыт узгач, ягъни 2021 елның 19 июнендә интернеттагы белдерүләр сайтына ике суыткыч контейнерны 10 мең сумга сату турында игълан урнаштыра. Күрәсең, урланган әйберләр онытылган дип фаразлый. Ләкин ялгыша.

«Магнит» сәүдә челтәре керә торган «Тандер» акционерлык җәмгыятенең Яшел Үзәндәге хәвефсезлек хезмәте әлеге белдерүне күрми калмый. Аны «Магнит»та товар белгече булып эшләгән И.Зарипов куюы да тиз ачыклана, Балтач полициясенә хәбәр ителә. Эш узгач, ике термоконтейнер хуҗасына кайтарыла. Экспертиза 2010-2011 елларда чыккан ошбу савытларның гомуми бәясе 56 мең дип таба, ләкин зарар күрүче як моның белән килешми һәм 97552 сумлык матди зыян китерү турында И. Зариповка гаепләү белдерелә. РФ Җинаять кодексында гади урлау түгел, ә бәлки ышанып тапшырылган милекне хезмәт вәкаләтләреннән файдаланып үзләштерү дигән җитди җинаять санала бу. Хөкем чыгарылмаган әле. Моңарчы хөкемгә тартылмаган, холык-тәртибе уңай бәяләнгән ике кечкенә бала атасы колониягә озатылмас дип ышаныйк.

* * *

Ә менә 1979 елгы Чепья кызы С.Васильева узган ел телефон чәлдергән өчен бер ел да ике айга төзәтү колониясенә озатылды. Чөнки телгә алынган якташлары кебек беренче абынуы гына түгел аның, ә бәлки яшьтән угрылыкка башын салган өметсез ханымның инде 14 нче хөкеме бу.

Күбесенчә угрылыклар кылып җавап тоткан, шулай ук административ күзәтчелек шартларын үтәмәгән, баласына алимент түләмәгән, яшүсмерләрне аракы эчәргә җәлеп иткән, чит кеше торагына кергән өчен дә хөкем ителгән. Балтач кына түгел, Арча һәм Киров өлкәсендәге Малмыж каласы судларында мәҗбүри, төзәтү эшләре, ирегеннән шартлы рәвештә мәхрүм итү кебек җиңел җәзалар да бирелгән, бер-ике елга колониягә ябылган чаклары да булган. Алты ай утырып 2021 ел башында Балтачка кайткач та тагын 5 айлык шартлы хөкем алырга да өлгергән инде.

Боларга юньсез хатынның эчкече буларак исәптә торуын да өстик. Яшәү урыны буенча кайчандыр Яңа Салавычта бергә торган ире Илмас өендә теркәлгән булса да, рәсми кәгазьләрдә даими торагы булмаган зат санала ул, ләкин сәләмә киемле сукбайлар кебек чүплектә актарынып, ташландык йортларда кунып йөри дигән сүз түгел бу. Чөнки дуслары күп, хәзер 42 яшендәге ирекле ханымның ир затлары арасында абруе да бар кебек.

2001 елның маенда Балтачта «кунакта» була ул. Кичкә таба элеккеге «сожителе» Илмаска шалтырата, таныш таксистны чакырып, аның янына китә, шул ук авылда яшәүче 52 яшьлек тагын бер хатынны алып такси белән Кукмарага баралар. Андагы саунада кәеф-сафа корырга була исәпләре. Ләкин әллә исереклектән, әллә чыннан да буш урыннар булмаганга, аларны саунадан борып чыгаралар. Шактый гына Кукмара урамнарын буйлаганнан соң, сәрхушләр Илмас капкасы төбенә кайтып туктый. Лаякыл исерек хуҗа ишегалдына кереп китә, аның артыннан машинадан «кунак кыз» да чыга.

Күрәсең, аны өйгә чакыручы булмый. Светлана Кукмарага сәфәр кылган хатын өендә куна. Икенче көнне икәүләп Балтачка, Иркә атлы дуслары янына китәләр. Кичкә таба анда полиция килеп керә.

Эш шунда ки, Илмас иртән 8 меңлек телефонын таба алмый һәм бу хакта участок инспекторы Н.Фәйзрахмановка әйтә. Әңгәмә барышында кичке сәфәрне искә төшерергә һәм полициягә яхшы таныш С.Васильеваны телгә алырга туры килә. Чөнки телефонны сорап алып, Светлананың кемгәдер шалтыратканын хәтерли. Әлбәттә, һөнәри каракка шик төшми калмый. Бары тик йөремсәк хатынның кай тирәдә икәнен ачыклау мәшәкатьләрәк килеп чыга.

Угры телефонны да кайтарып бирә, гаебен дә таный. Бактың исә, Илмас телефонын онытып, машинаның арт утыргычында калдырып чыгып киткәч, авылдаш хатын-кыз, аны Светланага тоттырып, хуҗасына тапшырырга кушкан икән. Ләкин юньсез хатын кесәсенә кергән байлыктан баш тартырлык көч тапмаган үзендә. Нәтиҗәдә, чираттагы караклыгы өчен ундүртенче хөкемен алган.

Наил ВАХИТОВ.

Чирек гасырлык «КАЗАН»

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында «Казан» бию ансамбленең 25 еллык юбилеена багышланган концертлар узды. Программаның беренче өлешендә тамашачылар коллективның репертуарында булган иң яхшы номерларны карап хушланды. Бәйрәм уңаеннан, ансамбльнең егерме биш хезмәткәренә дәрәҗәле исем, мактау грамоталары һәм рәхмәт хатлары тапшырылды.

Концертның икенче бүлегендә «Голливуд» дип исемләнгән мюзикл форматындагы өр-яңа тамаша тәкъдим ителде. Гомуми сюжетка корылган биюләрдәге юмор, ирония, романтика, җыр һәм бераз гына куркыныч мизгелләр бер тамашачыны да битараф калдырмаячак иде. «Голливуд» сүзе күпчелек өчен якты хыяллар, матурлык, самими өметләр белән бәйле. Программада Америка мәдәниятенең иң яхшы, тарихта тирән эз калдырган музыка һәм хореография өлкәсе үрнәкләре урын алган. Бөек комик Чарли Чаплин, ир-егетләрне һуштан яздырырлык Мэрилин Монро, атаклы Элвис Пресли бродвей стилендәге данлыклы «Tapdogs» стэпын бии. Артистларның җете костюмнары, искиткеч музыка, югары кимәлдә башкарылган бию номерлары һичкем тел-теш тидерерлек түгел.

«Казан» бию ансамбленең сәнгать җитәкчесе, Татарстанның халык артисткасы Чулпан Закированың сәламләвеннән соң, ансамбль биючеләре һәм Татарстанның атказанган артисткасы Алинә Шәрипҗанова һәм Гөлназ Гафурова катнашында «Рәхим итегез!» дип аталган вокаль-хореографик композиция тәкъдим ителде. Аннары Татарстанның халык артисты Рәсим Ильясов җитәкчелегендәге «Казан нуры» халык уен кораллары оркестры чыгыш ясады. «Зәңгәр томан», «Егетләр», «Фламенко ритмнары», «Шәрык энҗеләре», «Кавказ ритмнары», «Калинка» биюләре сокландыргыч дәрәҗәдә башкарылды. Ә экранда коллективның тарихы, анда очрашып кавышкан гаиләләр турында кызыклы фильм, «Казан хәзинәләре», «Бөек ефәк юлы», «Зәңгәр шәл» музыкаль-хореографик спектакльләреннән өзекләр күрсәтелде. «Казан» хореография студиясендә шөгыльләнүче балалар катнашындагы «Халәй» төрек биюе тамашачыларга аеруча ошады.

Татарстан мәдәният министры урынбасары Ленар Хәкимҗанов котлау чыгышында «Казан» бию ансамблен республикабыз мәдәниятенең энҗе бөртеге дип атады, Россия күләмендә һәм чит илләрдә дә тамашачы мәхәббәтен яулавын билгеләп үтте. Хәзерге көндә коллективның яңартылган «Чулпан» мәдәният үзәгендә эшләп, балалар һәм яшьләр арасында хореография сәнгатен үстерү һәм колачлы проектлар булдыру мөмкинлегенә шатлыгын белдерде. Министр урынбасары ансамбль артистларына мактаулы исемнәр бирелү турында таныклыклар, мактау грамоталары тапшырды. Коллективны бу кичтә шулай ук Казан шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Гүзәл Сәгыйтова һәм башкаланың мәдәният идарәсе башлыгы Азат Абзалов та тәбрикләде.

Чулпан Закирова котлаулар өчен рәхмәтләрен җиткерде. «Артистның иҗат юлы бик җаваплы, җиңелләрдән түгел. Көн саен тир түгеп эшләргә һәм үзеңне һәрчак кулда тотарга кирәк. Юкка гына биюче хезмәтен шахтер эше белән тиңләмиләр бит. Хисләребезне бию теле аша җиткерәбез һәм эшебезне, тамашачыларны бик яратабыз», – диде ул.

«Казан» бию ансамбленә 1996 елда нигез салынган. Хәзерге вакытта коллективта 60 балет һәм 18 оркестр артисты эшли. Аларның күбесе ансамбльгә балачагында килгән. Шушы дәвердә ансамбль 4 меңнән артык концерт куйган. Биючеләрнең барлык костюмнары «Чулпан» мәдәният үзәгендә саклана. «Бер костюмның бәясе якынча 50-70 мең сум тора. Аларның һәркайсы – эксклюзив модель», – дип сөйләде ансамбльнең 25 еллык юбилеен билгеләп үтү уңаеннан уздырылган матбугат конференциясендә Чулпан Закирова.

«Казан» бию ансамбленең бәйрәм тамашасы озакламый «Чулпан» мәдәният үзәгендә дә тәкъдим ителәчәк.

Рәйсә БОРҺАНИЕВА.



Мәдәни җомга

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кульязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк, г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2

E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта: www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга. Бу санның чыгу көне 11.03.2022

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2750 данә

Заказ 2743

16+